Ренат Харрис
Избранные произведения
В семи томах

Статьи, выступления

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2006

# Сайланма әсәрләр
# Җиде томда

## Мәкаләләр, чыгышлар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006
Җыентыкны төзүче, текстларны хәзерләүче, кереш сүз авторы — филология фәннәре кандидаты, ТДГПУ доценты
*Фәридә Хәсәнова*

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Харисов Р.М.**

Сайланма әсәрләр: 7 томда / Ренат Харис; Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Хәсәнова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5-298-03912-X

7 т.: Мәкаләләр, чыгышлар. — 2006. — 511 б.

ISBN 5-298-03919-7

«Сайланма әсәрләр»нең бу томы Татарстанның халык шагыйре Ренат Харисның сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, тәнкыйтьче, публицист буларак эшчәнлеген яктырта.

ISBN 5-298-03919-7 (7 т.)
ISBN 5-298-03912-X

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Харисов Р.М., 2006

## Әдәбият белеме

### Җәйләр, көзләр нинди булыр?

*(«Беренче карлыгач» турында уйлану)*

Ундүрт яшь шагыйрьнең беренче шигырь җыентыклары быел аерым-аерым түгел, «Беренче карлыгач» дигән тартма «канаты» астында берләшеп чыкты. Халык сынамышларын искә төшерә торган бу уңышлы исем астында безнең шигърият дөньябызга кемнәр килде икән һәм алар бу дөньяга нинди яз китерделәр икән? Моны белү, минемчә, бик кызыклы һәм әһәмиятле, чөнки ул безнең шигъриятебезнең алдагы чәчәкле җәйләрен, җимешле көзләрен һәм торналар канатында илнең-җирнең төрле тарафларына китәчәк казанышларын күзалларга ярдәм итәчәк.

«Беренче карлыгач» алып килгән бу язны тулаем килеп уч табанына салу, һәрьяклап үлчәп карау, бәһа-

ләү, әлбәттә, бер кешенең, бер мәкаләнең генә кулыннан килә торган эш түгелдер, әмма прогноз өчен һәр фикернең дә күпмедер файдалы булуын зур шик астына алу урынсыз булыр иде.

«Беренче карлыгач» үз эченә вакытлы матбугатта 5–10 еллар дәвамында даими күренеп килгән авторларны туплаган. Димәк, авторлар шактый иҗади юл, сынаулар үткән кешеләр һәм нәшрият аларга әдәбиятның киң мәйданына чыгарга ишек ачкан. Ләкин әдәбият мәйданының киң булуы, аның меңләгән күңелләрдә, йөрәкләрдә булуы ишеккә гаҗәеп зур җаваплылык китерә...

Менә мин китап арты китап укыйм, шигырь арты шигырь хәтергә сеңә тора, шигырьләрдәге фикерләр, образлар, детальләр, алымнар аң тарафыннан тасланып конкретлаша, күңел экранында кайбер авторларның иң алдан бераз томан сарган, аннары шактый ачык булып күренгән лирик сурәтләре хасил була (ә кайберләренеке ниндидер сәбәпләр аркасында, билгеле, томаннан арына алмый кала) һәм «Беренче карлыгач» турында да, андагы авторлар, аларның китаплары турында да шактый гына фикерләр туа.

Килгән язның нәрсәләр вәгъдә иткәнен бераз гына булса да ачыклар өчен авторларга, мәкалә чикләре ирек биргәнчә, конкретрак тукталырга кирәктер.

Гәрәй Рәхимнең «Вәгъдә» исемле китабы тематик яктан, минемчә, «Беренче карлыгач»ның калган җыентыкларыннан әллә ни аерылып тормый. Ләкин андагы шигырьләрнең күңелне җәлеп итүләре, анда ниндидер яңа ассоциацияләр тудырулары, йөрәккә йә олы мәхәббәт, йә кискен нәфрәт хисе тутырып калдыра алулары шагыйрьнең бу күптән таныш темаларга да яңача карый алуы турында сөйлиләр.

Романнар, повесть-хикәяләр, драма әсәрләре кабатланмас образлар биреп иҗтимагый әһәмияткә, әдәби бәягә ия булганнары кебек, шигырь китаплары да үзләренең лирик геройлары, төгәлрәк итеп әйткәндә, шагыйрь образы белән кыйммәтледер. «Вәгъдә»нең лирик герое, һичшиксез, кызыклы образ. Ул дөньяга, тормышка конкрет критерийлардан чыгып карый һәм, бәхеткә каршы, бу критерийлар яшәешнең күп тармакларын колачлый алалар. Критерийлар шагыйрьнең иҗади агына катгый юнәлеш биргәннәр һәм бу юнәлеш тирәсендә шактый кызыклы шигъри дөнья калкып чыккан. Дөрес, бу дөнья әлегә яралу стадиясендә, ләкин аның кайдан башланганын, кая таба үсүен хәзер үк инде чамалап була.

Минемчә, Гәрәй Рәхимнең шигъри дөньясына керү өчен, аның критерийларын сиземләү өчен «Шигъри дөньям» дигәнне түгел, ә «Көзге урман», «Игеннәр илендә», «Миләш төбендә», «Каргалар киткәндә» дигән шигырьләрен укырга кирәктер. Алар, шагыйрьнең эчке монологлары буларак, Гәрәй Рәхимнең карашлары, идеаллары, өметләре турында ачыграк сөйлиләр, ә конкрет өметләрдән конкрет критерийлар туа. Бу шигырьләрнең гомумиләштерелгән фикерләрен «Тормышны көз кебек мул, күптөсле, бай хисле итеп күрәсем килә һәм мин аның шулай булачагына ышанам!» дигән җөмлә белән әйтеп булыр кебек. Ләкин шагыйрь идеаллар һәм чынбарлык арасында тарих үтәсе шактый озын һәм көрәш белән сугарылган юл барлыгын да күрә. Ул юл бер-берсе белән даими конфликтта торган, бер-берсен җиңеп, юк итеп барган контрастлардан, капма-каршылыклардан гыйбарәт, ә шагыйрь шигырьләренең һәр образы, һәр фикере белән диярлек тормышны ямьле иткән, бәхетле, якты иткән контрастларга үзенең көчен өстәргә тырыша — алар җиңсен! Аның мәхәббәте һәм нәфрәте, бер бәйгегә җигелеп, кеше күңелен гүзәллекләр иленә таба тарталар. «Вәгъдә»нең күпчелек шигырьләре менә шушы фәлсәфи нигезгә корылып язылганнар да. Дөрес, контрастларны шигъри дөньяларының нигезе иткән шагыйрьләр безнең әдәбиятыбызда бар. Аларның гүзәл бер вәкиле итеп мин Әхмәт Фәйзине китерер идем. Ләкин Гәрәй Рәхим Әхмәт Фәйзинең эпигоны түгел. Әгәр дә Әхмәт Фәйзи контрастларны сатирик йә юмористик планда алырга яратса, яшь шагыйрь аларны фәлсәфи планга куярга тырыша һәм үзенчә уңышлыкларга да («Вәгъдә», «Сагыш һәм шатлык», «Рас») уңышсызлыкларга да («Буыннан буынга», «Нәфрәт. Рәхмәт») ирешә. Ул уңышсызлыкларның нигезендә, минемчә, риторизмга сугылу, йә булмаса, контрастларның образ-фикер буларак төгәлләнеп җитмәве була.

Алда әйтелгәннәр «Вәгъдә» шигырен Гәрәй Рәхимнең методик һәм иҗади вәгъдәсе итеп карарга мөмкинчелек бирәләр, контрастлар мөнәсәбәтендәге фәлсәфи хәрәкәтләрнең әле үсәчәгенә, киңәячәгенә һәм тирәнәячәгенә ышанырга юл куялар. Бу инде килгән язның Гәрәй Рәхим өлешенә тигән ягы шактый матур җәйгә әвереләчәге турында сөйлидер.

Мөхәммәт Садыйковның «Зәңгәр юллар» исемле җыентыгы сугыш елларында үсеп, сугыштан соңгы елларда буй җиткән, формалашкан кеше образын гәүдәләндерә. Илебезнең, тарихыбызның бу чоры «Зәңгәр юллар»ның лирик герое агына шуның кадәр тирән сеңгән ки, хәтта аның безнең бүгенгебезгә булган мөнәсәбәтенә дә үзенең төсен, юнәлешен биреп тора һәм шушы юнәлеш Мөхәммәт Садыйковның шигъри дөньясына төзлек, үзенә генә хас булган колорит китерә. «Зәңгәр юллар»ны, кайбер ташламалар ясап, урыны-урыны белән нык бәйләнештә булган, урыны-урыны белән ул бәйләнешне югалтып куйган шигырьләрдән хасил поэма дип тә атап булыр иде.

Мөхәммәт Садыйковка өстенә шинель киеп, иңенә солдат биштәре асып, канлы сугышлар булган җирләрдә йөрергә туры килә. Ул Польша җирләрендәге концлагерь калдыкларын күрә, пуля эзләре калган мәрмәр сыннарга «җан өрердәй булып» карап тора, иске окопларда ниндидер солдат муеныннан төшеп калган медальонга тап була. Бу юлларның һәр адымы шагыйрь күңелендә сугышка нәфрәт, сугыш корбаннарына, батырларына олы ихтирам уята һәм драматизм тулы шигырьгә әверелеп бара. Туган җирләрдән еракта булу шагыйрьгә туган илнең кадерен татып карарга да ярдәм итә: Одра елгасын күрү аның күз алдына мәгърур Иделне китереп бастыра, постта торган чакта җилләр дә ил ягына исәләрдер кебек тоела...

Тынычлык өчен барган хәрби хезмәт тәмам. Солдат туган якларына кайтып бара. Кинәт аның йөрәгенә гаҗәеп хисләр тула, ул туган иленең юмарт кунакчыллыгын яңадан татып ни эшләргә белми... Һәм аның күңеленнән үзеннән-үзе тормыш яме, җир гүзәллеге турындагы шигырьләр таша башлый...

Бер карасаң, бу сюжет, бу фикерләр һәм хисләр безнең шигъриятебез өчен һич тә яңалык түгел. Шуның өстәвенә Мөхәммәт Садыйковның «Зәңгәр юллар»дагы шигъри дөньясы киңлек ягыннан да шактый чикле. Ләкин эш бу дөньяның тирәнлегендә һәм төгәллегендә, чөнки шушы нәрсәләр шагыйрьнең мөмкинчелекләрен күрергә ярдәм итәләр, ә чикләр, шагыйрьнең биографиясенә карап, киңәя ала торган нәрсәләр.

Җыеп әйткәндә, шул: «Зәңгәр юллар»ның лирик герое, сугыш чорларын күреп, сугыш дәһшәтләрен канына һәм аңына сеңдереп концентрацияләнгән образ буларак, сугыш һәм тынычлык беренчел проблема булып торган безнең дөньябызда һаман да үсәчәк, киңәячәк һәм тирәнәячәк.

Шамил Маннаповның «Яшьтәшләрем» һәм Хәниф Хөснуллинның «Исәнмесез» җыентыкларындагы лирик геройларның сурәтләрен ачык итеп күрү минем өчен әлегә кыен. Ләкин бу — шагыйрьләрнең үз йөзләре юк дип әйткән сүз түгел. Авторларның икесе дә җор сүзле, бай хисле, дөньяның җитди күренешләренә дә ничектер олыларча тыныч һәм юмор аша карый торган кеше булулары һәр шигырьдә диярлек үзләрен сиздерәләр. Шушы сыйфатлар аларның шигырьләренә көтелмәгән драматизм кертә, ә бу драматизм безгә күптәннән таныш булган детальләрне дә кызыклы образларга әвереләдерә. Шул ук вакытта Шамилнең шигырьләре Хәнифнекеннән, билгеле, аерылып торалар. Әгәр дә Хәнифтә бу драматизм лирик геройның шушы мизгелдә кичерә торган тойгылары нигезендә булса, Шамилдә ул детальләр параллелизмы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Ягъни Хәнифнең лирик герое үзе дә драматизмны тудырган вакыйга эчендә була («Институтта», «Көзге төндә», «Рәсемеңне күрдем бирәүдә», «Тынгысыз төннәр»), ә Шамилнең лирик герое тормыш детальләрен күп вакыт абстракт төшенчә килеш чагыштырырга ярата, бу параллелизмнан килеп чыккан драматизм гомумирәк төскә ия була («Охшату», «Әйтә халык», «Кеше хисе»), һәм лирик герое Шамилгә күргәне генә түгел, ишетеп белгәне турында да язарга мөмкинчелек бирә, шагыйрьнең тематик диапазонын киңәйтә.

Бу чагыштырудан соң тойгыларга нигезләнгән шигъри дөнья фәлсәфәгә корылган шигъри дөньядан тар-рак була икән дип уйлау дөрес булмас иде, чөнки кеше тойгыларының төсмерләре, тормыш вакыйгаларының кеше аңындагы аналитик чагылышлары буларак, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да чиксезләр. Тойгылардан туган шигъри дөньяларның бик әһәмиятле үзенчәлекләре бар: алар логик анализга бик авыр бирелә-ләр һәм шагыйрьнең фикерләре фабуласын күзалларга шактый комачаулыйлар. Шуның өстенә дә «Яшьтәшләрем»нең, бигрәк тә «Исәнмесез»нең лирик геройларын ачык итеп сурәтләү артык җиңел эш түгел. Ләкин бу билгесезлек, минемчә, куркыта торган нәрсә түгел, киресенчә, күңелгә авторлар белән тирәнрәк кызыксыну, аларның иҗатларыннан ниндидер яңалык өмет итү хисе тудыра торган күренеш, чөнки ике шагыйрьнең дә шигырь техникасы белән яхшы жонглерлык итүләре, көтелмәгән алым белән образлы фикерләүләре, биографияләре аларның мөмкинлекләренә оптимистларча карарга юл куя.

Алда саналган дүрт авторның тагын бер күркәм ягы бар. Ул — кешелекнең иң бөек ләззәте — фикер ләззәте! дигән фәлсәфи тәгълиматка шагыйрьләрчә инану. Шуның өчен дә алар кешенең акылына мәдхия җырлау белән беррәттән үзләренең образ-фикерләрен ләззәт бирерлек итәргә тырышалар. Бу инде «Литературная газета», «Литературная Россия» газеталарында күп телгә алына торган «интеллектуаль поэзия»гә якынаерга тырышу һәм кайбер нокталарда шактый якынаю дигән сүз.

«Беренче карлыгач»ның калган авторларына да тукталсаң яхшы булыр иде булуын (башка укучылар, бәлки, тукталырлар да), ләкин, мәкалә чикләрен ихтирам итеп, «Беренче карлыгач»ның башка гомумирәк мәсьәләләренә күз салыйк.

* * *

Китапханәнең кыйммәте андагы китапларның күплегендә һәм төрлелегендә булган кебек, шигъриятнең көче шагыйрьләрнең күплегендә һәм төрлелегендә. Менә 1967 елда ундүрт яшь шагыйрь үзләренең беренче китапчыкларын чыгардылар. 1968 елда да шуның хәтле үк яшь шагыйрь «беренче карлыгач» булырга тора. 1969 һәм 1970 елларда да, бәлки, нәкъ шулайдыр, чөнки үткән декабрь аенда гына булган яшь язучылар конференциясендә катнашкан шагыйрьләр саны шактый зур булды. Күрәсең, шигъриятебезнең киләчәге сан ягыннан бик өметле. Ләкин дөньяда «Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше» дигән критерий да барлыгын онытмаска кирәк. Бигрәк тә шагыйрь булырга җыенучылар күп булганда.

Шигырьләрне укый башлаганга кадәр китапчыктагы аннотацияләр белән танышып чыксаң, «Монда үзенчәлекле шагыйрьләр җыелган икән!» дигән фикергә киләсең. Ә шигырьләрне укыганда бу өмет тулы фикер әкренләп үзгәрә башлый.

...Кулыңа алган туфрагың
Манчылсын кайнар тиргә.

*Д.Сирай*

Таныш юллар мине алып кайтыр
Тирем тамган колхоз җиренә.

*З.Шәйхуллов*

Маңгаемнан тирләр тамганда...

*Ә.Гайнуллин*

Сай буразналар өстенә
Түгелде маңгай тире.

*Р.Зәкиев*

Туфракны мин тирем белән ашлап...

*Е.Уткин*

Тир белән
Сугарып шул
Кысыр далаларны...

*З.Шәйхетдинов*

Мисалларда кабатланган һәр очракта «тир» сүзе «Әй, тырышып эшләдек тә соң!» дигән мәгънәгә ия. Утызынчы, илленче еллардагы безнең шигъриятебезгә хәтер канатында гына экскурсия ясасак, без бу образның бер мәгънә эчендә инде күптәннән бирле катып калганын күрер идек. Дөрес, сугыш елларында күп очракларда «тир» сүзе «кан» сүзе белән алмаштырылган. Бу — образларның тарихи, социаль күренешләргә нык бәйле булулары турында кечкенә генә бер мисал. Утызынчы еллар инде күптән үтте, кулдан, хезмәт процессының нигезе буларак, урак, кәйлә, көрәк төште, һәм «тир» сүзе дә үзенең алда әйтелгән мәгънәсен яртылаш югалтты, тырышлык символы буларак беренчелекне тән тирләве түгел, аксыл тирләве алды. Шуңа күрә дә бу образ аңга, күңелгә тәэсир итүдән элегрәк борынга бәрә башлады. Кыскасы, ул шаблонланган әдәби фальшь булып яңгырый һәм шигырьләргә шактый искергән нәрсә булып күренергә кирәгеннән артык ярдәм итә. Кызганычка каршы, күптән таныш булган һәм әдәбиятыбызда озак еллар яшәп искергән образларны эпигоннарча куллану бер «тир» сүзе белән генә чикләнми.

Менә шигърияттә иң күп кулланыла торган чәчәк образы. Ул мәхәббәтнең мәңгелек бер символы булып образлы фикерләүнең штампланган деталенә әверелгән инде. Әгәр берәр шигырьдә күзгә ялгыш кына «чәчәк» сүзе чалынса, ул шигырьне уку теләге кинәт сүнә, чөнки белеп торасың, сүз егет һәм кыз арасындагы (сирәгрәк ир белән хатын арасындагы) мәхәббәт йә бер-берсеннән суыну хисләре турында булачак. Әгәр дә чәчәк шиңгән булса, алдан ук бераз авыр сулап куярга була, чөнки мәхәббәтләр суынган, беткән, ә чәчәкләр шаулап, нурланып, хуш исләр бөркеп утырсалар — кайгырыр урын юк, эшләр ал да гөл генә. Чәчәк турындагы фикер фигыльнең үткән заман формасында әйтелсә, бераз кызыксыну уяна: ул чәчәк хәзер сулган микән, әллә һаман да гөрләп утыра микән?

...Гариф аңа алып килгән иде
Зәңгәр чәчәкләрен сиреньнең...

*Е.Уткин*

Ул чәчәкләр бирде өзеп-өзеп,
Сөйләсеннәр, ди-ди, хисемне...

*Т.Камалиев*

Кайдан табыйм икән җир гөлләрен,
Тере гөлләр эзлим көз көне.

*Ә.Гайнуллин*

Ал син аны — күңел чәчкәсен.

*Р.Зәкиев*

Чәчәкләргә көн дә сулар сиптең,
Сөюләрең чиктән ашканга...

*И.Фазлуллин*

Чәчәк образына яңалык өстәү җиңел эш түгел, чөнки аның фәлсәфи асылы дистәләгән гасырлар буе кешелек өчен даими. Чәчәк — табигатьнең биологик җимеше һәм аның мәгънәсе кешелек җәмгыятенең үсеше белән турыдан-туры бәйләнештә тормый. Ләкин кеше чәчәктән үзе теләгәнчә файдалана, аны үзе теләгән урында үстерә, аны бүләк итә, кабер өстенә куя, күкрәгенә кадый, такыя итеп башына кия, аның белән дәвалана, агулый, хәтта аны политик байрак итә (Белоянис, кызыл канәфер чәчәге) һәм башкалар, һәм башкалар... Күрүебезчә, халык чәчәктә бик күп мәгънә күрә, ә безнең «Беренче карлыгач» авторларының күбесе аны фәкать бер мәгънәдә генә кулланганнар. Ярар, алар чәчәк образына яңа төсмер кертүне максат итеп куймаганнар ди. Аларның максаты — мәхәббәт хисләрен оригиналь рәвештә күрсәтү булган ди (әгәр дә бусы да максат булмаса, иҗат итеп тору мәгънәсезлеккә дучар була ич!). Тапталган образлар, детальләр белән тапталмаган шигырь иҗат итү, минемчә, мәсьәләгә ниндидер яңа логик алым белән килүне таләп итә, ә андый алым, кызганычка каршы, күренми.

Менә тагын бер штамп. Аңа аңлатма биреп тору артык:

Сиңа булса бары унсигез?

*Е.Уткин*

Ә унсигез — күңелгә.

*Х.Хөснуллин*

Булырсың гел унсигездә!

*И.Фазлуллин*

Унсигез яшь кенә дисең дә!..

*Т.Камалиев*

Мондый мисалларны тагын да китереп булыр иде. Туган җир, туган як, йөрәк, чишмә, яз, бәхет, матурлык, каен, ана һәм башка, һәм башка образлар да яшь шагыйрьләрнең күпчелеге тарафыннан бертөсле үк, бер мәгънәдә диярлек үк бирелгән. Алай гына да түгел, бу бертөслелек безнең шигъриятебездә элегрәк булган бертөслелектән дә аерылмый диярлек.

«Беренче карлыгач»лар иске образларны, күнегелгән детальләрне үстереп-баетып торуны кирәк тапмыйча, турыдан-туры яңа образ-фикерләр алып килгәннәрдер.

Абсолют яңа образ-фикерләр тууы фәннәрдәге яңа ачышларга, социаль үзгәрешләргә, эстетик һәм этик критерийларның хәрәкәтенә, моральнең чикләренә бәйле. Ягъни яңа ачышлар, социаль үзгәрешләр, эстетика һәм этиканың бүгенге казанышлары кешене тормышка яңача карарга мәҗбүр итәләр. Хезмәт процессларының һаман да автоматлаша баруы, кибернетиканың көннән-көн тормышка, аңга ныграк үтүе һәм башка бик күп казанышлар Җир һәм Кеше, Кеше һәм Галәм арасындагы мөнәсәбәтләргә җентекләбрәк карарга боералар һәм мөмкинчелек тә бирәләр. (Хәзергә моннан да зур мөнәсәбәтләр бармы икән?!) Бу мөнәсәбәтләрне белмичә, аларга конкрет үз карашыңны булдырмыйча, бүген сәнгать белән шөгыльләнү дилетантлык булыр иде, чөнки фән, хәзер тормышка гади генә үтеп керү белән чикләнмичә, кешенең мөмкинчелекләрен, аның сыйфатларын үлчи торган бизмәнгә әйләнде.

Менә Җир һәм Кеше мөнәсәбәтен чагылдырган берничә таныш фикер: Җир — кешене туендыручы, киендерүче һ.б.; кеше — Җирнең хуҗасы; кеше — Җирне эксплуатацияләүче; кеше — Җир табигатен тәртипкә салучы гына; Җир — кешене тезгендә тотучы; кеше — бөҗәк, җәнлек, кош кебек үк Җирнең бер көчсез баласы һ.б. (Боларны шигърият нигезендә ята торган бердәнбер фикерләр дип кабул итмәскә кирәк. Алар мисал өчен генә бирелә.)

Бу фикерләрнең кайсына булса да шагыйрьләрчә инану тормышны шул яктан тирән итеп өйрәнергә мөмкинчелек бирә, ә бусы үз нәүбәтендә тормышның гадәти күренешләрен дә яңача итеп күрергә, таныш вакыйгалар нисбәтендә яңа халәт сизәргә ярдәм итә. Әгәр инанган фәлсәфи фикерең өр-яңа булса (мәсәлән, кеше — Җир баласы түгел һәм аның табигате Җир табигате кануннарына күп очракта капма-каршы,ди, шул нигездә туган образ-фикерләрең дә (детальләре иске булуга карамастан) яңа һәм үзенчәлекле була. Ә «Беренче карлыгач»ның күпчелек авторларында тормышны фәлсәфи яктан конкрет өйрәнү сизелми һәм яңа образ-фикерләр дә күренми. Тормышны белү ул, минемчә, әйберләрне, профессияләрне, аерым шәхесләрне, аларның ничек яшәгәннәрен, нинди төзелешләрдә йә колхозларда эшләгәннәрен генә белү түгел. Болар тормышны өйрәнүдәге бик вак детальләр генә. Менә шул вак детальләр арасындагы мөнәсәбәтләр асылына төшенү, анда зуррак гомумзакончалыклар күрә алу, ул закончалыкларның кайсына киртә куярга, кайсына үсәргә ярдәм итәргә тырышу — бу инде тормышны тирәннән белү. «Беренче карлыгач»ларның кайберләре, кызганычка каршы, әнә шул вак детальләрне генә җентекләп белүдән ерак китә алмаганнар.

Ә хәзер «Беренче карлыгач»ларның форма үзенчәлекләрен карыйк. Моның өчен яңалыкны, оригинальлекне дәгъва итми торган бер мисалга тукталыйк.

**ҮКЕНҮ ХАТЫ**

Юлдан олау узды... Шул олаудан
Бер уч печән алып иснәдем.
Яшәртә ул мине, гел яшәртә,
Көчәйтә ул якты хисләрне.

Йөрәгемдә җылы дулкын булып
Ташкынланган чагы хисләрнең...
Тоеп торам бөтен йөрәгем белән:
Сагыну тулы хатлар көтәсең.

Күпме көннәр, күпме еллар үтеп,
Күпме алсу таңнар атмады...
Нәрсә әйтим, нәрсә языйм сиңа,
Агачларда яфрак саргайды.

Кичерсәнә дип тә әйтә алмыйм,
Һай, бу хәлләр бигрәк әрнетте.

Баш ияргә кушты афәт җиле,
Иңбашымнан тотты селкетеп...

Иреннәрем исемең пышылдыйлар,
Белсәң ничек күңелем тулганны!
Эх, хәзерге акыл булса ул чак,
Дисвительни җүләр булганмын.

Чүкеч тотып сөялләнгән саен
Көче арта икән кулларның...
Сизәсеңме, печән иснәдем дә
Сиңа инде хат та юлладым...

Бу шигырьне шушы килеш «Беренче карлыгач»тагы бер китаптан да табып булмый, чөнки ул — җыелма шигырь, ягъни һәр ике юлы конкрет бер авторныкы һәм аларга бернинди үзгәреш тә кертелмәгән. Дөрес, бу мисал — ясалма эксперимент кына, ләкин ул «Беренче карлыгач»лар турында, минемчә, шактый объектив фикерләр әйтергә ярдәм итә. Күренгәнчә, шигырьнең ритмик агышы шактый шома һәм бу безнең авторларның фикер ягыннан гына түгел, бу очракта образның ритмик төзелеше ягыннан да игезәкләр икәне турында сөйли. Ул чыннан да шулай — китаплардагы барлык шигырьләр диярлек 8–7, 10–9 иҗекле юллар белән язылганнар, әйтерсең лә җир йөзендә башка шигъри калыплар беткән. Әгәр дә ул шулай булмаса, алда күрсәтелгән экспериментны эшләү мөмкин булмас иде.

«Беренче карлыгач»тагы шигырьләр үзләрендәге сурәтләү чараларының гаять ярлы булулары белән дә шаккатыралар. Кая киткән Тукайлар алып үстергән, безнең шигъриятебезгә шәрык колориты биргән моноримнар? Дәрдмәнд шигырьләрен кабатланмас мәгънә белән баетырга ярдәм иткән ассонанслар, аваз язымнары кая югалган? Кая Дәрдмәнднеке кебек катлаулы рифмалашуга корылган оригиналь строфалар?.. Бу сорауларны әле тагы да дәвам итеп булыр иде. Гади чагыштыру, сирәк-мирәк кенә сынландырулар һәм метафоралар куллану авторларны тулаем канәгатьләндерә булса кирәк, ләкин алар зәвыгы көннән-көн нәзберекләнә барган укучыларны канәгатьләндермиләр дип уйлыйм.

Тагын бер әһәмиятле мәсьәлә — шигъри жанрларның бертөрлелеге. «Беренче карлыгач»тагы барлык әсәрләрне бары ике-өч кенә жанр төренә бүлеп була: шигырь, поэма, җыр. Соңгы икесе — ике-өч кенә. Жанрларга ярлы булу әдәбият өчен бик күңелсез вакыйга, чөнки ул шигъриятебезне бертөслелеккә, бертөрлелеккә алып бара. «Беренче карлыгач» алып килгән язда пародияләр, бәетләр, элегияләр, романслар, сонетлар, газәлләр, касыйдәләр һәм башка, һәм башка жанрлар һәм шигырь төрләре очратырга теләгән шигъриятебезнең өметләре акланмады. Опера, оратория, кантата, музыкаль драма йә комедия либретточылары да, кызганычка каршы, «Беренче карлыгач» потенциалында күренми.

Шулай итеп, беренче нәтиҗәләргә дә килеп җиттек кебек. «Беренче карлыгач»ның күпчелек авторлары үзләренең образлы фикерләүләре, шигъри алымнары, жанрлары, шигырь формалары, хәтта темалары белән дә бер-берсеннән әллә ни аерылып тормыйлар. Алай гына да түгел, бу бертөслелек әдәбиятыбызда элегрәк булган бертөслелектән дә аермалы була алмаган. Бу инде әлеге нәтиҗәнең сәбәпләре турында уйланырга мәҗбүр итә. Барлык авторларга да хас сәбәпләрнең берсе, минемчә, шигъриятебезнең үткән юлын бизмән итеп үз иҗатыңны бәяләмәү һәм шуның аркасында әдәбият мәйданында үзеңнең кем икәнеңне шәйләп бетермәү, үз максатыңны әдәбият максаты белән бәяләмәү. Ә әдәбиятның максаты — һаман да яңа әсәрләр, яңа жанрлар, яңа алымнар, формалар, яңа фикерләр һәм проблемалар белән тулыландырып тору һәм укучыны баету.

Яшьләр иҗатына профессиональ тәнкыйтьнең якын килә алмавы да әлеге игезәкләнү процессының тирәнәя баруына ярдәм итә. Тәнкыйть якын килә алсын өчен, һәр яшь автор, даими рәвештә матбугат битләрендә басылып, үзенең үсеш тенденциясен мөмкин кадәр тулырак күрсәтергә тиеш. «Татарстан яшьләре»ндә берәр шигырь белән, «Казан утлары»нда ике-өч шигырь белән елына бер күренеп алу гына әлеге таләпкә җавап бирә алмый. Яшьләрнең әдәби журналлары, альманахлары, газеталары булмау аларның шагыйрь булып үсү процессын озынайта һәм «табигый сайланыш» («естественный отбор») дигән табигать законына үз эшен әдәбият мәйданында башкарырга ирек бирми. Нәтиҗәдә — бертөслелек, игезәклек.

* * *

Хәзер «Беренче карлыгач»ка башка яктан күз салыйк.

Кассета эченә тупланган шагыйрьләр бер-берсенә бик охшаганнар дисәк тә, алар китап тышлыклары кебек үк охшаш түгел. Кассета ундүрт китапка бер кыяфәт биреп ундүрт шагыйрьне тагын да төссезләгән.

Кассетаның киләчәге турында уйлансаң, аның тагын бер «хикмәте» бар икәнен сизәсең. Ул менә нидән башлана: бер яки ике егермешәр битле брошюраны гына кассетада чыгарып булмый, «Беренче карлыгач»ны кассетада дәвам итәр өчен шагыйрьләр запасының зур булуы кирәк. Ә ел саен ундүрт йә ун әдәбиятка кирәкле шагыйрь туып тора алмый. Шулай булгач, «Беренче карлыгач»ның чираттагы чыгарылышын өч-дүрт ел көтәргә, йә кассетаны һәр ел чиле-пешле шигырь китаплары белән тутырып чыгарырга кирәк. Өч-дүрт ел көтү — ике-өч талантлы яшьнең иҗади үсешен тоткарлап тору (дөньяга чыккан әсәр, бигрәк тә китап — бик зур иҗади стимул), ә ашыккан очракта — шигърият өстәлә полуфабрикат чыгару һәм укучыларыбызның болай да аптыраште калган зәвыгын тагы да аңлаешсызрак хәлгә китерү.

Перспективадагы ике мөмкинчелекнең икесе дә әдәбиятыбызга файдасыз. Әгәр дә «Беренче карлыгач»-ны кассетадан арындырып рубрика рәвешендә генә дәвам иткәндә («Мои первые книжки» рубрикасы сыман), йә булмаса, аның бераз өлешен генә яхшыртылган кассетада (бүләк өчен) калдырсаң, файдадан гайре бернәрсә дә булмас иде һәм һәр талантлы яшь шагыйрь тулырак килеш әдәбият мәйданына чыга барып укучыларга да тизрәк ирешер иде.

«Беренче карлыгач»ның культурасына кагылышлы берничә сүз дә әйтәсе калды. Басылып чыккан китапларның эшләнеш культурасы турында матбугатта күптән инде бик әйбәтләп сөйләшергә вакыт.

Борис Слуцкий «Литературная Россия» газетасындагы бер мәкаләсен (1967 ел, март, № 10) болай башлый: «Шагыйрьнең беренче китабы өчен өч нәрсә зарури: яхшы фотография, яхшы биография һәм яхшы исем. Болардан тыш — яхшы шигырьләр дә». «Беренче карлыгач»ны шагыйрьләрнең фотографияләре һәм биографияләре белән чыгарып нәшрият бик дөрес иткән. Китапларның исемнәре дә шактый уңышлы сайланган. Ләкин алда әйтелгәннәр генә китапны культуралы итеп бетерә алмый әле.

Менә «Беренче карлыгач»ның тартмасы — кассетасы. Ул төрү кәгазе вазифасын үтәргә генә эшләнмәгән, аның бурычы — бу ундүрт китапны еллар дәвамында «давыллардан-яңгырлардан» саклау, аларны берләштереп тору. Шулай булгач, ул нык калын картоннан йә башка материалдан эшләнгән булырга тиеш иде. Икенчедән, кассета гомумән дөрес эшләнмәгән. Кеше кулы, әгәр дә ул сулагай булмаса, тартманы сул кулы белән тота да аның эчендәге әйберне уң кулы белән ала. Әйберне салу процессы да шулай ук башкарыла. Ә «Беренче карлыгач» кассетасы кирегә эшләнгән, ягъни аның авторы кеше кулының еллар, гасырлар буе алган күнекмәсен истә тотмаган. Бу әйткәннәрне кайберәүләр вакчыллану дип тә кабул итәрләр, ләкин шунысын да онытмаска кирәк — хәзер инде чүкеч сабын да, ишек тоткасын да, станокларны да бүгенге эстетик таләпләргә таянып эшлиләр. Ә китап гади хезмәт коралы гына түгел, кешеләргә культура, белем, зәвык алып килә торган бөтен бер система, һәм ул система һәр яктан да камил булырга тиеш. Кассетаның соңгы стенасына күз салыйк: тәртипсез бүлгәләнгән набор белән анда ундүрт авторның фамилияләре җыелган, ә редакторныкы, художникныкы, художество редакторыныкы һәрберсе аерым юлда, шуның өстенә сирәгәйтелгән набор белән, — әйтерсең лә «Беренче карлыгач»ның төп хуҗалары алар өчәү.

Ә хәзер китаплар хакында. Аларны өстәлгә җәеп салсаң, иң беренче тәэсир: бу — авыл хуҗалыгы культураларын үстерүдә тәҗрибә уртаклашу нияте белән чыгарылган брошюралар сериясе. Шигырь җыентыклары өчен, аларның авторлары өчен бу бик күңелсез хәлдер.

Китапны алгач ук беренче булып күз карашын өткән нәрсә — китапның ике этажлы паспорты. Өске катта «газетная линейка» дигән кайма белән әйләндереп алынганы, аста шул ук паспорт, ләкин каймасыз. Бу күренеш шигырь китабына хас нәфислекне алдан ук үтереп куя.

Шигырьнең формасы бар, эчтәлеге бар һәм аның тәне, гәүдәсе дә бар. Кульязма шигырьне машинкада бастырып алсаң, ул ничектер әйбәтләнеп, төзләнеп киткән кебек була. Бу бик гыйбрәтле психологик момент һәм аны полиграфиядә беркем дә читләтеп үтми. Эш шрифтта. «Беренче карлыгач»ның шрифты бик тупас һәм ул шигырьләрнең болай да кабарынкы гәүдәсен Гогольнең Собакевичы өстәленә әверелдерә. Шуның өстәвенә ул шигырьләр бик кысан урнашканнар: өсләрендә — алгы биттә тәмамланырга өлгермәгән шигырьнең коерыгы, асларында — яңа башланган шигырьнең маңгае. Китапларның форматы экономик яктан бик җайлы сайланган булса да, эстетик яктан уңышсызрак...

Эчтәлекнең, паспортның йә китапның алдында, йә соңында булырга тиешлеге, заставкаларның һәр китап өчен аерым булырга тиешлеге, шигырь исемнәренең заголовочный шрифттан җыелырга тиешлекләре, эпиграф һәм багышлау шрифты шигырь шрифтыннан аермалы булырга тиешлеге турында әйтеп китү дә бик җиткәндер.

Әлеге җитешсезлекләргә укучыларның игътибар итмәве дә мөмкин. Ләкин бу әлеге җитешсезлекләрнең җаваплылыгын һич кенә дә киметә алмый, чөнки укучыларның эстетик таләпләрен, зәвыкларын тәрбияләүне күз алдында тотканда алар гафу ителмәслек факторларга әйләнәләр.

* * *

«Беренче карлыгач»ның дөньяга килүе, һичшиксез, күңелле вакыйга, ул изге максат белән эшләнгән. Аның турында, бәлки, шушы язган хәтле мактау сүзләре язып булыр иде. Ләкин эш анда түгел, эш шагыйрьнең беренче китабын беренче тапкыр чыгару принцибында һәм бу принципның әдәбиятыбызга нәрсәләр бирүендә. «Беренче карлыгач»ның беренче чыгарылышына эшнең әле әйткән асылы күзлегеннән карасаң, шуны әйтеп була: кассетада килеш ул яшь шагыйрьләрне бик чикләгән һәм аларның мөмкинчелекләрен тулы итеп күрсәтә алмаган.

Ә үзе турында үзе ул болай әйтә кебек:

«Хөрмәтле иптәшләр! Мин канатларыма төяп килеп шигърият кырыгызга быел бик күп ясмык чәчтем. Арада берәр бөртек солы, арыш, карабодай һәм бодай бар... Алдагы көзләрегез турында үзегез уйлагыз!»

# Яңа офыклар

*(50 нче һәм 60 нчы еллар яшь шигърияте турында)*

**Рафаэль Мостафин.** Соңгы елларда безнең яшь шигъриятебез хакында сөйләшүләр ишәйде. Кинәт кенә үсеп киткән яшь шигъриятебез укучылар, әдипләр, тәнкыйтьчеләр игътибарының алгы сызыгына чыкты.

«Казан утлары» журналының һәр саны диярлек яшьләр иҗатына зур урын бирә, яшь шагыйрьләр катнашы белән үткәрелгән әдәби кичәләр, концертлар һәрвакыт уңыш казана тора...

Бу елларда хәтта яңа атама, яңа термин да барлыкка килде: шагыйрьләребезнең иң яшь буынын без «дүртенче дулкын», «дүртенче буын» дип исемлибез.

Беренче дулкын — Шәүкәт Галиев, Гамил Афзал, Хисам Камал, Илдар Юзеев, Рәшит Гәрәй — шигърият мәйданына 50 нче елларның башында дисәк тә ярый, уртасында дисәк тә ярый, килеп керделәр. Бу дулкын көчле һәм үзенчәлекле иде. Һәм бу буын шагыйрьләренә озак еллар «яшьләр» булып саналып йөрергә туры килде. Сәбәбе — аларга алмашка шактый озак яшь көчләр килми торды.

Икенче дулкын — Әхсән Баянов, Роберт Әхмәтҗанов, Шамил Мәхмүдов, ягъни шигърияткә 60 нчы еллар башында килүчеләр.

Алтмышынчы еллар урталарында безнең шигъриятебезгә өченче дулкын килеп кушылды: Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Ренат Харисов, Рөстәм Мингалимов һәм башкалар, ягъни бүгенге яшь шигъриятнең төсен дә, асылын да билгеләүче үзенчәлекле шагыйрьләр төркеме.

Әле күптән түгел, алтмышынчы елларның ахырында гына, үзләреннән алданрак килүчеләрнең үкчәләренә баса-баса, шигъриятебезгә дүртенче дулкын керде. Ул — Зөлфәт Маликов, Мөдәррис Әгъләмов, Эдуард Мостафин һәм башкалар.

Алдан ук ике искәрмә ясап куясым килә: беренчедән, мин, барлык исемнәрне санап тормыйча, теге яки бу буынның иң үзенчәлекле, шул буынның йөзен ачыграк билгеләүче шагыйрьләрне генә атадым: икенчедән, «дулкын»нарга бүлү — шартлы рәвештә генә бүлү һәм ул шагыйрьләрнең әдәбиятка килүенең хронологиясен генә аңлата. Ә шагыйрьләр арасындагы субүләр тасма һәрхәлдә яшь буенча билгеләнми, чөнки төрле буын язучылары арасында һәм рухи, һәм стилистик якынлык була алган чакта бер үк буын язучылары арасында боларның булмавы да мөмкин.

Әмма дулкыннар күз алдында һәм аларның (бигрәк тә өченче һәм дүртенче дулкыннарның) әдәбиятка нинди яңалык алып килүләрен, үзләреннән элегрәк килгәннәрдән кайсы яклары белән аерылып торуларын, уртаклыклары нидән гыйбарәт икәнен ачыклыйсы килә.

Минем күзәтүем буенча, соңгы ике буын алдынгыларга караганда стиль, ритм, тойгыларның күптөрлерәк булуы белән аерылып тора. Моны мин һич тә 50 нче еллар яшь шигъриятенә шелтә йә үпкә рәвешендә әйтмим. Ул вакытта заман башка булган. Бернәрсә дә юк җир-җирлектә бар була алмый. Шагыйрьне аңлар өчен аның нәрсәгә таянганын да, нинди традицияләрдә тәрбияләнгәнен дә, нәрсәне үстерергә тырышуын да күрергә кирәк. 50 нче елларда килгән яшь шагыйрьләрнең таяныр җирлеге, минемчә, өченче, дүртенче дулкыннар җирлегенә караганда таррак булган.

50 нче еллар яшь шагыйрьләре, кагыйдә буларак, бер әдәби «алла»га — Һади Такташка табындылар. Аларның кайберләрендә (мәсәлән, И.Юзеевның башлангыч чор шигырьләрендә һәм поэмаларында) Такташ интонацияләре үзләрен нык сиздерә, ә икенче берәүләренең иҗатларында ул интонацияләр алай ук күзгә бәрелеп тормасалар да, аларны яшереп булмый иде. Шуның өстәвенә бу буын шагыйрьләренең укытучылары да барысына да уртак иде — Сибгат Хәким. Заманында тәнкыйтьчеләр И.Юзеевны да, Ш.Галиевне дә, Рәшит Гәрәйне дә «Хәким мәктәбе» шагыйрьләре дип атадылар. Хәзерге көндә, билгеле, алай дип әйтеп булмый — Сибгат Хәкимнең укучылары күптән инде үзләренә генә хас шигъри сыйфатлы шагыйрьләр булып җитештеләр һәм кайбер юнәлешләрдә остазларын узып та киттеләр. Ә иҗатларының башлангыч чорында алар күп мәсьәләләрдә бер-берсенә бик якыннар иде һәм бу якынлык, бертөслелек, минемчә, җирлекнең барысы өчен дә уртак булуы белән аңлатыла.

**Ренат Харисов.** Югарыда әйтелгән фикерләр белән килешәм, ләкин бер-ике өстәмә белән. Әдәби «алла»ның да, остазның да ул еллар яшь шагыйрьләре өчен уртак булуы бертөслелек файдасына уйнаган. Әмма ул елларда, минемчә, авторитетлар Такташ белән Сибгат Хәким генә булмаган. Мәсәлән, Әхмәт Фәйзинең бик үзенчәлекле, көчле, акыллы, күпкырлы шигъри авазы да әдәбият мәйданында яңгыраган һәм күп яшь шагыйрьләрнең күңелен үз ягына караткан. Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев иҗатларындагы сатира, юмор Әхмәт Фәйзи талантының бер тармагына барып тоташкандыр әле. Сатирачы буларак, Әхмәт Фәйзи Тукайлардан, Бабичлардан, Такташлардан килгән традицияне дәвам иткән һәм шушы дәвам итү, үзе традициягә әверелеп, Ш.Галиев, Г.Афзалларның табигать биргән талантларына этәргеч булган диясе килә. Публицист, зур проблемаларны шигырьнең тар юлларына көчәнмичә-нитмичә сыйдыручы Әхмәт Фәйзинең дә (бу — шагыйрь талантының икенче тармагы) варислары, дәвамчылары юк түгел. Әхсән Баянов, соңыннанрак — Роберт Әхмәтҗанов иҗатларында Әхмәт Фәйзинең шигъриятенә үз үзенчәлек биргән алымнар — проблемаларны космик киңлек фонына куеп карарга тырышу публицистиканың лиризм белән бик матур укмашуы, шигырьнең һәр юлын образ итәргә теләү бик ачык күренә. Ләкин бу шагыйрьләр Әхмәт Фәйзине кабатламыйлар, аны үзләренчә үстерәләр. Күрәсең, бер үк остаздан да төрле-төрле укучылар чыга ала һәм алар берсен берсе һич кабатламыйлар. Берничә шагыйрьнең бер-берсенә охшашлыгы, бертөслелеге остазларының уртак булуыннан да элегрәк өйрәнчекнең талантына, иҗади максатларына, иҗади кыюлыгына күбрәк бәйледер. Әгәр дә өйрәнчек үзенең шигъри мәхәббәтеннән өстен була алмый икән, ул остазын кабатлаудан уза алмаячак. Күрәсең, 50 нче еллар яшь шагыйрьләре Такташ шигыренә, аның алымнарына булган мәхәббәтләреннән арынмаган булганнар.

**Рафаэль Мостафин.** Бу төзәтмәне, төгәлрәк итеп әйтсәк, минем тезисыма булган әһәмиятле өстәмәне кабул итәм. Күп нәрсә талантка бәйле дигән фикер белән дә килешәм. Сәләтсез шагыйрь бик ныклы, бай җирлектә дә кызганыч эпигон булып кала, ә үзенчәлекле талант, киресенчә, үзе әдәби юнәлеш тудыра, үзе,

Тукай, Такташ, Җәлил кебек, яңа талантлар үсү өчен җирлек була. Шунысын да әйтергә кирәк, талантның әдәбиятка килүен тормыш үзе һәм әдәбиятның үткән юлы, традицияләре әзерли. 50 нче еллар шагыйрьләре, үзләреннән алдан килгән өлкән буын белән бергә, бүгенге яшь шагыйрьләр үсеп чыгасы әдәбият басуын тәрбияләделәр. Юлларны бер үк этәрелү ноктасыннан башласалар да, вакытында бер-берсенә шактый охшасалар да, беренче дулкын шагыйрьләренең һәрберсе үзенчәлекле иҗат юлы белән үсеп китте. Шәүкәт Галиев, мәсәлән, лирик булып башлап, безнең шигъриятебезне нечкә һәм акыллы юмор белән баетты. Аның шигырьләренең йөгерек агышы, цикл барышы (кайчак шул җиңеллек эчтәлеккә үтеп керсә дә), һәр сүзнең җегәрле булуы, һәр шигырьнең матур, төгәл эшләнеше күңелемә хуш килә. Хисам Камалов — лиро-эпик пландагы шагыйрь. Ул үзенең поэмаларында шактый катлаулы социаль һәм психологик проблемаларны гәүдәләндерергә тырыша. Гамил Афзал — көчле сатирик. Шул ук вакытта ул тирән лирик та. Аның иң яхшы шигырьләре сүзнең чын мәгънәсендә шедеврлар. Ләкин, кызганычка каршы, саф алтын белән янәшәдә үк аның иҗатында буш, җиңел токымнар бар. Илдар Юзеевның поэмалары гадәттә романтик аһәң белән өртелгән була. Соңгы елларда шул романтикага бик табигый рәвештә драматик киеренкелек тә килеп кушылды. Мисал итеп аның «Соңгы сынау» поэмасын күрсәтергә була. Ә менә Рәшит Гәрәйдә үзгәреш, башкалар белән чагыштырганда, кимрәктер. Ул үзенең башлангыч чорында бик матур ялтырап китсә дә, соңыннан үсеш темпын бик нык әкренәйтте һәм иҗади активлыгын да киметте.

Икенче дулкынның да татар шигъриятенә керткән өлеше шактый матур. Әхсән Баянов иҗатында без тормышның катлаулы сорауларына яна-яна җавап эзләүче һәм үз буынының кайгы-шатлыкларын барлаучы лирик герой белән очрашабыз. Үзенең башлангыч чорында шәп җыр текстлары һәм лирик шигырьләр биргән Роберт Әхмәтҗанов соңгы елларда үзенең иҗади күтәренкелеген киметә төште кебек. Безнең тәнкыйтебез тарафыннан тиешенчә бәяләнеп җитмәгән шагыйрь Шамил Мәхмүдов шигъриятебезгә үзенчәлекле фәлсәфи лирика алып керде, яшьләрдән беренче буларак, яңадан ак һәм иректле шигырьне терелтеп җибәрде, онытыла язган мәдхия формасын яңа җирлектә үстерде. Шулай итеп, өченче һәм дүртенче дулкын шагыйрьләре шигъриятькә килгәндә, анда инде күптөрле тармаклар, стиль үзенчәлекләре, шигырь жанрларының бай төсләре бар иде. Өлкән буын шагыйрьләре Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Нәби Дәүли, Әнвәр Давыдов, Зыя Мансур, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗиевлар да бик актив эшләгән чор иде бу. 90 нчы елларның урталарында Дәрдмәнд, Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиев кебек онытылганрак шагыйрьләр дә тулырак һәм объективрак бәһа алдылар. 53 нче елда беренче мәртәбә Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» басылып чыкты. 50 нче елларның икенче яртысында шигъриятебезнең зур остасы булган Хәсән Туфан яңадан әдәбият мәйданына кайтты. Бу үзгәрешләрне һәм яңалыкларны сиздерергә, кабул итәргә шактый вакыт кирәк булуы һәм шул яңалыклар 60 нчы елларда килгән яшь буын иҗатында шактый яңа һәм матур яңгыраш таптылар.

Күпмилләтле совет шигъриятендәге гомуми хәрәкәт тә үз йогынтысын ясамады түгел, чөнки яшь шагыйрьләр Э.Межелайтис, Р.Гамзатов, Н.Асеев, К.Кулиев, Е.Евтушенко һәм башкалар иҗатына да игътибар итми кала алмадылар. Дөнья шигъриятендәге алдынгы хәрәкәткә — Н.Хикмәт, П.Неруда, Г.Лорка, У.Уитмен, П.Элюар иҗатларына һәм япон шигъриятенә игътибар артты. Боларның барысы да яшьләр иҗатында чагылыш таптылар.

Шулай итеп, 60 нчы еллар яшь шигъриятендәге күптөрлелек, күптөслелекнең сәбәпләрен иҗади җирлекнең киңәюеннән, традицияләрнең баюыннан эзләргә кирәктер.

**Ренат Харисов.** Дәрдмәнднең, Бабичның, Сәгыйть Рәмиевнең яңадан әдәбият мәйданына кайтуы, һичшиксез, безнең шигъриятнең үсешенә матур этәргеч ясады. Хәлбуки алар иҗатындагы кабатланмас яклар, ягъни Дәрдмәндне Дәрдмәнд иткән җегәрле сүзләр, ювелирларча башкарылган форма һәм тирән фәлсәфә шигърияте, Бабичны Бабич иткән ниндидер илгизәр рухтан, тормышның асылына үтеп керү сусавыннан хасил шигърияте, Сәгыйть Рәмиевнең бунтарь романтикасы татар әдәбиятына һәрвакыт йогынты ясап торган, аларның иҗаты татар шигъриятен үстерүдә һәрвакыт өлге булып торган диясем килә минем. Шулай булмавы, минемчә, мөмкин дә түгел, чөнки һәр яулаган әдәби казаныш, һәр күтәрелгән биеклек мәңгелек булып кала һәм аларга, нинди генә оста булуына да карамастан, телисеңме-теләмисеңме эледән-әле йә борылып, йә бүрегең төшеп киткәнче каерылып багарга туры килә. Кол Гали, Утыз Имәни, Кандалый, Тукайлар шундый биеклеләр түгелмени? Ләкин ул биеклекләргә биеклек итеп тә, иҗат мәктәбе итеп тә карау мөмкин. Күрәсең, 50 нче елларда килгән шагыйрьләр Дәрдмәнд, Бабич, Сәгыйть Рәмиев мирасларын иҗат мәктәбе булудан бигрәк иҗат биеклеге итеп караганнардыр. Моны мисаллар белән дәлилләү бик кыен, чөнки бу — тәфсилләп тикшерүне сорый торган эш.

Шунысын да әйтергә кирәк, 60 нчы елларда килгән яшь шагыйрьләрнең укытучылары, иҗат мәктәпләре, җирлекләре бай һәм күпкырлы булып та «бертөслелек» чире белән авыру юк түгел. 1967 елда чыккан «Беренче карлыгач»лар аерым уңышлы китапчыклар булуга да карамастан, моңа ачык дәлил. Күрәсең, бу чир белән беренче нәүбәттә табигать тарафыннан бирелгән талантлары чамалырак шагыйрьләр авырыйлар, ул чирне алар тудыралар. Ә бүгенге шигъриятнең күптөслелегә беренче чиратта талантлары шик уятмый торган шагыйрьләр килүендә. Шуның өстәвенә аларның борылып карарга юллары да шактый төзек, ягъни татар шигъриятенең үткәненнән алып бүгенгесенә кадәр өзек бөжралар, төшеп калган буыннар юк дисәк тә була. Боларның барысы да яшь шагыйрьләргә үзләрен тиз табуда нык ярдәм итә. Ә үз-үзләрен тапкан шагыйрьләрнең бер-берсеннән аерылып тормый хәле юк! Н.Хикмәт, У.Уитмен, П.Неруда, Г.Лорка, хокукы йә талантларыннан бигрәк хәзерге яшь шагыйрьләрнең күптөслелегенә татар шигъриятенең әнә шул ачыклана төшкән, төзекләнгән традицияләре күбрәк йогынты ясады димәкче булам. Шигъри алымнарыбызның, образлы фикерләү ысулларының байлыгын, гүзәллеген күрсәтеп бирүдә Нәкый Исәнбәтнең мәшһүр өч томы мә-

кальләре дә, Г.Ибраһимов исемендәге институт чыгарган «Татар халык җырлары» да, Х.Госманның «Татар шигыре» дигән хезмәте дә яшьләр өчен бик вакытлы туган булышчылар булдылар, шигъриятебез традицияләренең асылына үтеп керүдә юлны җиңеләйттеләр. Ак шигырь, мәсәлән, минем өчен аңлашылып җитми торган күңелгә ятрак форма иде. Татар халык җырларында ак шигырь элементлары йә шигырьнең һәр өлеше өчен аерым ритмик төзелеш очраткач, ак шигырь дә, иректе шигырь дә минем өчен ачылып, үз булып китте. Мәсәлән:

Туган гына әтәвем,
Туган гына әнәвем,
Җиде бала эчендә
Ят күргәнең мин булдым.

И әтәвем, әнәвем,
Мине сатып ни алдың?
Мине сатып ни алдың?
Ярты тустаган бал эчтең!

Менә тагын:

Тиңдәш кенә алашам,
Мине тартып килгәндә
Колмактан җиңел булдыңмы?
Мине ташлап китәсең,
Таштан авыр булдыңмы?

Ах, алашам, алашам,
Тартып килдең, тартып кит,
Таштан авыр мин булдым,
Колмактан җиңел син булдың...

50 нче һәм 60 нчы еллар яшь шигъриятен Такташлар, Туфаннар яшь шагыйрь булып йөргән заманнар белән дә чагыштырып алу кызык. Кутуйлар, Такташлар, Туфаннар өчен ул чакта татар шигъриятенең традицияләре төзек булган. Тормышның рухи, киеренкелеге дә ашкынучан, көчле булган — шатланып, көрәшеп, зур күтәренкелек белән яңа тормыш, яңа ил, яңа социалистик сәнгать корган вакыйга бит. Ә 50 нче елларда тормышның киеренкелеге, күрәсең, йомшарган булган, дөресрәге, ул барлык тулылыгы белән шигърияткә үтеп керә алмаган. Ә 60 нчы елларда, фән-техника революциясе киң колач җәйгән чорда, тормышның рухи киеренкелеге дә, традицияләре өзек бөҗралар да шактый ялганды, шагыйрьләрнең аң-белеме үсешенә уңай йогынты ясарлык җирлек тә киңәйде. Ә шагыйрь һәрвакыт үз чорының кыяфәтен күпмедер дәрәҗәдә кабатлап, үз чорына таянып туа. Менә шуның өчен Такташлар, Туфаннар заманында яшь шигърият күптөсле булган, 50 нче елларныкы — бертөслерәк, ә 60 нчы елларныкы — яңадан күптөсленәнде. Күрәсең, хәзерге көннәрдә бүгенге, яңа җирлектә 30 нчы еллар әдәби күтәрелеше кабатлана.

**Рафаэль Мостафин.** Шулай итеп, мәсьәләнең бу ягына карата без бер фикердә торабыз — бүгенге яшь шигъриятнең үсешен, күтәрелешен, аның күптөслелеген, стиль үзенчәлекләренең күптөрлелеген безнең татар әдәбиятының, күпмилләтле совет әдәбиятының һәм дөнья әдәбиятының хәрәкәте тудырды. Ә хәзер шушы шигъриятнең кайбер сыйфатларын билгеләп карыйк. Бу гади һәм җиңел эш түгел, чөнки шигъри шәхесне ниндидер системага салып карау мөмкин булмаганрак эштер. Равил Фәйзуллин һәм Тәүфикъ Камалиев бер буын шагыйрьләре, бер үк җирлектә үсеп киләләр, әмма шигърияткә карашлары ягыннан, эстетик принциплары ягыннан алар капма-каршылар. Равил Фәйзуллинның иҗаты ниндидер җепләр белән Әнвәр Давыдовның киеренке, катлаулы иҗатына тоташкан булса, Тәүфикъ Камалиев гадилеккә омтыла, хәер, ул гадилек кайвакыт беркатлылыкка әверелеп китми.

Барыбер, 60 нчы еллар яшь шигъриятенең иң үзенчәлекле шагыйрьләренә карап, ниндидер нәтиҗәләр чыгарып, бу шигъриятнең гомуми йөзен билгеләп була. Яңа буын шагыйрьләренең иң зур казанышлары, минемчә, татар әдәбиятында интеллектуальлекне яңадан кайтаруда һәм аны үзләренчә тирәнәйтүдә. Бу күренешне мин һич тә «модерн»га, үтә яңалыкка, формаль эзләнүләргә мөкиббән китеп иярү дип карамыйм. Интеллектуаль шигърият беренче нәүбәттә фикер шигърияте, уйланучы, эзләнүче шигърият. Ул XX гасырның фәнни һәм фәлсәфи казанышлары белән ихлас күңелдән тигезләшергә тырыша.

Әгәр дә 50 нче еллар шигърияте, гомумән алганда, хикәяләү, озынсүзлелек белән чирләсә, 60 нчы еллар яшь шигъриятенә бу инде хас түгел. 50 нче елларның шагыйрьләре инерция буенча авыл укучысына йөз тотыбрак иҗат иттеләр булса кирәк. Хәзер шул авыл укучысы да бик үзгәрде. Радио, телевидение, газета-журналлар аның эстетик зәвыгын заманга хас итеп тәрбияләүдә зур уңышларга ирештеләр. Фольклор традицияләренә генә таянып иҗат ителгән әсәрләр инде авыл укучысын да канәгатьләндереп бетерә алмый.

Билгеле, «интеллектуальлек» дип кенә яшь шигъриятнең кайбер уңышсызлыкларын да аклап булмый. «Интеллектуальлек» белән кирәгеннән артык мавыгу кайбер очракларда психологик абстрактлылыкка да китерде. Мәсәлән, Равил Фәйзуллинның кайбер шигырьләреннән ниндидер салкынлык, уйлап чыгарганлык күренеп тора. Аларда без кайвакыт үзенең кабатланмас шәхси үзенчәлекләре, йөзе һәм характеры булмаган «гомуми» кеше образын очратабыз. Шундый ук абстрактлаштырылган «гомуми кеше моделен» Шамил Мәхмүдов һәм Рөстәм Мингалимов иҗатларында очратып була. Күрәсең, бу — эзләнү чорына хас «балалык авыруы»дыр. Хәзер инде яшь шагыйрьләрнең күбесе чын шигъриятнең конкрет кеше хисләреннән башка булуы мөмкин түгелен яхшы аңлыйлар. Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким лирикасының иң яхшы үрнәкләре

күрсәтүенчә, хисләрнең һәм образларның конкретлылыгы тормышны тирән итеп күрсәтә алуга да, гражданлык тойгыларының офыгы киң була алуга да комачауламый. Бүгенге яшь шигъриятебез менә шушы юнәлештә үсә дә. Аның диапазоны зурая, офыгы киңәя бара. Шагыйрьләрне тормышның, чынбарлыкның кардиналь социаль-фәлсәфи мәсьәләләре күбрәк һәм тирәнрәк кызыксындыра бара. Шул ук вакытта тормышка, чынбарлыкка үз мөнәсәбәтеңне булдыру, һәрнәрсәгә үз күзлегеңнән карарга тырышу кебек моментлар да көчәя бара — йөрәк аша үтмәгән йөрәккә керми шул ул.

**Ренат Харисов.** «Интеллектуальлек» дигән терминга минем дә бераз тукталып үтәсем килә. Бу сүзне без соңгы елларда шигъриятебезне бәяләгәндә чыннан да еш куллана башладык. Яшьләр иҗатына күз ташлап, без: «Шигъриятебезнең үсеше интеллектуальлеккә таба бара!» — дип куанабыз.

Шигъбрияттәге интеллектуальлек үз эченә төп ике нәрсәне ала: берсе — заманның иң мөһим, катлаулы проблемаларын сыйдырган эчтәлекне, ягъни мәгълүматны, икенчесе — шул мәгълүматны, эчтәлекне ачарга ярдәм иткән образлы фикерләүнең бүгенге көн кешесе аңына лаек булган ысулларын, ягъни формасын. Эчтәлекнең шигърилеген бәяләүдә йөрәк, хис белән беррәттән фәнни дөреслек тә критерийга әверелә. Дөреслеккә туры килмәгән, гайре табигый мәгълүмат корылган шигырь эпитет, метафоралары белән генә матур була алмый. Бу хәл шигырьдән җилбәзәклекне куып чыгара, детальләрдән, образлардан тирәнлек, төгәллек таләп итә. Фикерне тирәнәйтү өчен булмыйча шигырьне купшылатыр өчен генә кулланылган эпитетлар, метафоралар, чагыштырулар һәм башка сәнгать чаралары бу критерий алдында үзләрен бүреге янган карак итеп сизәләр...

Бу фикерне шушында беразга өзеп калдырып, 50 нче һәм 60 нчы еллар яшь шигъриятенең кыяфәтен билгеләп карыйк. Һәрбер яшь шагыйрьгә һәм яшь шигъриятькә документальлек, фактиклык хас. Һәр шагыйрьнең диярлек башлангыч иҗаты тормышның йә кечкенә, йә зур фактларга багышланган шигырьләргә бай. Аларда зур гомумиләштерүләр дә, олы шигъри табышлар да очрату авыр. Бер чорда бу фактиклык шагыйрьләрнең үсмер чагында үтелә, икенче бер чорда әдәбиятка ук килеп керә. Сугыш кайтавазыннан арынып, авылга бер яңа ферма йә клуб салу, электрсаугыч аппаратлар кую, шәһәрнең бер урамында яңа йорт җиткерү, өй кыекларында телевизор антенналарының күпләп күренә башлавы һәм шуңа охшаш күп үзгәрешләр бик зур вакыйга ителеп бәяләнгән 50 нче елларда шигъриятьтә фактиклыкның булуы бик табигый, чөнки боларның барысы да кеше күңеленә бик якын булган, шагыйрьләрне хисләндергән үзгәрешләр бит! Ләкин 50 нче еллар яшь шигърияте, үзенең тормышка якын торуы белән отып та, шул тормышның, вакыйгаларның асылына артык тирән үтә алмавы белән дә оттырды.

60 нчы еллар яшь шагыйрьләре, үзләренә абый тиешле буын тәҗрибәсенә таянып, шул буынның ярдәме белән, фактиклыкны әдәбиятка алып кермәделәр — фактларның, вакыйгаларның асылына үрелеп, аларны ил, халык, планета язмышы, чор язмышы фонына куеп бәяләргә, аларны гомумиләштерергә тырыштылар. Нәтиҗәдә тирәнлек, образлылык, колач ягыннан отып та, алар бераз «абстрактлашыбрак» китеп оттырдылар.

Ләкин шигърият фактиклыктан абстрактлыкка юл тотканда үзенең үсеше өчен мөһим булган берничә табышка очрады һәм үзенә соңгы елларда бик җитешмәгән әлеге дә баягы интеллектуальлек сыйфаты белән баеды. Табышларның берсе — ассоциация, икенчесе — шигъри форманың, калыпның күптөрлеләнүе. Шамил Мәхмүдовның «Юл өстендә кояш»ы, Равил Фәйзуллинның «Ажаган»ы, Рәдиф Гатауллинның «Гөлләр су сорыйлар»ы, Рөстәм Мингалимовның «Эзләр»е, Гәрәй Рәхимнең «Вәгъдә»се төрлесе төрле яктан әнә шул яңару турында сөйлиләр. Дөресен әйткәндә, бер шигъри детальнең йә фикернең укучы аңындагы башка бик күп төрле детальләр, фикерләр белән бәйләнешкә керүе, ягъни ассоциацияләнүе, татар шигыренә элек-электән таныш нәрсә. Ләкин ассоциация шигырьнең, шигъриятнең йөзен билгеләүче казаныш булмыйча, шагыйрьләрнең үзләре дә сизмәстән тапкан уңышлы, тирән шигъри детальләренең ярым очраклы нәтиҗәсе иде. Ә 60 нчы еллар яшь шигъриятендә, бигрәк тә бу шигъриятькә хас үзенчәлекләрне инде 50 нче еллар азагында ук тапкан Шамил Мәхмүдов иҗатында, ассоциацияләү шигъри алымга, сурәтләү чарасына әверелә башлый. Равил Фәйзуллинның, Рөстәм Мингалимовның, Камил Мостафинның, Рәдиф Гатауллинның, Гәрәй Рәхимнең, Шамил Маннаповның күп шигырьләрендә ассоциация коры логик фикерне шигъри фикергә әйләндерә торган төп көчләрнең берсенә әверелә, ягъни шигырь үзенең эчке формасы белән шуңа нигезләнә. Тагы да яшьрәкләрдән Зөлфәт Маликов, Эдуард Мостафин, Разил Вәлиев, Мөдәррис Әгъләмовлар да ассоциацияләүне очраклы гына файдаланмыйча, аны шигырьнең мәгънәсен тирәнәйтүче, офыгын киңәйтүче чара итеп кулланалар. Офык дигәннән — ассоциация чыннан да шигырьнең фикер орбитасын киңәйтә, шигырьне масштаблы итә. Ләкин кайбер очракларда, үзенең орбитасын киңәйтә-киңәйтә, фикер «җирнең» тарту көченнән дә, укучының аңлау көченнән дә ычкынып китә. Ассоциацияләргә нигезләнеп язылган шигырьләрне «су кебек эчү», йә булмаса, «сусыз да кабып йоту» шактый кыен нәрсә. Әгәр дә шигырьдәге ишарәләрнең, төрттерүләрнең, кинаяләрнең мәгънәсен укучы аңлый алмый икән, билгеле, шигырь оттыра, бөтен гүзәллеген, тирәнлеген бу укучы алдында югалта. Моның сәбәбе ике төрле булуы мөмкин: йә шагыйрьнең ишарәләре төгәл булмаган, йә укучының аңында шагыйрь фикерләре белән бәйләнешкә керә алырлык фикерләр юк. Шулай да, шигырьне катлауландырганын белә торып, мин ассоциацияне бүгенге шигъриятебезнең бер куанычы дип әйтер идем. Мин, үземә калса, ассоциацияне лирик геройны «гомуми кеше моделенә» әверелдерүдә йә «интеллектуальлекне» психологик абстрактлыкка китерүдә һич гаепли алмас идем. Шамил Мәхмүдовның гади әйберләргә мәдхия җырлаучы, яуларны пьедесталга күтәрүче тыныч канлы, киң күңелле, зирәк акыллы лирик героен да, Равил Фәйзуллинның тиз кабынып китүчән, үз фикерен, тавышын күтәребрәк әйтергә яратучан, үз сүзенә турылыклы булырга тырышучы лирик героен да, Рөстәм Мингалимов-

ның кырыс, киная белән сөйләргә ярата торган, тормыштагы үз урынын яхшы белгән лирик герое да, минемчә, психологик яктан, чорга мөнәсәбәт ягыннан да конкретлар, бер-берсенә охшамаганнар, гәрчә уртаклыклары шактый күп булса да. Әгәр дә проблемаларның күбесе бүген илләр, халыклар, Җир шары өчен гомуми икән, бу гомумилекнең лирик геройларга да үтеп керүе, аларның уртак сыйфаты булуы табигый күренештер.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: «өченче дулкынга» хас тормышка якынлык, иң соңгы елларда «өченче һәм дүртенче дулкынга» хас «гомумилек», «абстрактлык» белән органик рәвештә кушыла бара һәм әдәбият мәйданына тормышчан, тирән шигырьләр килә тора. Бүгенге яшь шигъриятебезнең үсеш юлы әнә шул юнәлештә.

# Эредәнрәк, олыданрак

*1968 ел татар шигърияте*

Хөрмәтле иптәшләр! Безнең мәҗлесебез «Әдәби 1968 ел йомгаклары» дип аталса да, мин шигъриятебезнең тәгаен бүгенге, быелгы торышы турында күп әйтә алмам. Китаплардагы, журналлардагы, гәзитләрдәге шигырьләрнең күпчелеге үткән елларныкы. 1968 елда шагыйрьләребез иҗат иткән әсәрләрнең байтагысы бастырып чыгарудагы оперативлыгыбызга бәйле рәвештә тагын берничә елдан гына дөнья күрәчәк. Ул әсәрләр турында без, нәкъ бүгенгечә, берничә елга соңгарып фикер йөртербез, бүгенге көнебез, иртәгәбез өчен шактый кирәкле булган хөкемебезне соңгарып чыгарырбыз.

Әсәрнең язылуы һәм басылып чыгуы арасындагы тәңгәлсезлек әдәби әсәрләргә үзләренең социаль бурычларын үтәргә комачаулый. Көн аһәңе белән сугарылып, конкрет вакыйгалар чагылышы булып туган, шагыйрьнең хис кайнарлыгын, фикер киеренкелеген саклаган әсәрләр, кем әйтмешли, «янгын сүнгәч кенә» укучыга барып җитәләр. Бу очракта инде әсәрләр үзләренең кыйммәтен күпмедер җуйган булалар. Шигырь, матур әдәбиятның иң оператив жанры буларак, бастыруда да кичекмәс оперативлыкны дәгъва итә. Шигырьнең шушы таләбен хисапка алмау, аны үтәмәү — шигырьгә социаль бурычын үтәргә булышмау дигән сүз. 1968 елда язылган шигырьләр турында сүзем шул: алар тизрәк дөнья күрсеннәр һәм укучыларына ирешсеннәр иде.

Ә хәзер сүз 1968 елда дөнья күргән әсәрләр турында барыр. Дөресрәге, аларны укыганнан соң туган шәхси кичереш, фикерне сезнең белән дә уртаклашмакчы булам.

Шушы уңайдан алда торган ике олы бәйрәм турында да әйтеп узасы килә. В.И.Ленинның 100 еллыгы да, Татарстанның 50 еллыгы да безнең шагыйрьләребезгә «публицистик илһам» бирә. Юбилей көннәренә якынлашу ул илһамны киеренкерәк иттерә, шагыйрьнең хис-фикерләрен кәгазьгә ешрак ташыта, шигырьгә эвереледерә. Ул шигырьләрне кайнар, хуш исле килеш укучыларыбызга җиткерә бару үзебезнең тарихыбызга һәм киләчәгебезгә зур ихтирамыбыз булыр иде.

Әсәрнең язылуы белән басылуы арасындагы зур вакыт кайвакыт әсәрнең авторына да күңелсез минутлар китерә. Әйтик, мин бүген берәр шигырьне йә китапны сүгеп ташласам, шулар нигезендә аларның авторын, шагыйрьнең иҗатын бәяләсәм, шагыйрьгә дә, бәяләүчегә дә шактый уңайсыз булачак. Нишләмәк кирәк, быел чыккан китапларга, быел басылган шигырьләргә нигезләнеп фикер йөртергә туры килә. Башка чара юк. 1968 елда яңа әсәрләр туу, яңа китаплар чыгу шатлыгы белән беррәттән, тетрәндереп җибәрерлек шигъри кайгы да булды. Үзенең илле еллыгын да тутырмыйча, күп әсәрләренә соңгы ноктаны куярга өлгермичә, зур талант иясе, туры шагыйрь Әнвәр Давыдов вафат булды. Шагыйрьне сагынып:

Ник киттең,
Ник киттең,
Ник киттең, югыйсә
Бер артык көн бирде
ич сиңа кәбисә, —

дип әйтәсе килә. Әнвәр Давыдовның якты истәлегенә хөрмәтебезне белдереп, бу эшлекле мәҗлесебезнең бер минутка торып басуын теләр идем.

Гәзит-журналларыбызда, гомуми җыентыкларда, аерым китапларда басылган шигырьләребезне укып чыккач һәм аларны гомуми килеш күз алдына китергәч, 1968 елдагы шигъриятебезгә мондыйрак бәя биреп була: «Үткән елда безнең шигъриятебезнең үсеше фәлсәфи яктан тирәнәю юнәлешендә барган». Ягъни һәрбер сүз мәгънәлерәк яңгырый башлаган, һәр җөмлә үз эченә күбрәк фикер сыйдыруга ирешкән, һәр шигырь олырак, тирәнрәк мәгънәгә ия булып, тормышыбызның социаль-фәлсәфи ягына ныграк бәйләнгән. Шагыйрьләребез тормышның асылына тирәнрәк үтеп керә алганнар. Фикерләремне мисаллар белән расларга телим. Мәсәлән, Сибгат Хәкимнең фашист теле турында:

Колакка ят, имәннәргә ул ят,
Нигә ул ят? Серен тап, өйрәт.
Бәрелеп сугылып йөри кырда сүзләр,
Кабул итми кебек табигать,

— дип әйтүе.

Яңа буын шагыйрьләрен көтә,
Җәлилләрдән бушап, тәрмәләр...

*(«Белгәннәр тик тора». «Казан утлары», № 1)*

Хәсән Туфанның:

Олылый һәрбер бөек ил
Үзенең үткәннәрен.
Ә синең, халык буларак,
Юкмыни өлкәннәрең?
Азмыни күргәннәрең?

*(«Истәдер». «Казан утлары», №2)*

Әхсән Баянның:

Әй, кешеләр,
Бәхеттәнме сезнең,
Ояттанмы алсу йөзегез?

*(«Мин — диңгез». «Казан утлары», № 6)*

Шәүкәт Галиевнең:

Ярый, дөнья
Тыныч тора.
Баш өстендә
Кылыч тора.

*(«Казан утлары», № 7)*

Равил Фәйзуллинның:

...Асылыңны яшереп
кыланма ни генә, —
буыннар хәтерендә
бары да чигелә!

Рөстәм Мингалимовның:

Дөрес юнәлешне юллар бирә,
Каршылыклар дөресен аңлата...

*(«Казан утлары», № 11)*

Гәрәй Рәхимнең:

Сез гел сынап карамагыз,
Алданырсыз, мин бит кеше.

Нури Арслановның:

Бер мин түгел, әлмисактан бирле
Халкым минем моңны ярата.
Бик күбәеп китсә хәсрәтләрем,
Җырлыйм: «Җыру кайгы тарата»

Роберт Әхмәтҗановның:

Мин үземә үзем тыныч дәүләт:
Сугыш ачмыйм, утлар гүләтмим.
Һәр пунктка ашыгып имза куймыйм,
Һәм танымыйм һәрбер дәүләтне...

*(«Иделдә җәй. Еллар»)*

Илдар Юзеевның:

Гөлне киссәң — гөл кала,
Телне киссәң — тел кала,
Башны киссәң — ил кала...

*(«Казан утлары», № 9)*

Камил Мостафинның:

Акылларын җуйса балалар,
Балаларын җуя аналар, —

дигән шигъри өзекләре генә дә шигъриятебезнең куандыргыч тирәнлеге турында күпмедер сөйлиләр. Шушы мисалларга нигезләнеп кенә дә без шигъри детальләрнең, образларның йөрәкләрендә зур социаль-политик мәгънә, фәлсәфи тирәнлек һәм бүгенге көннең киеренке сулышы ятканы турында шатланып әйтә алабыз. Шагыйрьләребезнең дөнья, тормыш күренешләрен синтезлый алу осталыгы зурайган, шагыйрьләр үзләренең гражданлыкларына фәлсәфилек өстәгәннәр һәм бу фәлсәфилек, әгәр дә шулай дип әйтергә мөмкин булса, илебез «стандартларына» якынлашкан. Ә кайбер шагыйрьләребезнең иҗатында ул чын мәгънәсендә илебезнең иң катгый, кырыс «стандартларының» таләпләренә җавап бирә алырлык. «Казан утлары»ның 1 нче санына кергән «Эмблема» һәм «Белгәннәр тик тора» дигән шигырьләргә сылтап, Сибгат Хәкимнең «Герма-

ния циклы», минемчә, нәкъ шундый әсәр. «Германия циклы»нда уй-фикерләр, хисләр, проблемалар ил, дәүләт, халык масштабындагы фәлсәфи категорияләрне үз эчләренә сыйдырганнар. Андагы проблемалар, социаль һәм чор, көн чикләреннән ашып, гомумхалык, гомумвакыт категорияләренә барып җиткәннәр. Шуның белән беррәттән проблемаларны куючының чын коммунистик идеяләре, идеал-өметләре, принциплары көн кебек ачык. Бу идеяләр зур осталарча табылган, көмешчеләрчә төгәл, зәвыклы итеп эшләнгән образларга төреп бирелгән.

Гамил Афзалның «Казан утлары»ның 5 нче санында чыккан шигырьләрендә дә, Роберт Әхмәтҗановның «Еллар яна» китабында да, Илдар Юзеевның «Соңгы сынау»ларында да, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Марс Шабаев, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баянов, Хисам Камалов шигырьләрендә дә шигъриятебезнең үсешен күреп була. Өлкән шагыйрьләребез дә, урта буын, яшь буын һәм иң яшьләребез дә шигъри формаларны эчтәлеклерәк, баерак, тыгызрак итү өстендә эшләгәннәр. Хәтта шигърият ишеген шакып килеп керә торган Зөлфәт Маликов, Мөдәррис Әгъләмов, Эдуард Мостафиннарның әсәрләре дә формаларының эчтәлеклелеге ягыннан шактый куандыралар. Тагын шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: моннан ике-өч ел гына элек өч буыннан гына гыйбарәт булган шагыйрьләр коллективы бу өч исем белән инде дүрт буынлы гаиләгә әверелде. Бу дүртенче буын, әйтелгән өч фамилия белән генә чикләнмичә, алдагы елларда тагы да тулылана төшәр әле дип уйларга да урын бар. «Яшь ленинчы»да, «Татарстан яшьләре»ндә, «Казан утлары»нда күренеп-күренеп киткән яңа исемнәр шуның хакында сөйлиләр.

Шагыйрьләр гаиләсенең тагын бер буынга баюы һәм бу буынның шактый талантлы булуы минем яшьтәшләргә, безнең буын шагыйрьләренә стимул өстәп җибәрде. Алар әдәбиятның төрле өлкәләрендә шактый активлашып киттеләр, ә бу активлашу урта һәм олы буын шагыйрьләренә дә йогынты ясады дип әйтсәк ялгыш булмастыр. Гомумән, 1968 елда ярышчылар күбәйде, иҗади ярышка мәйдан киңәйде, һәм бу — 1968 әдәби елның зур казанышларының берсе. Иҗади ярыш җимешләре алдагы елларда бик ачык күренер һәм барыбызны да шатландырыр дигән өмет бик зур һәм шиксез.

1968 шигъри елның уңышлары гомумән әнә шундый.

Быелгы шигъриятебезне берничә мәртәбә күздән кичереп чыккач, анализлагач, казанышларын күреп куангач, минем алдымда үзеннән-үзе бер сорау туды: ә ни өчен безнең шигъриятебез бөтенсоюз мәйданында тиешле яңгырамый соң? Сәнгать әсәренә шушы яктан килү безнең шигъриятебезгә генә хас сорау түгел. Композиторларыбыз да, рәссамнарыбыз да үзләренең әсәрләрен бөтенсоюз аренасына чыгарырга телиләр, шуңа тырышалар. Башка халыклар сәнгатендә дә бу сорау беренчел сорауларның берсе булып тора. Күрәсең, бөтенсоюз аренасына басарга тырышу ул — күпмилләтле совет сәнгатен тудырудагы бик зур стимулларның берсе. Бу — совет сәнгате өчен зарури күренешләр. Ә шулай да ни өчен соң безнең шигъриятебез бөтенсоюз мәйданында тиешле яңгыраш тапмый? Бәлки, бездә көн кадагын образ иткән, чор, сәясәт сорауларына җавап булып, йә, киресенчә, фәлсәфи, социаль сорау, таләп булып яңгырый торган публицистик шигърият юктыр.

Бәлки, һәр күңелгә үтеп керә ала торган, һәр йөрәкне башка йөрәкләр белән тоташтыра ала торган, һәркемгә әхлакый азык булырлык гражданлык поэзиябез юктыр? Бар. Бар. Безнең шигърият дөньясында шактый дефицит булган сатирик поэзиябез дә бар, юмор поэзиябез дә, һәм алар, бәхеткә каршы, эпиграмма, пародия белән генә дә чикләнмичә, үзләренең тулы канлы тормышлары белән яшиләр. Кем әйтмешли, бу дефицит товар белән курыкмыйча, әллә кайларга чыгып китәргә мөмкин, бер карасаң. Ләкин андый шигырьләребез дә бөтенсоюз мәйданында яңгырамыйлар.

Әлеге «ни өчен?»гә җавап табар өчен, шигъриятебезнең зур, матур булып күренгән казанышларын бөтенсоюз шигърияте казанышлары белән чагыштырсак, минем карашка, берничә зур сәбәпкә юлыгырбыз. Шуларның берсе, минемчә, монументальлекнең җитенкерәмәве. Әгәр дә Фатих Хөсни, прозаны күздән кичереп, «Кайда соң сез, олы язмышлар?» дисә, без дә «Кайда соң син, монументальлек?» дип кычкырабыз. Монументальлек беренче чиратта шигъриятнең эпик төрләренә хас, чөнки эпик әсәрләр яшәеш, тормыш, вакыт турында дәүләт, дөнья, кешелек масштабындагы фикерләрне сыйдырырга сәләтлерәк. Дастаннар, эпослар, поэмалар еллардан елларга, дәверләрдән дәверләргә үзләрен тудырган халыкларның, чорларның акыллы, гыйбрәтле тәҗрибәләрен алып киләләр. Алар үз чорларына йә шул чорлардагы берәр проблемага мәңгелек һәйкәл булып калалар.

Без, эпик әсәр дигәч тә, поэманы күз алдына китерәбез. Алай гына да түгел, күпләребез озынрак шигырь яза да аны поэма дип исемли. (Күрәсең, әсәрнең жанрын билгеләгәндә баллны арттыру прозабызга һәм тәнкыйтебезгә хас күренеш түгел икән. Зур булып күренергә тырышу кайсыдыр яктан безнең җитлекмәвебезне күрсәтә торган нәрсә дә ул.) 1968 елда унбишләп әнә шундый зур әсәр матбугат битләрендә басылып чыкты һәм ул әсәрләрдән монументальлек таләп итү бик тә табигый. Ләкин шул әсәрләрдән бик азы шигъриятебезнең үсешен күрсәтә. Илдар Юзеевның «Соңгы сынау»ы, Хисам Камаловның «Тормыш дулкыннары», Равил Фәйзуллинның «Көрәшчеләр»е, Нәби Дәүлинең «Кеше турында монолог»ы — төрлесе төрле яктан шигъриятебезне үстергән әсәрләр. Ләкин шушы дүрт әсәрнең икесе генә — «Соңгы сынау» һәм «Көрәшчеләр» — монументальлеккә омтылганнар.

Хисам Камалов «Тормыш дулкыннары»нда үзенең гаҗәеп киеренке, кешелекле хисләрен-фикерләрен сентиментальрәк агымга кертеп җибәргән һәм әсәренең яңгырашын чикләгән.

Нәби Дәүли «Кеше турында монолог»ын да үзенең проблемаларын дидактика, нотык сөйләүгә кайтарып калдыра, аерым вакыйгаларны, аерым проблемаларны гомуми масштабка, вакыттан өстенрәк масштабка күтәреп җиткерә алмый. Бу ике әсәрдә куелган проблемалар монументаль чишелеш таба алмаганнар.

Ә «Соңгы сынау» белән «Көрәшчеләр»дә эш башкачарак.

«Көрәшчеләр» — кешенең аңы, җаны өчен көрәш барган безнең чорның рухын, ритмын, киеренкелеген шактый төгәл күрсәтә торган әсәр. Монда:

Беләкләләр җитә,
Йөрәкләләр кирәк,
Куәтлеләр җитә,
Көрәшчеләр кирәк, —

дигән, озак вакытлар безнең гасыр чакыруы булып яңгырый торган юллар да бар. Бу катлаулы, күппланлы әсәрдә, минемчә, әсәрнең гомуми тышкы киеренкелегенә ятышлы, ләкин эчке киеренкелегенә артыграк булган детальләр, фикерләр дә очрый. Алар әсәрне таркаурак итәләр. Бу әсәр, шушы яңгырашы сакланып, минимум детальләр белән генә эшләнсә, публицистик поэзиябезнең монументальлектә җитешкән бер үрнәге булыр иде.

Илдар Юзеевның «Соңгы сынау»ы — монументаль кешенең монументаль үлеме турында. Әсәрнең әдәби алымы — мәңге монументаль Мефистофель белән Мусаның диалогы. Шушылар гына да «Соңгы сынау»га монументальлек бирергә тиешләр иде. Ләкин Муса белән Мефистофель арасында чын мәгънәсендә зур фәлсәфи бәхәснең була алмый калуы, ә кай ара Муса бер нәрсә турында, ә Мефистофель икенче нәрсә турында декламировать итеп, аңлашылмый торган сөйләшү алып баралар, Мефистофельнең Мусага «җанны саттырырлык» бернәрсә дә тәкъдим итә алмавы, кешегә аллалар булышмаганда да ярдәм кулы сузган Мефистофельнең кинәт, бернинди сәбәпсез, тиран ярдәмчесе булып китүе, ниһаять, әсәрнең башында ук Мусаның җанын, идеалларын сатмаячагы сизелеп торуы Илдар Юзеевка алган проблемасын монументаль итеп чишәргә ирек бирмәгән. 1968 елгы иң кызыклы әсәрләребездән булган бу поэмага Илдар Юзеев тагын бер әйләнеп кайтыр әле дип әйтәсе килә.

Безнең әсәрләрнең гомумхалык, гомумвакыт категориясендәге фикерләре белән сугарылып җитмәве әнә шул монументальлекнең җитмәвенә кайтып кала да инде. Әгәр дә без «для всех эпох и народов» дигәнрәк таләп куябыз икән — артыксынмаска кирәк. Безгә инде күптән зурдан каера башларга вакыт. Безгә инде күптән үзебезнең уңышларны, казанышларны үз җирлегебез бизмәне белән генә үлчәмичә, илебезнең күпмилләтле әдәбияты калыбындарак карарга вакыт. Шунда әсәрләребезнең кыйммәтен тулырак күрербез.

Шигъриятебез алдында торган, алай гына да түгел — әдәбиятыбыз алдында торган икенче бер зур проблема ул — милли колорит. Милли колорит дигән нәрсә — безнең сәнгатебез барлык бармаклары алдында тора торган нәрсә. Рәсем сәнгатендә ул беренче чиратта милли төсләр гаммасын табуга, милли сызыклар, алымнар булдыруга кайтып калса, шигъриятебездә милли, традицион жанрларны үстерүгә, образларны милли атрибутлар асылы нигезендә баетуга һәм, иң мөһиме, әсәрләрне халкыбызның психологик үзенчәлекләренә нигезләнеп башкаруга барып тоташа. Психологик милли колоритка ирешү, билгеле, җиңел эш түгел. Ул ахыр чиктә милли жанрларның, милли әдәби алымнарның татар халкына гына хас тормыш атрибутларының, образларның конкрет әсәр эчендә гармоник укмашуы. Милли колорит һәрвакыт халык язмышында, аның бөтен тарихында, бүгенгесендә, гореф-гадәтләрендә, әхлакый кануннарында, сынамышларында, йолаларында, җыр-биюләрендә...

Ә без хәзер ул милли колоритны тел үзенчәлекләренә, идиоматик әйләнмәләренә, җөмлә төзелеше кануннарына һәм географик атрибутларга гына кайтарып калдырабыз кебек. Кайчандыр безнең дә ул колоритыбыз булган. А.И.Метченко дигән рус әдәбияты белгече 1940 елны «Ранний Маяковский»[1] дигән мәкаләсендә болай дип яза: «В противопоставлении русского искусства западному футуристы находились под сильным влиянием славянофильских идей. Россия рассматривалась как выражение восточного начала, отсюда увлечение Востоком, Азией. «Да здравствует прекрасный Восток!» провозглашали лучисты и будущники. «Мы против Запада, опошляющего наши и восточные формы и все невелирующего». Россия и Восток нераздельно связаны еще с времен татарских нашествий, и дух татар, дух Востока, так вкоренился в нашу жизнь, что подчас трудно отличить, где кончается национальная черта и где начинается восточное влияние».

Ул колоритның булганын Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, Фатих Кәрим һәм башка зур шагыйрьләребезнең әсәрләре белән исбатлап булыр иде.

Дагстан шагыйре Капиев әфәнденең бер шигыре искә төшә:

Оттого, что влюблены,
Нет добра нам, добрый друг,
Коль разлучены сердца,
Как вершины снежных гор.
Если б можно было нам
Так сердца соединить,
Как в стволе ружья слиты
Пуля с порохом в одно.

Күрәсез, рус телендә дә шигырь үзенең тау ягы колоритын, ритмын саклап кала алган, ә безнең тел нюансларына гына корылган кайбер шигырьләрне тәрҗемә итсәк, шигырь бөтен ямен һәм мәгънәсен югалтып, төссез бер массага әверелеп кала, гәрчә ул шигырьләр әйбәт кенә булсалар да.

Кайберәүләр, тәрҗемә итү аша әсәрнең бәясен билгеләү критерий түгел, диярләр. Бәлки, бәлки... Әгәр

без үзебезнең шигъриятне бөтенсоюз бизмәненә куеп карыйбыз икән, тәрҗемә — зур критерийларның берсе. Моңа мисаллар бик күп, мин бер-икене генә китереп китмәкче булам.

Таңда янган якты йолдыз кебек,
Матур күзләреңә табынам.
Салкын караш күрсәм, газапланам,
Ялкын күрсәм, дөрләп кабынам.
Сине эзлим йөргән юлларымда,
Төшләремдә сине юксынам,
Очратканда тәмам телсез калам,
Әйтер сүзем бер дә юк сыман.

*Резеда Вәлиева*

Бездә нинди генә телгә тәрҗемә иткәндә дә үз колоритын саклап калучы шигырьләрне табу кыен эш. Кабатлап әйтсәк, колорит ахыр чиктә милли психологиягә, халкыбызга хас булган тормыш-көнкүреш атрибутларына, халкыбызның күңеле асылына, аның рухына һәм форма ягыннан милли жанрларга, аларны үстерүгә, алардан вариацияләр, модификацияләр ясауга, халык авыз иҗатының потенциаль мөмкинчелекләре булган шигъри алымнарын үстерүгә кайтып кала.

Сәбәпләрнең тагын берсен әйтер өчен Резеда Вәлиеваның «Якты йолдызым» дигән поэмасыннан өзек китерик:

Авыр сулап куйды Сания:
— Әйдә, дустым, кайтыйк, кич җитә...
Тик Гөлниса озын толым очын
Бер үрә дә һаман, бер сүтә:
— Якын сердәшем син, дустым син,
Хәлләремне ләкин белмисең...
Һәм сыенды дусты күкрәгенә,
Кырлар кинәт тынып калдылар.
Гөлнисаның зәңгәр күзләреннән
Энҗедәй саф яшьләр тамдылар...
— Газап чикмә. Хәйдәр үзе дә
Түзә алмас сине күрмичә.
Күз яшеңә кадәр сөйкемле,
Гаҗәеп кеше бит син, Гөлниса...
— Син әйтерсең инде, дускаем! —
Онытылып Гөлкәй бер көлде.
Яңгырдан соң чыккан кояш төсле,
Күзләреннән нурлар бөркелде...
Имән яфракларын лепердәтеп,
Йомшак кына талгын җил бәрде.
Җил уяткан таңгы сандугачтай,
Кыз өздереп җырлап җибәрде:
    Мирхәйдәрем — яшьлек язларым,
    Мирхәйдәрем — күңел назларым,
    Бәхетемнең сүнмәс яктысы,
    Сагышымның чиксез татлысы...

Күз алдыгызга китерегез: үбешеп йөри торган Гөлниса бернинди сәбәпсез иптәш кызының күкрәгенә сабый бала кебек сыена. Нигә сыена? — Хәйдәрне уйлап. Аннары соң елап җибәрә. Минут та үтми — көлеп җибәрә, аннары соң (игътибар итегез) «кич җиткәндә», «таңгы сандугачтай, кыз өздереп җырлап җибәрә».

«Мирхәйдәрем — яшьлек назларым». Беренчедән, автор бу очракта үзенең героен үзе дә сизмәстән табигый булмаган ситуациягә куя. Бу ситуация, билгеле, ышандырмый, укучыга автор теләгән эффектны бирми, киресенчә, комик вакыйга булып күренә. Икенчедән, кодмәгәндә һәм кирәкмәгәндә бу хикәягә (мин бу «поэманы» хикәя кебегрәк дияр идем) мелодрама дисәк тә ярый торган, опера элементы дисәк тә ярый торган җыр китереп кертә. Әлеге дә баягы комик ситуация хәзер бер мәгънәсез нәрсәгә әйләнеп кала. Өченчедән, авторның эпитет сайлаудагы грамотасызлыгы: автор үзе «кич җитә» ди, үзе «таңгы сандугачтай җырлап җибәрде» ди.

Тәүфикъ Камалиевның:

Шыкырдап каткан көн итек,
Шыгырдап тора ак кар.
«Эх, солдат, солдат» дигән күк
Пошкыра бугай атлар, —

дип әйтүе дә шул чамадарак. Әгәр дә «таңгы» дигән чагыштыру янына «яңгырдан соң чыккан кояш төсле»не дә, «өздереп»не дә, «энҗедәй саф»ны да, «күздән бөркелгән нурлар»ны да һәм тагын йөзләгән шундый сүзләр, чагыштырулар өстәсәк, әдәби осталыкның тагы ике ноктасына китереп басабыз. Берсе — образларның табигый һәм фәлсәфи төгәллеге. Икенчесе — образларның, шигъри детальләрнең штампланулары. Болар-

ның икесенә дә, кызганычка каршы, мисалларны шактый күп китереп булыр иде. Вакытны аңарга әрәм итеп тормыйча, бу ике сәбәп турында берничә сүз әйтеп китик, бәлки, файдалырак булыр. Шигырь — беренче хәрефеннән алып соңгы ноктасына кадәр бер организм, бер халәт. Аның үзенең чикләре, юллары, нокталары бар. Шигырьнең халәте (ә халәт һичшиксез эчтәлеккә бәйле) барлык детальләрне, образларны үз законына буйсындыра һәм үзен монумент итә. Нәкъ безнең сингармонизм законы кебек — сүзнең тамырындагы беренче сузык аваз калган сузыкларны үзенең теләгенә буйсындырган кебек. Шигырьнең төп образлары да башка образларны һәм детальләрне үзләренә охшарга (ассимиляцияләнергә) мәҗбүр итәләр. Бу инде стильләштерү дип аталадыр. Тукайның «Кисекбаш»ы — әнә шундый ассимиляциянең гүзәл бер үрнәге. Андагы образлар һәм детальләр әсәрнең буеннан-буена бер стильдә (сатира-гротеск стилендә) бара. Бер-берсе янында детальләр, образлар бик тыныч, табигый яшиләр. Грамоталы итеп стильләштерергә өйрәнү — күп шагыйрьләребез алдында торган бер мәсьәлә. Бигрәк тә яшьләре шактый булып та, «Яшь шагыйрь» булып йөргәннәребез арасында.

Дөрес, кайбер очракта осталарча стильләштерелгән әсәрләр дә очрап куя. Мәсәлән:

Дөнья —
Зур ашханә,
Минут —
Шеф-повары аның.
Кулында уйната
Язмыш чүмечен.
Берәүгә —
Тутырып сала
шатлык шәрабын,
Берәүгә —
Хәсрәт өйрәсен — чөмерсен.

*А.Сәләхетдинов*

Шигырь һөнәр атрибутлары ягыннан бик төгәл стильләштерелгән, ләкин бу алым авторны вульгарлыкка китереп керткән, зәвыксызлыкка кертеп батырган. Мондый талымсызлыклар, таләпчәнлекне оныту, һәрхәлдә, безнең шигъриятебезнең үсешенә дә, укучыларыбызның зәвыгы камилләшүгә дә файда китермидер.

Ә штампланган образлар һәм детальләр шигъриятебезне төче итәләр, төссез итәләр, көчсез итәләр.

«Нәрсә булды?» —
Җиңел соравы,
Өзелгәндә күңел кыллары...

*К.Фәсәхов*

Күкне иңләр хыял канатларың
Сугыш утларында янмасын!

*Э.Мөэминова*

Каннар койдык сугыш кырларында...

*М.Мазунов*

Боларны күпме кабатларга кирәк иде? Мондый штампланган образлар һәм детальләр укучы өчен беркатлылар (наивлар), сайлар. Андый образлардан, детальләрдән торган шигырьләрнең тәэсир итү көче дә чамалы гына, кыйммәте дә бик кечкенә. Шигырьнең хәтта гаҗәп кызыклы логик-композицион төзелеше дә, кызыклы әдәби алым да штампның штамплылыгын алып ташлый алмый. Безнең шигъри детальләрнең җегәрсез булуы ахыр чиктә шигырьләребезнең дә буш булуына китерә. Ә җегәрле детальләр, образлар — үзләренә чорның авырткан йә чәчәк аткан урыннарын, социаль хәрәкәтне, халыкларның тел очында торган уй-фикерләрен сыйдырган, тормыш фәлсәфәсенә турыдан-туры мөнәсәбәте булган детальләр һәм образлар.

Шагыйрьләрнең юлын кан кискән,
Эше беткәч, алып пистолетын,
Безнең чорга чөйгән Дантеслар.

Сибгат Хәкимнең бу юллары укучы аңында зур ассоциацияләр тудыра.

Шушы нисбәттән «аңлашылмый торган» дигән шигырьләр турында да берничә сүз әйтеп үтәргә кирәктер. Төрле җыелышларыбызда сөйләнгән сүзләрне исебезгә төшерсәк, андый шигырьләрнең чыннан да булуына тагын бер тапкыр ышанырга туры килер. «Аңлашылмый торган» шигырьләр алар, минемчә, берничә төрле. Кайберләре зур җегәрле образлар, детальләрдән хасил булып, оригиналь, катлаулы логик-композицион җилем белән сугарылганнар һәм, чыннан да, авыр аңлашылалар. Андый шигырьләрне аңлар өчен, билгеле, күпмедер дәрәҗәдә универсаль белем дә, культура да кирәк. Мәсәлән, Рөстәм Мингалимовның, Равил Фәйзуллинның, Роберт Әхмәтҗановның кайбер шигырьләре нәкъ менә шундыйрак «аңлашылмый торган» шигырьләр. Билгеле, алар шул дәрәҗәдә үк катлаулы булып, сай шигырьләр кебек үк аңлашыла торган булсалар, начар булмас иде. Ләкин алай булу йә бөтенләй мөмкин түгел, йә даһилык сорый.

«Аңлашылмый торган» шигырьләрнең башка төрләре дә бар. Мәсәлән:

Һай, күңелсез түшәк кырында.
Кайчан, димен, савыгыр көн туар?..
Ә күңелем сезнең җыенда,
Петрарка, Байрон, Элюар!..

Ә кем белә, синдә, мендәрем,
Тынар, бәлкем, кайнар йөрәгем...
Юк, суынмас, тынмас йөрәгем:
Яктыртыр ул юлын меңнәрнең!

Саф сулышлы җилне сагындым,
Шуңадыр шул учым кычыта!
Әмренә баш иеп аңымның,
Күңелкәем былбыл очырта.

Үлемсез җыр итсәң илеңне,
Туктатыр ил синең үлемне.

Менә бу шигырь чыннан да аңлашылмый.

1. Нинди «түшәк кырында»? Кырыенда — мәгънәле кырындамы, арыш кыры мәгънәсендәге кырдамы?

2. Ни өчен М.Хөсәеннең күңеле Петрарка, Байрон, Элюар җыенында?

3. Ни өчен автор «Йөрәгем меңнәр юлын яктыртыр!» дип әйтә ала? «Мендәрем, бәлки, синдә тынар йөрәгем!» дип әйтә алгангамы?

4. Уч кычыткач, саф җил исәме әллә? Әллә уч кычыту акча килү ырымымы? Әллә «саф җил» дип әйтү зур акчаны сагындым дип әйтүме?

5. Аң әмеренә баш игән күңелнең былбыл очыртуы нәрсә соң ул?

6. Ә шигырьнең ике актыккы юлы алдагы 12 юлга ничек бәйләнә һәм нәрсәне аңлата?

7. Бу шигырьне:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була, —

дип кенә әйтеп булганда, китапның редакторы Мөхәммәт Садри бу шигырьне һәм моңа охшаган тагын йөз шигырьне ничек үткәрде икән?

Менә болары инде аңлашылмый. Шушы ук мисалга бәйләп, шигъриятебезгә керергә маташа торган тагын бер авыру турында да әйтеп китик. Мәхмүт Хөсәеннең «Мәрҗәннәрен»дә бик күп исемнәр бар: Бурнаш, Тинчурин, Зыя, Шура, Газинур, Петефи, Алиш, Муса, Йоһан, Андре, Сәйдәш, Тукай, Лермонтов, Маяковский, Шекспир, Юрий Гагарин, Шевченко, Терешкова, Чапай, Павел Попович, Ленин, Назыйм Хикмәт, Петрарка, Байрон, Элюар, Мистраль һ.б., һ.б. Исем шигырьгә килеп керсә, ул инде гомумиләштерелгән образга әйләнә. Мәсәлән, Сибгат Хәким әгәр Дантес сүзен куллана икән, безнең аңда кеше үтерүче образы калка. Образ белән тарихтагы Дантес арасында һичнинди аерма юк. Әгәр дә Хәсән Туфан:

Анда — Буби, Лена, Ямаш, Тукай.
Анда — матәм, олы дүрт матәм.
Аларны мин
Абына-егыла гына,
Көчкә-көчкә генә күтәрәм, —

ди икән, анда татарның жандармнар тарафыннан тапталган мәгърифәт учагы, Россиянең канга баткан революцион көрәш мәйданы, үтерелгән Ямаш, Тукай образлары аңда калка. Алар тарихтагы мәгънәләренә шулай ук тугрылыклылар һәм шигырьнең фикер агышына да туры киләләр. Ә М.Хөсәеннең китабындагы исемнәрнең ничәсе генә шундый икән соң? Бик азы. Бик тә, бик тә азы. Шигырьгә интеллектуальлек өстим дип, тышкы эффект, җегәрлек өстим дип, әсәрне абсурд хәленә җиткерү, шуны укучыга тәкъдим итү — һич тә күркәм эш түгел. Бу — иллюзия күренеше, билгеле, бик күпләребезгә хас авыру.

Фикерләрнең очын очка ялгап шуны әйтәсе килә: зур аренага чыга алмый торуның сәбәпләренең әдәби осталыкка бәйлеләре, минемчә, әнә шулар, чөнки шулар чын кондициягә җиткән, зур мәгънәле әсәрләр тудырырга күпмедер комачаулыйлар. Һәрберебезгә әдәби осталыгыбызны үстерүдә, аңыбызны гомумхалык масштабына күтәрүдә бик күп эшлисебез бар икән әле. Ак шигырь начар да, традицион шигырь яхшы дип сафсата сатуларны ташлап, масштаблы зур мәгънәле, тирән эчтәлекле, осталык ягыннан да грамоталы әсәрләр иҗат итәргә тырышу, шушы юнәлештә бер-беребезгә булышу — менә безнең төп бурычларыбыз! Новаторлыкка тартылган шагыйрьләргә ярдәм итәргә кирәк, чөнки бүгенге новаторлык иртәгә традициягә әверелмәячәк дип кайсыбыз ышанып әйтә ала?

1968 елгы шигырьләрне, китапларны мин тагын бер максатны күз алдында тотып укыдым: кайсыдыр ягы белән кабатланмас рәвештә ялтырап киткән шагыйрь табармынмы, юкмы? Билгеле, бу максат өлкән шагыйрьләребезгә кагылмый. Кызганычка каршы, таба алмадым. Бу — 1968 ел уңышсызлыгы гына түгел, билгеле. Ләкин минем андый талантларның булмавына ышанасым килми, ә «менә мин шундый талант иясенең шигыре» дип кычкырып торган шигырьләрнең матбугатта күренмәве, бәлки, очраклы хәл генәдер. Шулай

икән, шагыйрьләрнең эзләнүләренә булышлык күрсәтергә кирәк. Эзләнүләрнең җимешенә: «Шәхси бу миңа ошамый», — дип кенә катгый һәм соңгы хөкемне чыгарырга кирәкмидер. Йә, киресенчә, «бу миңа ошый» дип кенә күккә чөюләр булмаска тиештер.

Мин еш кына бөек шагыйрьләрнең иҗатындагы дөньяга карашның, яшәүгә, үлемгә карашның даими булып калуы турында уйланам. Ни өчен, мәсәлән, Хәйямның барлык шигырьләрендә фани дөньядагы яшәүдән соң башка яшәү юк, шуның өчен фани дөньяда мөмкин кадәр күбрәк ләззәтләнеп, татып, шатланып кал, телэгеңә ирешеп кал дигән фикер саклана. Чөнки Хәйямның күңелендә моңа фәнни, шагыйрьнең үзе өчен үзе исбатлаган нигезе булган. XI йөздә үк инде Лобачевский геометриясенә якынлашкан, кубик тигезләмәләр теориясенең авторы булган, 5000 елга 1 генә көнгә ялгыша торган календарь төзегән кешенең фәнни инануы шигъри инануга әйләнгән һәм Хәйямга гына хас булган эзлекле, төгәл, һәрвакыт даими булган оригиналь шигъри дөньяга әверелгән. Бәлки, безнең шагыйрьләребез арасында да, Хәйям масштабында ук булмаса да, эзлекле эстетик принциплы, фәлсәфәсендә, дөньяга карашында оригиналь даимилек күрсәтә алырлыклары-быз бардыр. Менә шуларны тану, шуларны үстерү — тагын бер зур бурычыбыз.

Шунысын да әйтик, алда саналган сәбәпләрне бетердек тә, бөтенсоюз аренасына килеп тә чыктык дигән сүз түгел.

1968 елда Мәскәү нәшриятларында бары өч татар шагыйренең генә китабы чыкты: Сибгат Хәким, Әхсән Баян, Шамил Мәхмүдов китаплары. Шигырьләрнең тәрҗемәләре гомумән алганда уңышлы гына. Җентекләбрәк тикшерә башласаң, тагы да яхшырак тәрҗемә итеп булганы ачыклана. Тәрҗемәләрнең тиешле кондициягә килеп җитмәвенең берничә сәбәбе бар. Берсе: тәрҗемәче подстрочник аша эш итә. Икенчесе: тәрҗемәче автор белән көндәлек бәйләнештә булмыйча эшли. Ә безнең татар теле гаять бай колоритлы, күптөсле, катлаулы тел. Аның бөтен бизәкләрен булдыра алганча максимум кабатлар өчен безгә подстрочниксыз эшли торган тәрҗемәчеләр булдырырга кирәктер. Ул тәрҗемәчеләрне Казанда булдырырга кирәк. Бу турыда үткән съездда да сүз булган иде, кызганычка каршы, бүген дә кабатларга туры килә. Болардан чыгып бер тәкъдим әйтәсе килә: «Шигырь бәйрәме»н, ел саен русча да чыгарсак, бу тәрҗемәчеләр үстерергә зур матди база булыр иде, татар шигырьләренә үзләренең интернациональ бурычларын үтәргә дә бер сукмак булып, бу сукмак тора-бара бөтенсоюз аренасына илтә торган юлга тоташыр иде.

Үзәк матбугатны күзәтеп барганда, тагын бер нәрсәне искәрәсең: төрле халык шагыйрьләренең китапларына рецензияләр күп басыла. Бездә күпме китап чыга, күпме әсәрләр туып тора, шуларның берсе турында да үзәк матбугатта рецензия күренгәне юк диярлек. Үзебезнең татар матбугатында чыккалаган рецензияләребез, бигрәк тә газеталарыбызда басылганнары, сыйфат ягыннан шактый түбәннәр, Нәби Дәүлинең «Мәрҗәннәр»гә, Рәшит Гәрәйнең «Бөртекләр»гә язган ише рецензияләре белән шигъриятебезне дә, укучыларның зәвыгын да дөрес юнәлештә үстерү мөмкин түгел. Ә яхшы рецензияләрдән, тәнкыйть мәкаләләреннән бер генә газета да, минемчә, баш тартмый. Күрәсең, шигырь буенча каләм чарлаган тәнкыйтьчеләребез аз, булганнары да шигъриятебезне бөтенсоюз мәйданында пропагандалау турында уйламыйлар ахры. Оператив тәнкыйть булдыру, ә моның өчен зур әзерлекле яшь тәнкыйтьчеләр булдыру бүгенге көндә шигърият проблемасына әйләнде.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: бөтенсоюз аренасына чыгарга тырышу ул үзмаксат түгел. Беренчедән, ул укучыларга яхшы кондицияле, ачык идеяле, тирән фикерле әсәрләр бирүгә барып тоташса, икенчедән, безнең әсәрләребезнең иҗтимагый бәяләрен арттыруга барып бәйләнә, иҗади активлыкны арттыра, ә безнең иҗади активлыгыбыз — безнең иҗтимагый активлыгыбыз ул.

*1968*

# Состояние литературной критики в журналах 1970 года

Познакомившись с подшивкой журнала «Совет мэктэбе» за два с половиной года (1968,1969 и первая половина 1970 г.) о состоянии литературной критики в этом издании можно сказать, что за просмотренный период в журнале напечатаны всего два материала, достойных рассмотрения как литературно-критические статьи. Это — статья научного сотрудника института языка, литературы и истории имени Г.Ибрагимова товарища Ф.Ибрагимовой, называющаяся «Биографический жанр в татарской детской литературе» и напечатанная во 2-ом номере журнала за 1968 год, и статья товарища Н.Хисамова «Мотивы Родины в поэзии Дэрдменда», напечатанная во втором номере за 1969 год. О них речь позже.

В журнале постоянно ведется рубрика «Тәнкыйть һәм библиография» («Критика и библиография»), под которой в подавляющем большинстве случаев публикуются небольшие материалы аннотационного характера. (Интересно отметить то, что вышеупомянутые статьи Н.Хисамова и Ф.Ибрагимовой напечатаны не под этой рубрикой.)

Журнал «Совет мэктэбе», соответственно своей специфической направленности, все эти материалы адресует в помощь учителю, через них сообщает ему новейшие сведения в помощь учебникам, рекомендует учителю приобрести ту или иную аннотируемую книгу или познакомиться с рекомендованной работой.

Лучшие из этих аннотаций, например, «Уңышлы хезмәт» Абрара Каримуллина в № 4 за 1968 год (о книге Х.Ярми «Поэтическое искусство татарского народа»), являются хорошими рецензиями, отмечающими как положительные и отрицательные моменты рассматриваемого произведения, так и содержащими практические советы и дополнения, определящие их общественное и научное значение. Кроме упомянутого труда Х.Ярми, рецензированы следующие книги, имеющие отношение к литературе и истории: «ТАССР тарихы» (С.Алишев, М.Мулюков), «Русча-татарча мәктәп сүзлеге» (И.Абдуллин, М.Мухаммадиев), «Г.Камал драмаларының теле», «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (Г.Саттаров).

Кроме аннотаций и рецензий, в журнале встречаются материалы иного плана, в какой-то мере относящиеся и к литературной критике. Один из них — «Газәл жанры турында» («О жанре газели») — напечатан в № 10 за 1969 год и его автором является аспирант КГУ Н.Лаисов. В целом это статья о том, что такое газель, каково ее композиционное своеобразие, у кого из татарских поэтов можно встретить ее. В этой статье есть маленькая (а быть может — большая) ошибка и она начинается с самого названия: газель не жанр, а стихотворная форма вроде итальянской терцины или японской хокку, танки. Эта маленькая оплошность журнала способна ввести в заблуждение большое количество учителей, и через них — учащихся.

Статья М.Гайнетдинова в № 5 «Поэмы Хасана Туфана», написанная как ответ на просьбы читателей, ограничивается простым перечислением поэм Х.Туфана без литературно-критического анализа и толкования, без художественной оценки.

В журнале есть раздел «Татарский язык и литература», где помещаются хорошие методические материалы об изучении творчества того или иного писателя. Лучшие из них очень ценны и как методический, и как литературно-критический материал. Например, в статье М.Магдеева «Об изучении в VIII классе творчества Г.Кандалый» имеется обстоятельный анализ творчества поэта, где автор доказательно выступает против односторонности толкования творчества Г.Кандалый только как атеиста и показывает широту творческого диапазона этого мастера.

Одной из лучших, действительно литературно-критических статей, в журнале является статья Н.Хисамова «Мотивы Родины в поэзии Дэрдменда». Анализ здесь глубокий, разносторонний, наглядный, доказательный. Дэрдменд предстает перед читателем как большой мастер стиха, но как поэт, ограниченный в своих общественно-политических взглядах.

Другая литературно-критическая статья — это «Биографический жанр в татарской детской литературе» Ф.Ибрагимовой. И в этой статье применение слова жанр небесспорно, ведь жанр — это определенный вид произведений, принадлежащих к одному и тому же роду. Автобиографический очерк Тукая, рассказ Г.Ибрагимова «Заки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» и стихотворение М.Гафури не могут относиться к одному и тому же роду. Ф.Ибрагимова в «биографический жанр» включает произведения, рассказывающие о жизни исторического лица. Быть может, речь идет об «историческом жанре» или о «документальном жанре»? В общем-то ведь в основе почти всех произведений лежит жизнь человека. Тогда все они входят в «биографический жанр»...

Автор односторонне и спорно рассматривает интернационализм татарской детской литературы. Если татарский писатель К.Латыйпов написал о чуваше Андрияне Николаеве или М.Хусаин о Павлике Морозове, то, по мнению автора, «Не ограничиваясь национальными рамками, татарская детская литература поднимается на высоты идей интернационализма».

Так же несостоятельно толкование автором понятия «творческий принцип писателя». Творческий принцип рассматривается вне зависимости от общественно-политических взглядов и художественного видения, мировоззрения писателя и сводится только к выбору художественных приемов: если один писатель рисует полную биографию личности, а другой только определенные моменты его жизни — это уже отличие творческих принципов двух писателей...

Эта статья — плохой пример для учителей и хороший пример невнимательности журнала. К счастью, она — единственная.

Пожелания:

1. Наряду с рубрикой «Критика и библиография», где должны печататься истинно литературно-критические статьи и заметки, неплохо бы ввести рубрику «Рецензии», где помещать аннотации и рецензии.

2. Требовать от авторов аннотаций вводить в аннотации моменты критического анализа и оценки.

3. Привлекать больше известных профессиональных критиков.

Просмотрев номера журнала «Азат хатын» за 1968, 1969 и первую половину 1970 года, не могу сказать ни единого слова о состоянии литературной критики, ибо на страницах журнала я не встретил ни одного подобного материала.

Исходя из своей специфики, очевидно, и журнал «Азат хатын» может предоставить свои страницы литературно-критическим материалам. Это остается пока в перспективе.

*1970*

## Балалар өчен шигырьләр

Мин мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен, ягъни үзләре укый белмәгән балалар өчен булган шигырьләр турында берничә сүз әйтмәкче булам. Бу яшьтәге балалар өчен булган шигырьләргә бик олы һәм бик изге бу-

рычлар йөкләтелергә тиеш. Мин шул бурычларның берсе турында гына сөйләмәкче булам. Ул — балада логик фикерләү тәрбияләү. Дөрес, бу бурыч шигырь өстенә генә төшкән бурыч түгел. Уенчыклар һәм уеннар, бала белән дөрес юнәлештә алып барылган әңгәмәләр, аның сорауларына дөрес итеп бирелгән җаваплар, асылда, баланы логик фикер йөртергә өйрәтәләр. Шигырьләр дә бала өчен әнә шул дөрес сайланган уенчыклар һәм уеннар, әңгәмәләр һәм җаваплар кебек булырга тиешләр, минемчә.

Барыбызга да мәгълүм — ата-аналар үзләренең ул-кызларына теләсә нинди китап алып кайтырга яратмыйлар. Ата-ананың дүрт-биш яшьлек ул-кызына кибеттә китап сайлау процессы — баласының бүгенгесе, киләчәге турында ныклап уйлану, кайгырту процессы. Ул иң элек шигырьләрне үзе укып карый, аларга, интуитив булса да, төрле яктан бәя бирә, аннары, катгый бер карарга килеп, бу китапны йә кабул итә, йә инкарь итә. Ягъни балалар өчен язылган китап иң беренче чиратта аның ата-анасы өчен язылган китап дияргә кала. Ә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен китаплар турыдан-туры ата-аналарга адреслананалар, чөнки алар балага фәкать ата-аналары, әби-бабалары, бакчадагы тәрбиячеләре аша гына барып ирешә ала. Дүрттән алып җиде яшькәчә балаларның ата-аналары бүгенге көннәрдә күбесенчә 1937–1942 елларда туган һәм төрле яктан бүгенге көн тәрбиясе алган яшьләр икәнен дә әйтсәк, балалар әдәбиятына заман таләбенең нинди икәнен чамалау кыен булмас. Шул яшьләрнең бер өлеше — педагогика кануннарын белгән өлеше — балаларына үзләренчә яраклы дип аталган татарча шигырь китабы таба алмыйча көрсенеп йөрүен бүген еш очратырга туры килә. Күрәсең, безнең балалар язучылары кайбер очракларда бүгенге яшь ата-аналарның гомумүзенчәлекләреннән хәбәрдар түгелләр. Бу, минемчә, балалар әдәбияты белгечләренең әлеге мәсьәләдә социологик тикшеренүләр алып бармавы һәм балалар язучыларына ярдәм итмәве турында да күпмедер сөйли кебек. Ә кайда соң бездә балалар әдәбияты белгечләре, балалар әдәбияты тәнкыйтьчеләре? Һәм алар нишлиләр? Аларның хезмәтләре кайда?

Балалар әдәбияты тәнкыйтьчеләренең һәм белгечләренең иҗади активлыклары, беренчедән, балалар язучылары өчен кирәк булса, икенчедән, һәм иң мөһиме — ата-аналар өчен кирәк. Балалар өчен булган әсәрләрне һәм педагогик, һәм эстетик яктан квалификацияле итеп тикшергән тәнкыйть мәкаләләре ата-аналарның зәвыгын дөрес юнәлештә тәрбияләүдә бик зур һәм мөһим урын тота. Ә андый мәкаләләр, ялгышмасам, «Казан утлары»нда да, «Совет мәктәбе» журналында да бер дә күренми кебек.

Ә шул арада без балаларга менә мондыйрак шигырьләр тәкъдим итәбез һәм зәвыгы чамалы булган ата-ана алар белән, аны-моны уйламыйча, балаларын тәрбияләргә тырыша:

Арыш, бодай теземнәре
Тора юлларга охшап.
— Бу юл кайларга илтә? — дип
Сорады шуны Илшат.

Елмаеп куйды әтисе:
— Туктамасаң әгәр дә,
Бу юл, улым, алып бара
Муллык дигән шәһәргә...

*(Хәйдәр Гатин. «Хәерле иртә» китабы)*

Беравыктан мин мисал итеп тагын бер шигырь укыячакмын. Менә мондый шигырьләр балалар өчен язучы кайбер шагыйрьләребез өчен типик дисәк тә ярый торган шигырьләр. Алдан ук әйтеп куйсак: алар педагог кулы, педагог аңы белән язылмаганнар. Ә балалар язучысы — педагог булырга тиеш.

Хәзер әлеге шигырьгә кайтыйк. Автор бу шигырьне (китабын да) балаларга дип язган, нәшрият аны балаларга дип бастырып чыгарган, ата-ана, балаларга бу дип, аны улы-кызына укыячак, ә бала үзе бу шигырьдән он суы да, тоз суы да алмаячак. Ник? Чөнки ул нәнигә һич аңлашылмый. Ник аңлашылмый? Чөнки образлылыгы чамалы гына булу белән бергә ул балалар психологиясен белмичә язылган. Нәни баланың урып салган арыш теземенең Муллык дигән шәһәр белән тоташканын күзаллавына, аңлавына иманым камил түгел. Образлы фикер йөртүдән узмаган бала аңында (ә бу китап мәктәпкәчә яшьтәгеләр өчен) мондый метаморфозалар, ассоциацияләр булдырып булмый. Бу шигырь балага эстетик тәрбия бирүдә дә, педагогик тәрбия бирүдә дә файда китерә алмый. Бу шигырь баланың белем офыгын да киңәйтми, фикер йөртә белү осталыгын да арттырмый. Ә баланы дөньяны дөрес итеп танырга, фикер йөртергә өйрәтү — ата-ананың да, балалар язучысының да олы максаты.

Күптән түгел мин менә мондый шигырь очраттым:

**ВОРОБЬИ**

Я насыпал проса.
Угадай, зачем?
Прилетели воробьи.
Угадай, зачем?
Приходила кошка.
Угадай, зачем?
Взял я в руки палку.
Угадай, зачем?

Менә мондый шигырьләр белән баланы уйланырга, эзлекле итеп фикер йөртергә өйрәтеп була, чөнки шигырьнең һәр юлы балага сорау бирә һәм баладан җавап эзләтә. Иң мөһиме, бала автор теләгән җавапларны үзе эзләп таба. Бу шигырь балага «Эврика» шатлыгын бирә, аңарда чыпчыкларны кызгану, ә мәчегә ачу хисе уята. Ягъни баланы аң-белем, фикерләү ягыннан да, эстетик яктан да баета бу шигырь. Әлеге яшь ата-аналар, күрәсең, шушындыйрак шигырьләрне таба алмый көрсенеп йөриләрдер. Кызганычка каршы, азрак шул алар, безнең балалар шигъриятендә азрак.

Балаларга сорау биргән шигырьләр безнең әдәбиятта байтак. Әнә Хәйдәр Гатин да «Бу юл кайларга илтә?» дип сорау куя да бала аңламаслык итеп булса да аңлатырга тырыша. Әрмән шигырендә сорау җавапны шигырь эчендә таба. Кабатлап әйтәм, җавап аңлашылмаслык булса да, аның шигырь эчендә булуы уңайрак сыйфат. Ә Заһирә Гомәрова болай ди:

Беркөн шулай Вәсилә
Үпкәли әнисенә:
— Әнием, — ди, — ник син, — ди, —
Миннән алда үстең? — ди.
Уйнар идек бергәләп,
Куар идек күбәләк.
*«Чын герой»*

Бу шигырьнең соравы шигырьнең үз эчендә дә, хәтта тышында да җавап таба алмый. «Синнән алда туганга, синнән алда үстем» дип әйтү, аңлату гына шигырьдәге сорауга җавап түгел, чөнки «синнән алда туганга» дигән нәрсә үзе балага аңлашылып җитми һәм яңа сорау тудыра. Аңарга җавап бирә-бирә, әллә кайларга барып җитү мөмкин. Ягъни шигырьнең соравы балага аңлашылмас дәрәҗәдә абстракт. Бәлки, шушындый шигырьләр баланы абстракт логикага, абстракт фикерләүгә өйрәтү өчен бик мөһимдер? Минемчә, мондый шигырьләр белән балага абстракт логика алымнарын өйрәтү мөмкин түгел. Моның өчен балага менә мондыйрак шигырьләр дә тәкъдим итеп була:

— Птица, птица красная,
Отчего ты красная?
— Поклевала красных ягод!

— Птица, птица синяя,
Отчего ты синяя?
— Поклевала синих ягод!

— Птица, птица белая,
Отчего ты белая?
— Поклевала белых ягод!

Бу шигырьләрдәге конкрет сорау (кызыл кош нигә кызыл?) һәм конкрет җавап (кызыл җиләк ашаганга) арасында абстракт умозаключение бар. Бу абстракт умозаключениене балага сеңдерер өчен автор сорауларны һәм җавапларны өч мәртәбә кабатлый һәм умозаключениегә канун, логик фикерләү алымы, төсе бирә. Ягъни: «Әгәр дә бу болай булса, ул болай, әгәр дә бу тегеләй булса, ул тегеләй». Ә «тегеләй» һәм «болай» төшенчәләрен бала практикада үзе теләсә ничек конкретлаштыра ала. Бу шигырьнең төп максаты, минемчә, матур төсләр, детальләр аша, аңлаешлы сораулар һәм җаваплар аша баланы абстракт фикер йөртергә өйрәтү, дөньяны эзлекле итеп танырга әзерләү. Бу максат шигырьдә ярылып ята. Ә безнең шигырьләргә максатның ачыклыгы, аның балалар психологиясеннән, яшь үзенчәлекләреннән үсеп чыккан булуы, бу максатның педагогика, эстетика таләпләренә туры килеп бетүе җитенкерәми. Безнең шигырьләрдә конкрет мәсьәлә куелмый. Дөрес, Шәүкәт Галиев, Рөстәм Мингалимов шигырьләре бик күп очракта конкрет мәсьәлә куялар һәм аны (бигрәк тә Шәүкәт Галиев) балалар психологиясен күз алдында тотып чишәләр. Ләкин балалар өчен шигырь язучылар шактый күп бит. «Бу шигырь балалар өченме, балалар турындамы?» дигән бик урынлы һәм проблемага әверелеп бара торган сораулар да, минемчә, һәр шигырьдә нинди дә булса максатның ачык булмавыннан килә кебек.

Кыскасы, мисалларны бик күп китерергә һәм алар тирәсендә шактый гына фикер куертырга мөмкин булыр иде. Моны матбугат битләрендә балалар әдәбияты белгечләре, тәнкыйтьчеләр эшләрләр, яшь ата-аналарга үзләренең зәвыкларын тәрбияләүдә, балаларны тәрбияләүдә зур гыйльми ярдәм күрсәтерләр әле дип ышанырга кала.

*1971*

# Самое верное — через произведения

Самое лучшее и верное литературное знакомство — это через произведения. Читаешь их и чувствуешь,

что твое сердце беседует с сердцами народов. Чем ближе мы подходим к празднованию 50-летия со дня образования великого, интернационального, воистину дружного и сплоченного Союза Советских Социалистических Республик, тем больше желания беседовать друг с другом, делиться радостями и достижениями. Произведения татарских прозаиков, поэтов печатаются на языках нашей многонациональной страны, пьесы татарских драматургов ставятся на сценах разных городов. Татарские писатели в свою очередь переводят произведения братских народов, а газеты, журналы, книжное издательство доводят их до сердец татарских читателей. Не это ли самая лучшая и верная дружба народов и искусств!

Азербайджанская литература знакома татарскому читателю через переводы на татарский через русский язык. На татарский язык переведены произведения С.Рустама, Расула Рзы, Гусейна Магди и многих других, изданы книги «Азербайджанские рассказы» и «Азербайджанские поэты», в тематический план Таткнигоиздата на 1972 год включен сборник произведений азербайджанских писателей «Волны Каспия». На сцене Татарского Государственного Академического театра с большим успехом шла пьеса «Айдын». Радостно вспомнить и то, что на сценах азербайджанских театров идут пьесы татарских драматургов Шарифа Хусаинова и Габдрахмана Минского. Это является сегодняшним продолжением тех традиций, начало которому положила встреча татарской театральной труппы «Сайяр» Абдуллы Кариева с азербайджанской труппой Араблинского.

Думается, что для дальнейшего расцвета такой дружбы в нашей стране имеются все условия, а литературам ее нужно только поддерживать и развивать. Исходя из этих побуждений, мне хочется сейчас вкратце рассказать об этапах развития татарской советской литературы, пустившей корни своих традиций в глубь восьми веков, помнящей и почитающей имена Кул Гали (XIII век), Мухаммедьяра (1539 год), Утыз-Имяни (1754 год) и конечно же — могучий талант Габдуллы Тукая, Галимджана Ибрагимова, Фатиха Амирхана.

Татарская советская литература родилась в дни Гражданской войны с революционным оружием в руках. Она воспевала революционную новь, борьбу за советскую власть. От произведений тех лет Маджита Гафури, Галиаскара Камала, Шамуна Фидаи, Зия Ярмаки и многих других по сей день пышет огнем революционного вдохновения, жаром самоотверженной борьбы за молодую республику Советов. В них мы видим зарождение образа нового человека — человека советского, с его героическим оптимизмом, неукротимой волей в достижении революционных целей, за осуществление идеалов Октября.

В двадцатые годы, когда борьба перекинулась от военных фронтов на разрушение старого уклада жизни и построение нового, в татарскую литературу, как и во многие литературы, проникли разного рода «измы», с одной стороны, вводя в заблуждение писателей, а с другой — помогая им свершать творческие открытия. В эти годы самой основной из творческих задач была задача создания литературы эпохи социализма. Проходя короткий, но бурный и сложный путь, испытывая благотворное влияние передовой русской советской литературы, татарская литература постепенно изжила ошибки и встала на правильную позицию развития. В этом большая заслуга поэтов Кави Наджми, Аделя Кутуя, Фатхи Бурнаша, Наки Исанбета, Хасана Туфана, оставивших неизгладимый, порой противоречивый след на путях развития литературы 20-х годов. Начав свою творческую деятельность поэтами, некоторые из этой плеяды стали потом известными прозаиками (Кави Наджми, Адель Кутуй) и драматургами (Фатхи Бурнаш, Наки Исанбет).

Из этой плеяды особо следует ометить одного из основоположников татарской советской поэзии Хади Такташа — поэта- трибуна, атакующего публициста, создавшего свою поэтическую школу. Если мы сейчас говорим об истинных поэтических традициях татарской советской литературы, то это разговор о традициях, созданных Такташем и развитых Мусой Джалилем, Хасаном Туфаном, Ахмедом Файзи и Сибгатом Хакимом.

В двадцатые-тридцатые годы был большой подъем и в прозе, и в драматургии. Именно в эти годы были созданы классические произведения татарской советской литературы: романы Г.Ибрагимова «Глубокие корни», «Наши дни», Шарифа Камала «Когда рождается прекрасное», повести Аделя Кутуя «Неотосланные письма», Мирсая Амира «Агидель», Гумера Баширова «Сиваш», пьесы Мирхайдара Файзи «Галиябану», Карима Тинчурина «Американ», «Без ветрил», «Потухшие звезды», произведения Шамиля Усманова, Тази Гиззата, Фатхи Бурнаша, Наки Исанбета и других. Произведения конца тридцатых годов, годов первых пятилеток, несли в себе уже совершенно новые по сравнению с двадцатыми годами качества. Начинает развиваться рабочая тематика, центральными героями становятся рабочие и крестьяне-колхозники.

Во время одного из выступлений поэт Алексей Сурков назвал татарскую поэзию солдатской поэзией. Эти слова в первую очередь воскрешают в памяти образ поэта-борца, Героя Советского Союза, лауреата Ленинской премии Мусы Джалиля, чей поэтический и гражданский подвиг звучит песней в сердце всего советского народа. Стихи другого выдающегося поэта-патриота Фатыха Карима, павшего смертью храбрых на подступах к Кенигсбергу (ныне — город Калининград) за два месяца до победы, также переросли в песни, отдельные строки и строфы превратились в афоризмы. Абдулла Алиш, Адель Кутуй, Хайретдин Музай, Нур Баян, Рахим Саттар! Их могилы далеко от родного Татарстана, от границ Советского Союза, но они вернулись к нам песней о борьбе.

После войны весь советский народ взялся за ликвидацию последствий войны. Раны страны постепенно заживали. Героем наших будней вновь стал созидатель. И в литературе начался новый подъем. Об этом говорят такие крупные произведения, как романы «Весенние ветры» К.Наджми и «Честь» Г.Баширова, удостоенные Государственной премии СССР, романы «Тукай» А.Файзи, «Орлята», «Газинур» А.Абсалямова, «Чистая душа» М.Амира, «Обыкновенные люди» И.Гази, «Тропою пешехода» Ф.Хусни, «Когда расходятся

пути» А.Расиха, повести А.Еники «Спасибо, товарищи!», «Болотный цветок», «Тайна сердца».

После войны облик Татарстана обогатился новым качеством, республика стала нефтяным центром страны. Сегодня одну треть всей нефти страны дает Татарстан. Расцвет облика республики повлиял и на развитие татарской советской литературы. Появились романы, повести, стихи и поэмы о нефтяниках. Романы И.Гази «Обыкновенные люди» и Г.Ахунова «Клад» и «Хозяева», поэма лауреата премий имени Г.Тукая и М.Горького поэта Сибгата Хакима «Через кручи» снискали искреннюю любовь у читателя.

На фронтах сегодняшней поэзии работают десятки талантливых поэтов: Хасан Туфан, Ахмед Исхак, Нури Арсланов, Заки Нури, Салих Баттал, Гамиль Афзал, Шаукат Галиев, Ахсан Баянов, Ильдар Юзеев, Хисам Камалов, Наби Даули, Саджида Сулейманова. К ним на смену и на помощь пришли молодые, своеобразные поэты Роберт Ахметжанов, Равиль Файзуллин, Гарай Рахим, Рустем Мингалимов, Радиф Гатауллин, Рашид Ахметзянов и многие другие. Продолжая традиции своих предшественников и учителей, они принесли в татарскую поэзию новую, порой спорную, но здоровую струю.

Своими новыми произведениями радуют драматурги Шариф Хусаинов (автор пьесы «Приехала мама», идущей на сцене Сумгаитского театра), Аяз Гилязов, Юнус Аминов, Туфан Миннуллин, детские писатели Лябиба Ихсанова, Джавад Тарзиманов, Гариф Губай, Амина Бикчантаева, лучшие из которых переводятся на языки народов страны.

Сегодня на берегу Камы-реки строится Нижнекамский химкомбинат и невиданный в истории страны Набережночелнинский автомобильный завод, объявленный всенародной стройкой. Строят его молодые, средний возраст которых всего 23 года.

Сейчас наши писатели считают себя летописцами этого автогиганта. Идет только второй год этого строительства, а наш писательский журнал «Казан утлары» уже печатает роман Ахсана Баянова «Огонь и вода», в редакторском портфеле журнала ждут своей очереди романы Махмута Хасанова, Шамиля Бикчурина, Эдуарда Касимова, повесть Мусагита Хабибуллина.

Когда-то А.С.Пушкин говорил, что, глядя только на литературную критику, можно определить степень образованности всей литературы. Развитие литературы действительно немыслимо без развития критики. За последние годы наши литературоведы и критики создали ряд крупных монографий о творчестве писателей, ряд исследований отдельных проблем нашей литературы. Так что литературоведение и литературная критика стали наукой о татарской литературе в подлинном смысле этого слова.

Накануне большого праздника всех советских народов, их литератур и искусств, о татарской литературе можно сказать следующее: она развивалась в направлении сближения с жизнью, отдавая дань каждому периоду ее развития и помогая народу в его созидательном труде.

Конечно, даже в большой статье трудно воссоздать истинную и полную картину развития такой большой литературы как татарская. Я ограничился перечислением имен основных писателей и их произведений с надеждой на то, что это будет ключом для азербайджанского читателя к самому лучшему и верному знакомству — знакомству через произведения татарских писателей.

*1972*

# Поэзия в газете «Социалистик Татарстан»

*(Выступление в ОК КПСС)*

За последние годы газеты республики уделяют большое внимание вопросам литературы, литературному процессу и самим художественным произведениям. Вслед за газетой «Социалистик Татарстан» организовала ежедневную литературную полосу и «Советская Татария», где постоянно публикуются произведения русских писателей нашей республики и самые свежие переводы произведений татарских писателей. Когда не было этих специальных полос, и у читателей, и у писателей, и у литературной общественности к газетам была одна-единственная претензия — почему мало печатаете художественных произведений? С появлением специальных полос, посвященных литературе и искусству, увеличились обьемы литературно-художественных материалов, и количество отзывов о них. Короче говоря, эти полосы сейчас являются и площадкой, где происходит литературный процесс, и экраном, через который мы имеем возможность как-то следить за этим процессом, и школой, активно влияющей на формирование вкусов и эстетического идеала нашего читателя. И можно смело утверждать, что эти специальные полосы в общей своей сути верно отражают развитие нашей литературы, своевременно фиксируя ее достижения и недостатки, заостряя внимание читателей на ее важнейших проблемах. В обеих газетах материалы по литературе и искусству публикуются еженедельно в воскресном номере, а кроме этого, во многих номерах в течение недели. Очевидно, такое количество материалов требует у малочисленной группы сотрудников отделов культуры газет большой энергии и оперативности. Но они стараются, успевают подготовить материалы. А все-же, как мне кажется, объем их работы превосходит количество рабочей силы, а это, наверное, не на пользу газете.

Мне было предложено высказать свое мнение об опубликованных на страницах газеты «Социалистик Татарстан» произведениях поэзии. За 1 полугодие 1973 года в 32 номерах газеты состоялось 52 публикации поэтических произведений 34 авторов. Всего напечатано 91 произведение. По моим грубым подсчетам, это более 2000 стихотворных строк, то есть солидная книга стихов в 3 печатных листа. Так что ни поэты, ни любители поэзии, ни литературная общественность не могут быть недовольными количеством публикаций. А

поэт Галимзян Латыйп, стихи которого опубликованы 5 раз, как самый популярный поэт газеты должен быть даже очень-очень благодарным.

Приятно отметить жанровое разнообразие опубликованных произведений. Здесь и цикл стихов С.Хакима «Күңел кыялары» и стихи-обращения Наби Даули «Табигать исеменнән», «КамАЗ машинасы миңа кирәк», и сатирическое стихотворение Ш.Галиева «Сәер кеше», и монолог Г.Афзала «Йөрәк яна», и стихи-фельетоны С.Гилемханова «Атым да бар, чанам да бар» и пародии Ф.Хузина «Сөйләнү» и т.д. и т.п. И тематика публикаций довольно-таки широка. Здесь стихи о Родине, труде, природе, войне и мире, о селе, КамАЗе... После прочтения всех стихов у меня сложилось такое впечатление, что газета представляет своего читателя только за станком, на поле, за рабочим столом, а между тем его рабочее настроение формируется и дома, в кругу семьи, возле любимой или любимого, среди друзей. На все великие подвиги человека вдохновляла и вдохновляет любовь, звала и зовет романтика. А о любви «Социалистик Татарстан», мне кажется, не совсем любит писать и публиковать такие стихи. Если публицистические стихи входят в сознание читателя как призыв, задача, то лирика духовно подготавливает человека выполнить эту задачу. Если плюс ко всему положительному, что имеет «Социалистик Татарстан» в тематическом отношении, учесть и эту психологическую сторону поэтического дела, то было бы еще лучше. На мой взгляд, фетишировать только тему в ущерб качеству не следует. Иногда стихотворение печатается только потому, что в нем есть слово КамАЗ, Вьетнам или агроном. Например, в № 32 стихотворение Ш.Маннапова «Тимерче гомере», в № 36 стихотворение М.Скороходова в переводе Г.Сафина, в № 18 стихотворение Г.Латыйпа «Көн дими». У Галимзяна Латыйпа также опубликовано стихотворение «Әмәк белән Җәмәк», в 45 строчках которого автор совсем не смешно пытается рассказать известный анекдот о том, как двое пьяных в темноте натыкались на столб и один из них, намучившись, сказал: «давай лучше переждем, пока столбы не перебегут через дорогу». Это стихотворение, не имеющее ценности как художественное произведение, опубликовано, очевидно, только ради отклика на известное постановление о борьбе против пьянства; но отклик можно было бы сделать посолиднее. Примерно так же можно было бы оценить стихи Дж.Дарзаманова о субботнике «Колачы кин» № 95 и стихотворении М.Садри «Без сайлыйбыз» в № 140. И о субботнике, и о выборах в местные Советы можно было бы сказать гораздо лучше в публицистической заметке. Отдел культуры газеты, выполняющий большую и благородную работу, в таких случаях должен ограждать стихотворение от неразумного его использования. Если уж печатать, то печатать действительно такое художественное произведение, в котором взятый материал будет звучать и после кампании.

Под рубрикой «Дружба литератур — народов дружба» газета «Социалистик Татарстан» знакомит своих читателей с образцами литератур братских народов. За этот период опубликованы стихи Марка Лисянского, узбекского поэта Н.Нарзуллаева, грузинского поэта Шота Роква, башкирских поэтов Г.Рамазанова и Р.Янбулатовой. Стихи узбекского и грузинского поэтов, возможно, много потеряли в процессе перевода. Но это не может быть оправданием для их публикации. В таких случаях нужно быть требовательнее к переводчикам. Их халатность создает отрицательное отношение и к поэту, и к литературе, которую он представляет. Башкирскую поэтессу Р.Янбулатову газета представила читателю при помощи эпитета «известная» (күренекле) и опубликовала в № 143 два полуученических стиха «Бозлар киткәндә» и «Ак яулык», состоящих из перепетых деталей и настроений. Вот такое преподнесение материала дезинформирует, вводит читателя в заблуждение, создает несерьезное отношение и к литературе, и к писателю.

Кстати, в № 38 опубликованы доклады общего собрания писателей по итогам литературного 1972 года. Газета пишет, что критик Т.Галиуллин в число неудач литературного года отнес книгу Роберта Ахметжанова «Идел-йорт». А на самом деле критик в своем докладе назвал эту книгу одной из самых лучших поэтических книг 1972 года и подробно проанализировал ее удачи. Газета пишет о том, как критик Азат Ахмадуллин отрицательно оценил пьесу Т.Миннуллина «Ат карагы», тогда как докладчик этого не говорил, ибо произведение не опубликовано, не поставлено и никак не могло попасть в руки Ахмадуллина. Этим самым газета поставила в неловкое положение Ахмадуллина, во-вторых, совершила юридически недопустимый проступок, в-третьих, и самое главное, создала вокруг будущего произведения Т.Миннуллина предвзятое мнение.

Несколько слов о подаче (верстке) поэтических произведений. Я не знаю для кого как, а для меня бывает очень трудно подступиться и приступить к чтению стихотворения, зажатого со всех сторон так, что строки его сломаны там, где не положено. Такие строки и стихи с такими травмами трудно воспринимаются, ибо внимание раздваивается: то ли следить за логикой образов, деталей стиха, то ли следить за логикой предложения. Желательно бы помещать стихи попросторнее, не ломая их естественную форму, выделив его и местом и шрифтом, чтобы чувствовалось уважение и внимание газеты к печатаемому стиху. Это внимание обязательно будет замечено читателем, и у стиха повысится «коэффициент полезного действия».

Из всего прочитанного особо яркое впечатление оставляют публикации циклов стихов С.Хакима (12 стихотворений), Г.Рамазанова (4 стихотворения), З.Нури (7 стихотворений). Нет, не потому, что они или очень сильные, или очень слабые, а потому, что они солидно поданы. Они запоминаются и своим объемом, и тем, что в большой подборке больше граней для соприкосновения с сердцем читателя. Например, об этом цикле стихов С.Хакима уже можно написать литературно-критическую статью, с полной характеристикой определенного творческого этапа поэта. Желательно и впредь давать большие, цельные подборки отдельных авторов, нежели давать их стихи несколько раз, но по одному, по два стихотворения. И сопровождать такие капитальные подборки портретом поэта.

А в общем-то, литературная полоса газеты «Социалистик Татарстан» хорошая. У нее есть свое опреде-

ленное лицо, сохраняющееся вне зависимости от изменения темы, проблемы. Ей не откажешь и в оперативности освещения самых важных культурных событий республики. Она старается быть точкой пересечения, вернее, точкой слияния литературы с жизнью. А высказанные замечания и пожелания, по-моему, естественны, ибо мы собрались сегодня для того, чтобы еще более повысить культуру, идейную и эстетическую грамотность литературных полос.

Напоследок у меня одно конкретное предложение: для того, чтобы помочь отделу культуры газеты «Социалистик Татарстан» в отборе лучших поэтических произведений для публикации, очевидно, есть необходимость прикрепить одного, двух опытных поэтов в качестве литературных консультантов.

*24 июня 1973*

# 1975 ел шигърияте турында

Безнең бүгенге шигъриятебезнең хәл-әхвәле, аның казанышлары, җитешсезлекләре, минемчә, күпсанлы шигырь сөючеләргә дә, әдәбиятыбызның һәр жанрындагы үзгәрешләрне җентекләп күзәтеп, тикшереп баручы әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләренә дә, каләмдәшләре иҗатына битараф була алмаган һәр язучыга да билгеледер. Әле күптән түгел генә «Казан утлары»ның алты санын тикшергәндә, аннан алдарак — язучыларыбызның VIII съездында, элгәрерәк даими үткәрелеп килә торган төрле җыелышларда шигъриятебезнең бүгенге дәрәҗәсе турында гомуми мәгълүмат бирерлек төрле камиллектәге сөйләшү-киңәшүләр булды. Ләкин безнең бүгенге максатыбыз — 1975 ел шигъриятенә игътибарлырак карау, аның ел дәвамында кичергән үзгәрешләрен мөмкин кадәр ачыграк күрергә һәм билгеләргә тырышу. Ләкин бу быел җиңел эш түгел. Шигърият, акыл һәм хис җимеше буларак, акыл һәм хис кебек үк бик тә акрын үзгәрә.

Дөрес, бер ел эчендә берәр шагыйрьнең таланты гөрләп ачылып китүе мөмкин, икенче бер шагыйрьнең иҗат итүдән туктавы ихтимал, көтмәгәндә шигъри офыкта бер яшь талантның пәйда булуы мөмкин, ниһаять, арадан беребезнең, бер бик акыллы тәнкыйтьченең барлык киңәшләрен дә тотып, калганнарыбызның борынына чиертеп, даһи бер әсәр язып ташлавын да көтәргә була. Әдәбият мәйданындагы мондый үзгәрешләр шигърияткә дә, һичшиксез, йогынты ясарлар иде, һәм бу йогынты күзгә бик ачык күренер иде.

Ләкин 1975 елда безнең әдәбият мәйданында мондый үзгәрешләр булмады кебек. Барыбыз да, бәхеткә каршы, исән-сау, барыбыз да кулдан килгәнчә язабыз, иҗат итәбез, барыбыз да мөмкин булганча газета-журналларда басылабыз, китаплар чыгарабыз. 1975 елда дөнья күргән шигъри әсәрләрне махсус максат белән күз һәм күңелдән кичергән кеше буларак, шунысын да әйтә алам: көтмәгәндә кабынган ут йә яңгыраган җыр кебек игътибарны ирексездән үзенә тарткан яшь талантлар һәрхәлдә миңа быел күренмәде. Шул ук вакытта җитешсезлекләре белән шигъриятебезнең бүгенге дәрәҗәсеннән бик нык аерылып торган әсәрләр күп очрады дип тә әйтеп булмый.

Татарстан китап нәшриятының 1975 елгы тематик планына кертелгән барлык шигырь китаплары да чыгып җитсә, безнең шәхси китапханәләребезгә татарча басылган тагын 13 китап өстәлер иде. Дөрес, бу санга мин балалар өчен чыккан китапларны кертмим, фәкать өлкәннәр редакциясеннән чыккан исемнәрне генә алам, чөнки, белгәнемчә, балалар әдәбияты турында махсус доклад бар. Унөч китапның сигезе — Муса Җәлилнең ике томы, Габдулла Тукайның ике томы, Хәсән Туфан икетомлыгының бер томы, Әхмәт Исхакның «Шигырь китапханәсе» сериясендәге китабы, Фәнис Яруллинның «Аерылмас дустым» дигән җыентыгы, Шәүкәт Галиевнең «Тамчылар тамар чаклар» дигән китабы — безгә күптән мәгълүм шигырьләрдән торган переизданиеләр, икесе — «Әрмән шагыйрьләре» һәм Марс Шабай тәрҗемәсендә чыккан Уолт Уитмен шигырьләре — тәрҗемә китаплар, «Тукайга чәчәкләр» — шулай ук безгә билгеле әсәрләрне туплаган китап. Бары Зәки Нуриның «Яңа сукмаклар» дигән китабы һәм Галимҗан Латыйпның «Йөрәгем синең белән» дигән җыентыгы гына яңа шигырьләрдән тора. Оригиналь шигырь китапларының ике генә булуы, күрәсең, ел хасияте белән аңлатыладыр — Тукайның 90 еллыгы, Җәлилнең 70 еллыгы. Бу олы юбилейлар безнең күңелләргә генә сызылып түгел, мәңгелеккә ташка да язылып калырга тиешле әдәби вакыйгалар.

Соңгы ике-өч ел эчендә газеталарыбыз шигъри әсәрләрне, минемчә, сайлап булса да бик теләп басалар. 1975 елда «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре» битләрендә дөнья күргән шигырьләр шулай ук элекке еллар чамасында. «Казан утлары», «Азат хатын» журналларында да эш шулайрак тора.

Гомумиләштереп әйткәндә, шигырьнең сан белән билгеләп, күз белән күреп, үлчәүгә салып үлчәп була торган сыйфатлары ноктасына басып бәһаләгәндә, минемчә, 1975 ел безнең шигъриятебез өчен гадәти ел булса кирәк.

Икенчедән — аның асылын, күрәсең, шигырь китаплары түгел, ә вакытлы матбугатта чыккан әсәрләр билгелидер, һәм безгә дә төп игътибарны газета-журналларда, бигрәк тә «Казан утлары»нда басылган шигырьләргә юнәлтергә туры килер.

Ә шулай да сүзне китаплардан башлыйк.

Галимҗан ага Латыйпның «Йөрәгем синең белән» дигән китабы тематик яктан шактый бай. Анда без туган якларыбызның таңы, төне, көне, киче, елның дүрт фасылы, яшьлек, картлык, сабан туе, төзелеш, сугыш хатирәләре, мәхәббәт турындагы шигырьләрен очратабыз, бүгенге көн кешесенең күңелендә һәм күзендә һәрвакыт була торган шатлыкларга, борчуларга, шикләнү, өметләнүләргә кагылып үтәбез. Шагыйрь, гражданин буларак, вакыт агышын яхшы сизеп-тоеп яшәүче кеше буларак, Бөек Ватан сугышы каһарманнары турында да, игенчеләрнең фидакарь хезмәте турында да, ерак Америкада барган вакыйгалар турында да, Казан мәктәпләренең берсендәге музей турында да уй-фикерләрен әйтергә ашыга, тойгылары белән уртаклаша.

Тема байлыгы Галимҗан ага Латыйпның барлык китапларына да хас сыйфат һәм «Йөрәгем синең белән» дә бу традициягә тугрылыклы булып калган.

Китапта күзгә ташланган күркәм сыйфатларның тагын берсе — шигъри форма төрлелегенә омтылу. Бу китапта без дүрт юллы гадәти строфалар белән бергә җидешәр, алтышар юллыларын да очратабыз, строфасыз шигырьләр янында үзләрен бик иркен тойган дүртьюллыкларны да күрәбез. Строфаларның, шигырь юлларының эчке структуралары күзлегеннән караганда да Галимҗан аганың форма ягыннан эзләнүчән шагыйрь икәне күзгә ташлана. Барыбызның да шигъри арсеналында ныклы урын алган 10–9, 8–7, 8–8 һәм башка үлчәмнәр белән бергә китапта шактый үзенчәлекле яңгыраш тапкан 8–3, 4–4 белән язылган шигырьләрне дә укыйбыз.

Галимҗан ага Латыйп бу китабында шигырь жанрларыннан да мөмкин хәтле тулырак файдаланырга тырышкан. Монда «Хәер — хак булсын», «Яшә, яшьлек!» кебек сюжетлы шигырьләр дә, «Җырчы чыршы» кебек шигъри легенда да, «Истә — хәтердә» дигән Севастополь оборонасының 30 еллыгы уңае белән язылган шигъри репортаж да, «Бүкән» дигән мәсәл дә, «Өмәк белән җәмәк» кебек фельетоннар да бар. Г.Латыйпның бу китапка тупланган башка шигырьләре кебек үк, әйтеп узган әсәрләр дә бүгенге көн кешесенең уй-фикерләре турында сөйлиләр, тормышның кайбер күренешләрен җанландырып, зурайтыбрак күрсәтәләр.

«Йөрәгем синең белән» дигән китапта, билгеле, матур-матур юллар, оригиналь строфалар, зур шагыйрьләрчә тотып алынган шигъри детальләр һәм образлар да байтак. Шагыйрь чирек гасырдан соң Можайск урманнарына барып чыга.

Очрый монда солдат каберләре,
Бил тиңентен сынган имәннәр.
Алар һаман сызгыралар әле
Каршы яктан искән җилләрдән.

*«Кышкы урман»*

Бу бил тиңентен сынган һәм теге яктан, безгә һаман да янарга маташучылар ягыннан, искән җилләрдән сызгыра торган сизгер имәннәр Можайск урманнарында түгел, ә этисен, бабасын, баласын, сөйгәнен фронтта югалткан һәр өйнең, һәр йөрәкнең түрендә утыралар кебек.

Шушындый шигырьләр белән янәшә, кызганычка каршы, шактый йомшакларын да, беркатлыларын да күпләп очратабыз. Хәтта Г.Латыйп кебек тәҗрибәле шагыйрьгә гафу ителмәслек юллар да килеп чыккалый. «Кичен генә салкын яңгыр яуды» шигырендә ул ни өчендер бик шикләнеп, бик куркынып: «Томансызмы күңел пәрдәләрем, үз урынындамы ирлегем?» — дип, үз-үзенә шактый уңайсыз сорау бирә. Шигырь юллары арасында Гималай йә Һималай урынына «Гемалай», Василий Теркин урынына «Василий Тюркин» булып киткән, авторның үз каләменнән башланган, редактор күрми калган хаталар килеп чыгып, кәефне тагы да бозып җибәрәләр. Хәреф хаталары турында сүзне, бәлки, артык куертмаска да кирәктер. Ләкин бу хаталар, минемчә, специфик хаталар һәм алар авторның гомуми грамоталылыгы хакында шик уятырга мөмкин. Укучыда шундый шик уяндымы, ул инде безнең шигырьләрне дә кальбе белән бирелеп, шашып укымаячак. Димәк, хәреф хатасы аркасында укучы алдында шагыйрьнең дә, шагыйрь аша әдәбиятның да дәрәҗәләре төшәчәк.

«Йөрәгем синең белән» китабын Г.Латыйпның уңышсызлыгы дип тә, уңышы дип тә әйтеп булмый. Бу китапта без Г.Латыйпның бөтен иҗатына хас уңай яклар белән дә, кимчелекләр белән дә тагын бер тапкыр очрашабыз. Уңышлары турында әйттем кебек инде, ә хәзер, минем фикеремчә, җитешсезлекләр турында. Мин хәзер әйтәчәк кимчелекләр, билгеле, Галимҗан аганың йомшаграк шигырьләренә хас күренешләр, ләкин алар аның көчле шигырьләрендә очрап, аларны да бозгалап куялар.

Г.Латыйпның бу китапка кергән байтак шигырьләрен таслап тезелгән, ныклап төзелгән бөтен әсәр дип әйтүе кыен. Шигырьнең исеме сине бер уйга этәрә, уртасы икенче якка алып кереп китә, ахыры өченче нәрсә турында сөйли. Бу кисәкләр бер-берсенә ябыша алмыйлар, һәм әсәр аңлашылмый кала. Башка шигырьләрдән мисал китереп тормас өчен, бер шигырьне, әлбәттә, кыскарагын, тулаем укыйсы килә.

Җил искән саен
Бөгелә каен,
Сыгыла каен.
Шул каенга
Сөяләм мин
Шатлыгым, кайгым саен.

Шатлыклар кайчак азрак,
Кайгылар артып китә.
Кайгылар күбәйгән саен,
Шатлыклар килеп җитә.

Шатлыклар килеп җитә дә
Чөяләр югарыга.
Гел кояш нурлары гына
Сибәләр юлларына.

Ачыла күгем,

Таңнарым,
Яп-якты киләчәгем.
Мин беләм,
Беләм һәр җирдә
Гайбәтнең үләчәген.
Гаделлек, хаклык хакына
Шатлыкның җиңәчәген.

Бу шигырьдә очрый торган җитешсезлекләр кайбер яшь һәм бик үк яшь тә булмаган каләмдәшләребездә дә очраганга күрә, аны тукталыбрак анализлыйсы килә.

Беренче строфада: җил, каен, кайгы, шатлык.

Икенче строфада кайгының кайчан килгәне, шатлыкның кайчан килгәне турында сөйләү.

Өченче строфада инде җил дә, каен да, кайгы да юк, кояш нурлары, юллар, ягъни яңа детальләр килеп керә.

Дүртенче строфада җил дә, каен да, кайгы да, юллар да, кояш нурлары да юк. Анда автор ни сәбәптәндер гайбәтнең үләчәге хакында сөйли. Бер карасаң, якты гына, җылы гына, матур гына шигырь кебек, бер карасаң, буталчык һәм шундый шигырьләр, кызганычка каршы, барыбызда да бар.

Шушы шигырь һәм Галимҗан аганың башка бик күп шигырьләре нигезендә бүгенге татар шигъриятенә хас тагын бер кимчелекне әйтеп үтәргә мөмкин. Бу — таушалып, каеш бүрек кебек ялтырап беткән тәгъбирләрдән, образ-детальләрдән, ситуация-вакыйгалардан кирәгеннән артык файдалану. Таң атулар, нурга төренүләр, аякка басулар, легендага әйләнгән гомерләр, күңелгә ятышлы җылы җилләр, узмаган кебек яшьлекләр, бер-бер артлы үткән көннәр һәм башкалар, һәм башкалар китаптан китапка, шигырьдән шигырьгә, шагыйрьдән шагыйрьгә күчеп йөри-йөри булган символик мәгънәләрен дә югалтып бетерделәр инде. Шундый буш сүз тезмәләре очраган урында шигырь сына, сызлана, укучының гайрәтен чигерә.

«Йөрәгем синең белән» дигән китап турында фикеремне йомгаклап тагын шунысын да әйтәсе килә: аның лирик герое рухы белән яшь кеше, бүгенге заман кешесе. Аның йөрәге яшь, хәтере нык, дәрте ташып тора, кыю, шаян. Димәк, бу сыйфатлар Галимҗан аганың үзенә дә хас сыйфатлар. Йөрәге яшь, күңеле көр тәҗрибәле әдип үзенә карата әйтелгән тәнкыйть фикерләрен зирәк аксакалларча кабул итәр дигән өметем бар.

Зәки Нуриның «Яңа сукмаклар» дигән яңа җыентыгы өч бүлектән тора. Беренче бүлеккә шагыйрьнең ил, хезмәт, дуслык турындагы лирик һәм публицистик шигырьләре тупланган, икенче бүлеге мәхәббәт, яшьлек темасына багышланган шигырь һәм җыр текстларыннан тора, ә өченче бүлектә юмор-сатира әсәрләре. Китапның шушылай бүленеше генә дә Зәки аганың күпкырлы шагыйрь, шигъриятнең барлык өлкәләрендә һәм жанрларында да җиң сызганып эшләүче әдип икәнлеген күрсәтә. «Яңа сукмаклар»ның тематик һәм географик диапозоны да киң. Памир, Әлмәт, Чаллы, Кисловодск, Улан-Батыр, Кызыл-орда, Красноярск — шагыйрьне илһамландырган, укучыларга ниндидер фикер әйтәсе килүне уяткан җирләр, шәһәрләр.

Бу китапның үзәге булган төп тема, минемчә, кеше һәм сугыш темасы. Совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 30 ел тулган елны чыккан китап өчен, фронтовик шагыйрь өчен шулай булуы табигый дә. Зәки ага Нуриның шушы китаптагы иң уңышлы шигырьләре дә, минемчә, сугышка, сугыш хатирәләренә, сугыштан исән килеш кайту бәхетенә ирешкән кешеләргә багышланганнары. Менә шундый кешеләрнең берсе, разведкада йөргән, разведчикның кайбер сыйфатларын үз йөзендә бүген дә саклаганы. Дөресрәге, шул кешенең күзләре:

Үзләре сирәк кашлылар,
Үзләре кысык кына, —
Күпне күзәткәнгә, ахры,
Яшеренеп, посып кына.

Әйе шул, булган, күзәткән
Уңсынга сугыш эше,
Дошман эзеннән йөргәндә
Сагаеп карый кеше.

Ә керфекләр? Беләм, алар
Атылганнар ук булып.
Шулар юлыннан күзләргә
Шатлык кайткан ут булып.

*«Аның күзләре»*

«Май ае балладасы»нда без сугышта үлгән улына охшаган егет очрамасмы дип, аңа бүләк итәр өчен чәчәк бәйләме тотып торган бер карчык белән очрашабыз.

Әйтмәде чал ана кай көндә, кай якта
Бердәнбер улкаен кем ничек күмгәнен...
Ә егет әйтмәде, быел, май башында,
Әнкәсе нәрсәдән һәм ничек үлгәнен.

Менә тагын бер строфа. Ул «Яралы яфрак» шигыреннән.

Искә төште кинәт: шул ук корыч
Бер анага ничек тигәне,

Ә яралы нарасые аның:
«Мин ник, әни, кызыл?..» —

дигәне.

Сибгат ага Хәкимнең «Дуга» поэмасында бер эпизод бар: кеше кебек елаганга күрә генә фашистлар тарафыннан атып үтерелгән төлке балалары ак карда салып ташланган бияләйләр сыман аунап яталар. Фашистларның ерткыч рухларын, ерткычлык белән сугарылган аңнарын, кешесезлекләрен бер штрих белән шушылай күрсәтеп биргән башка шигъри детальне мин үзебезнең хәзерге поэзиядә белмим. Зәки ага Нуриның да бу строфасы, минемчә, сирәк очрый торган әдәби табыш, чөнки анда зур гомумиләштерү көче белән бергә бик ачык, бик гади образ бар.

Ара-тирә әнә шундый строфалар, шигырьләр очрый торуы «Яңа сукмаклар»ның беренче бүлеген кызыклы итә.

Китапның «Яратуны ярату» дигән икенче бүлеген мин, мәсәлән, үзем яратмадым. Бу бүлеккә мәхәббәткә багышланган шигырьләр һәм җырлар тупланган, ләкин алар арасында мин шагыйрьнең кемгәдер пышылдап кына, сакланып кына, тартынып кына әйткән сүзләрен очратмадым. Андагы шигырьләрдә зур хисләр, олы кичерешләр юк. Һәр шигырен Зәки ага ниндидер бер зур залга, аудиториягә, йөзләгән кешегә сөйлидер кебек. Ә мәхәббәт шигыре, минемчә, кемнеңдер үзенә генә, күзеңне дә күтәрергә кыймыйча, калтырана-калтырана әйтелгән сүзләрдән туадыр.

Безнең укучыларыбызга, минемчә, кемнедер яратуыбыз турында бер-беребезгә сөйләгәнне тыңлаганга караганда сөйгәнебез белән нәрсә турында, ничек сөйләшкәнебезнең үзен ишетү кызыклырак.

Шушы урында беразга тукталып, 1975 елның тагын бер хасияте турында әйтеп үтәсе килә — бу ел халыкара хатын-кызлар елы иде бит. Ел үзе «сөеклең турында яз, әниең турында яз!», «иң катлаулы, иң мактаулы, иң авыр эшләргә дә үзләренә генә хас батырлык белән тотынучы эшче хатын-кызлар турында яз!» дип торганда, алар турында быел, бер карасаң, поэмалар, шигырь цикллары, балладалар, һич югы, матур-матур шигырьләр күпләп язылырга тиеш иде. Тиеш булганга гына түгел, гомумән, матурлыкның, сәнгатьнең нигезендә хатын-кыз образы ятканга күрә дә! Ләкин китапларда да, алдан да әйтеп куям, вакытлы матбугат битләрендә дә хатын-кызга багышлаган, хатын-кыз мәхәббәтенә, аның тугрылыгына, аның хыялларына, хезмәтенә багышланган шигырьләр күп күренмәде. Күренгәннәре дә тасвир шигырьләр, берәр исемгә багышланган төссез, сентименталь шигырьләр генә. Татар әдәбиятында хатын-кызларның иң шигъри, камил образлары прозада, «Кара йөзләр»дәге Галимә, «Тапшырылмаган хатлар»дагы Галия, «Акчарлаклар»дагы Газизәләрне генә телгә алу да җитә. Поэзиядә Такташның «үзе усал, үзе болай бер дә усал түгел кебек шикелле» Алсуы — безнең өчен һаман да үрелеп карый торган биеклек. Без ярата белмибез дип әйтмим. Беләбез, ләкин сөйгәннәребезне күкләргә чөя белмибез, үзебезнең идеалыбыз, хыялыбызга тиң образ иҗат итә алмыйбыз. Безнең шигырьләрдәге хатын-кызлар шәхес түгелләр — уенчыклар. Татар шигърияте татар хатын-кызлары алдында һаман да бурычлы.

Сүзне Зәки аганың китабы турында дәвам итик. «Яңа сукмаклар»ның өченче бүлеге китапның яртысын тәшкил итә. «Шаян утлар, усал уклар» дигән исемнән үк күренгәнчә, без бу бүлектә сатира һәм юмор әсәрләре белән очрашабыз.

Сатирик, юмористик шигырьләрне күпмедер дәрәҗәдә канәгатьсезлектән, тормышның кайбер күренешләре хакында чын йөрәктән борчылудан туган әсәрләр дип бәяләп буладыр. Мондый әсәрләргә әдәбият тарафыннан, җәмгыять тарафыннан йөкләтелгән бурычларның берсе — укучыга гүзәллекне, чисталыкны, пакьлеккә омтылу хисе йоктыру.

Безнең әдәбиятта юмор, сатира тармагының тамырлары тирән — Тукай, Такташ, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзиләрдән. Бүгенге көндә бу тармак Әхмәт Исхак, Гамил Афзал, Шәукәт Галиев иҗатларында матур дәвам һәм чагылыш таба. Зәки ага Нуриның да бу өлкәдә хезмәте зур. Аны соңгы елларда сатира һәм юмор әсәрләре язучы иң актив татар шагыйре дисәк тә ялгышмабыз. «Яңа сукмаклар»га кергән сатира һәм юмор шигырьләре арасында «Мактанышу», «Милициягә һәм милициядән», «Турысын әйтте», «Бер кыз әйтте», «Тун трагедиясе» кебек кыска да, оста да язылганнары да аз түгел. Телгә алынган шигырьләрдә яхшы анекдотларга хас тапкырлык, тәҗрибәле шагыйрьләргә хас зәвыклылык, җор теллелек бар. Бу шигырьләр мөһим проблемаларны тиешле әдәби югарылыкта күрсәтәләр. Ә менә «Бу уклар кемгә тияр?» һәм «Чәнчеп-чәнчеп алабыз» бүлекчәләрендәге шигырьләр кыскалыкка кыска, әмма осталыкка килгәндә, тирәнлеккә килгәндә... Мәсәлән:

— Яхшы китап бер укуда ятлана,
Алар — эштә, алар — кулдан төшмиләр.
— Ә нәширләр кат-кат басып бүтәнне
Нигә икән киресенчә эшлиләр?

*«Ник киресенчә?»*

— Шәп беләсең психоанализны,
Темаң җитди, көчле сүз әйттең.
— Материалны чөнки яхшы беләм:
Хатынымның холкын күзәттем.

*«Диссертация яклагач»*

— Йөз сум акча биреп торчы?

— Күргәнем юк, белмим, кем соң син?
— Белүчеләр хәтта бер тиен бирмәс,
Биргәндә дә миңа мең сум син.

*«Үтә беркатлы кеше»*

Ул бары тик Нуль, ләкин масаер
Мин дә керәм дип сан исәбенә.
Санаулы була алганын белми,
Алдына бүтән сан куйсаң гына.

*«Буш сан»*

Кыскасы, китапта әнә шуңа охшаш 155 шигырь бар һәм алар «Яңа сукмаклар»ның барлык ямен алып торалар. Дөрес, алар арасыннан бер 15–20 әйбәт кенә дүртьюллыкны сайлап бастырганда китап өчен начар булмас иде, бәлки.

Ә хәзер сүз вакытлы матбугатта чыккан шигъри әсәрләр хакында.

Алда билгеләп үткәнебезчә, соңгы елларда газета-журналларыбыз шигырьгә урынны кызганмый бирәләр. Бер ел эчендә «Казан утлары» журналында гына да кырыкка якын шагыйребезнең әсәрләре басылган, «Азат хатын», «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре» дә «Казан утлары»ннан калышмаганнар.

Китапта чыккан шигырьләрдән вакытлы матбугатта басылган шигырьләр яңа язылулары белән аерылып торалар. Алар башлыча 1975 ел, 1974 ел җимешләре, ягъни шигъриятебезнең әлегә соңгы сүзе. Телевидениегә күпсерияле фильмнар, спектакльләр алып килгән соңгы еллар әдәбиятның классик формаларына зур йогынты ясадылар. Романнар, повестьлар, пьесалар, киресенчә, кыскарды, 400 юллы поэмалар укып бетерә алмаслык эпос, дастан булып күренә башлады. Шигырьләр кыскардылар, әмма, минемчә, саекмадылар, ярлыланмадылар. Шигырьнең кыскару процессы образларның эчтән баюы, саллылануы бәрабәренә бара. Шигырь юлларыннан матурлык өчен генә, яңгыраш өчен генә кертелгән купшы буш сүзләр коела баралар. Хәзерге социалистик поэзия соцреализмга хас сүзнең ассоциация тудыра алу сәләтен дә, экспрессионизмга хас хисләрне куертып бирүне дә, прозага хас салмаклылыкны да үз файдасына бик матур итеп җигә белә. Шигырьләрдә кинематографка, телевидениегә, хәтта симфоник музыкага хас темаларны берсе өстенә икенчесен шудыру, бер үк вакытта, бер үк урында кешенең, вакыйганың төрле халәтен, стадиясен күрсәтү алымнары белән очрашабыз. Әгәр дә шигырьне сынлы сәнгать белән чагыштырсак, без аның нәкышкә түгел, ә графикага тартым икәнен күрер идек. Кара һәм ак төсләрдән генә торган офортларда, гравюраларда төсләрнең барлык гаммасын ачык төсмерләп булган кебек, купшы эпитетлардан арынган, гади сөйләм теленә якынлашкан ай-вайсыз юллардан торган шигырьләрдә дә табигатьнең бөтен төсе, тормышның бөтен яме ачык чагыла. Бүгенге шигырьләрдә уй-фикернең ярлылыгы, сайлыгы, кичерешләрнең сыеклыгы, ваклыгы купшы юллар ышыгына яшеренеп кала алмый.

Бүгенге шигъриятнең тагын бер үзенчәлеге, минемчә, шигырьләрнең тавыш көче үзгәрүдә. Маяковский, Асеев, Такташ, Хәсән Туфанның «Урал эскизлары» чорындагы, Бөек Ватан сугышы елларындагы йодрыкны баш өстендә селки-селки зур аудиторияләргә, хәтта Җир шарына кычкырып сөйли торган шигырьләр янына бүген һәр кешенең үзенә генә адресланган, һәр кешенең үзе белән генә сөйләшергә яраткан, «ул минем белән сөйләшергә теләрме, теләмәсме икән?» дип шикләнеп маташмаган, хәтта күпмедер дәрәҗәдә үз-үзенә ышанган шигырьләр килә.

Бу сыйфатлар соңгы 15–20 ел эчендә безнең татар совет поэзиясендә дә үзенә бер төрле чагылыш таптылар, һәм аларны кайбер шагыйрьләребезнең быел дөнья күргән әсәрләрендә дә очратабыз.

Сүзләрне дәлилләр өчен мин иң беренче нәүбәттә Сибгат Хәкимнең «Казан утлары»ның 5 нче санында чыккан шигырьләрен китерер идем. Бу шигырьләр кемгәдер, ихтимал, артык салмак, артык шәрә, артык кырыс булып күренер, чөнки 21 шигырьнең бер генә юлында да ай-вайлар, «ал таңнар», «мөлдерәгән хисләр», «аязган офыклар», «якты юллар», «нурлы көннәр» һәм боларга охшаш шалтыравыклар юк, һәр юл кырыс, кыска, детальләр төгәл, нейтраль образлар юк. Гади, прозага якын юллар, ныклы баскычлар кебек, сине югарыга, әкрен генә, уйландыра-уйландыра, һаман югарыга алып менә. Юлда синең игътибарыңны гадәти дә, гадәти дә булмаган детальләр, образлар җәлеп итә, хәтереңә сеңә бара: һәр таңда шагыйрьне юрганыннан тартып уятучы Белгород йә Харьков, шигырьләренең эчтәлеген тикшереп йөрүче яшен уты, салават күперенә менеп баручы солдатлар, кичке ашка кайткан уракчылар кебек арып Казанга кайтучы самолетлар, Есенин сурәтенә интим гына елмаючы Чаллы кызлары, шагыйрьнең иске хисләрен машинага сосып ятучы экскаватор һәм башкалар, һәм башкалар.

С.Хәким мактауга мохтаҗ шагыйрь түгел. Һәр әдәби ел йомгагында, һәр утырышта без аның шигырьләрен мактыйбыз. Аны мактау инде кайберләребезгә ошап та бетми, махсус мактау итеп кабул ителә. Мактаулардан иң туйган кеше, минемчә, Сибгат ага үзе. Ләкин нишлисең, тирән мәгънәле, оста язылган шигырьләрен укыйсың да, көнләшеп куела. Шул көнләшүне кешегә сөйли башласаң — кеше аны мактау итеп кабул итә. Ләкин нечкә итеп, чын математик төгәллектә фикерли белүе һәм шул фикерен музыка белгечләренә әйтеп аңлата алуы белән мине көнләштергән бер шигырен аерым телгә алмыйча булдыра алмыйм.

Ватан сугышы маршаллары...
Күңел шундый күнеккән,
Өлкәләр, фронтлар булып
Калды Жуков, Коневлар.

Тормыштан китә маршаллар,
Ә син тыныч торып кал.
Яңадан кулдан киткән күк
Булды миңа фронтлар...

Сугыш еллары кеше күңелендә менә ничек тә саклана алалар икән. Шагыйрь һаман да утыз ел буе үзен Жуковлар, Коневлар командалыгы астында көрәшүче итеп сизгән. Менә алар юк. Шагыйрь үзен бер мизгелгә ятим сугышчы итеп тоя. Аңа уңайсыз. Ул нишләргә белми. Кеше халәтендәге мондый сизелер-сизелмәс мизгелне С.Хәким экспрессионистларга хас алым белән тотып, чын реалистларча ныклы җирлеккә куеп, олы гражданлык хисе белән сугара алган.

Бөтнек исе белән аэропорт исен органик рәвештә бәйләгән бу шигъри циклны мин 1975 елның казанышы дип атар идем. Ләкин аны Архимед турындагы һәм «Мин кайтканчы яучы килә» дигән шигырьләрсез күрәсе килә. Бу шигырьләрдә Сибгат ага әйтергә теләгән фикерен ачып бирерлек образлар, детальләр таба алмаган.

«Казан утлары»ның 3 нче санында Салих ага Батталның бер шигыре бар:

Бөек Ватан сугышында
Елгалап кан акканда,
Ә без Ерак Көнчыгышта
Резервта чакларда
Борчак кадәрле бер төер
Чыккан иде башыма.
Ярдылар, чәчемне кырып,
Китереп бар шартына.
Врачның осталыгын мин
Шунда мактаган идем.
Ул да телгә алып үтте
Зур чыдамлыкны минем.
Бик әдәпле сөйләшсәк тә,
Саф булса да күңелебез,
Мыскыллаган кебек сиздек
Беребезне беребез.

Бу шигырьне мин шулай ук кеше халәтенең күренер-күренмәс нюансларын зур осталык белән тоткан, гражданин йөрәгә аша күрсәткән уңышлы, истә кала торган әсәр дип әйтер идем. Ватанны саклауда катнашуның зур горурлык, зур бәхет икәнен без, яшьләр, акылыбыз белән яхшы беләбез. Менә мондый шигырь Ватанны саклауның чын куаныч икәненә дөрестән дә ышандыра.

Шагыйрьнең активлыгы ахыр чиктә шигырь саны белән билгеләнми, шигыренең иҗтимагый һәм политик активлыгы белән билгеләнә. С.Батталның шушы бер шигыре генә дә аны 1975 елның иң актив шагыйре дип атарга мөмкинлек бирәдер.

Шулай ук бер шигырь белән актив шагыйрьләр исемлегенә керергә лаеклы язучылардан, минемчә, Рәшит Гәрәйне дә атарга була. Р.Гәрәй иҗаты турында без соңгы елларда йә ләм-мим эндәшми килдек, сүз әйткәндә, өстән-өстән генә, шудырып кына әйттек. 1975 елда Р.Гәрәйнең «Социалистик Татарстан»да, «Татарстан яшьләре»ндә чыккан шигырьләренә карап, аның иҗатында матур үзгәрешләр бар дип әйтергә була. Һаман бер моңга, бер тонда, кычкырмыйча да, пышылдамыйча да язарга күнегеп китә язган Рәшит Гәрәй җилкенеп куйган. Аның эчке кичерешләре олыгайган, тирәнәйгән. Урталыктагы хисләре полюсларгарак күчкән. Шигырьләрендәге графикага хас контрастлык пәйда булган. Шигырьләренә сөйләү, сөйләнү урынына сурәт ясау, уйлану, киная кергән. Рәшит Гәрәйнең шундый шигырьләренә мисал итеп мин «Казан утлары»ның 8 нче санында чыккан «Шигырь укыттылар» дигән әсәрен алыр идем. Бу шигырьне укыганда, син үзеңне әдәбият һәм кеше, ил һәм әдәбият, хезмәт һәм сәнгать, горурлык һәм мәсхәрә хисе, сәнгатьнең кеше язмышындагы урыны турында философларча фикер йөрткән олы йөрәкле кеше белән сөйләшкән кебек итеп тоясың. Шагыйрьне сабан туе мәйданына чыгарып шигырь укыталар. Шагыйрь укый, ләкин шигыре һәм халык арасында контакт урнашмаганын сизеп ала. Ләкин халык кул чаба. Шагыйрьгә түгел, шигырьгә түгел, әдәп өчен, чөнки шигырьдә чынбарлык, ихласлык чамалырак.

Җиңелгәнне кем соң күккә чөйсен,
Башым минем түбән иелгән.
Сөялләнгән куллы аксакаллар
Килеп кага шунда иңемнән.
Якын итеп биргән киңәшләрен
Гомер буе юлдаш итәрлек:
— Җырларыңны өйрәт көрәшергә,
Сабантуйлар алда җитәрлек.

Рәшит Гәрәйнең соңгы ике-өч ел эчендәге иҗаты болай, үтеп барышлый гына түгел, тукталып, төрле яктан килеп анализлауга мохтаҗ. Минемчә, аңа хәзер иң беренче чиратта жанрлар, шигырь формалары турында уйланырга кирәктер. Сизүемчә, Рәшит Гәрәйнең күңеле инде моңа әзер, ләкин кулы инерция буенча һаман да бер калыпка тарта.

Бүгенге көн поэзиясенең үзенчәлекләреннән берсе дип без трибун шагыйрьләр янына, алар рәтенә тынычрак тавышлы шигырьләр килүен билгеләп үттек. Ләкин тормыш һаман да трибун шигырьләргә мохтаҗ һәм бу мохтаҗлык алда да булачак әле, чөнки без төрле идеологияләр канга-кан килеп бәрелешкән чорда яшибез, безнең тавышыбыз — үзебезнең коммунистик идеология тавышы.

Шигъриятнең, чынбарлыкның шушы ихтыяҗын чын граждannарча тоючылар арасында Роберт Әхмәтҗанов һәм Равил Фәйзуллин.

«Казан утлары»ның 3 нче санында Равил Фәйзуллинның «Поэмадан өзек» дигән әсәре басылды. Күрәсең, ул «Көрәшчеләр» поэмасының дәвамыдыр. Равил әйтәсе фикеренең җегәрен, авырлык-җиңеллеген алдан ук бик тиз чамалый белүче шагыйрь һәм ул вак фикер белән олыдан кизәнми. Бу өзектә дә ул трибунага зур публицистик фикер алып менә һәм аны шигъри яңгыратуга ирешә.

Җирдә күп кешеләр.
Җирдә күп эшлиләр.
Кемнәр соң
Көрәшче — көчлеләр?
Максатларын белүчеләр,
Эшләренең мәгънәсен, төп асылын күрүчеләр,
Җирдә бәхет арттыручы хезмәт өчен
гомерләрен бирүчеләр —
шулар —
көчлеләр!
Аз — хезмәт кешесен сөям дип
Күкрәк сугып ант эчүчеләр.

Равилнең «Урта Идел халкы бәрәңге ала», «Туган ягын онытканга», «Безнең байлык» дигән шигырьләре дә матур тәэсир калдыра. Ләкин аның шигырьләрендә мин соңгы вакытта дөньяны аңлатып бирергә тырышу күрә башладым. Бу тырышу кайчак дидактикага, вәгазь сөйләүгә дә китерә кебек.

Роберт Әхмәтҗановның «Сине нинди җилләрдән сакларга», «Улым, көзнең бу китабын...», «Машук итәгендә уйлану», «Хисап көннәре» кебек зур осталык һәм бүгенге көн стиле белән язылган шигырьләренә тукталмыйча, «Иделгә ялвару» дигән шигыре турында гына берничә сүз әйтәсем килә.

1975 ел шигырьләре фонында бу әсәр шулай ук көр тавышы, публицистик темпераменты белән аерылып тора. Шагыйрь трибунага басып түгел, рухи бер калкулыкка басып, Иделгә, Идел символы аша туган җиргә, туган халыкка аваз сала, мөрәҗәгать итә.

Бер, Идел, бер Идел,
син моны аңларлык:
хыялга — иркенлек,
җырларга — кайнарлык.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Каныма — кыюлык,
Өметемә — хәрәкәт,
Илемә — иминлек,
Җиремә — бәрәкәт!
. . . . . . . . . . . . . . . . .
Биралсаң, бир идең
аз гына... сабырлык,
офыктан офыкка
тын гына агарлык.

Һәм бу ялваруга укучы да кушылыр сыман. Тормыш хәрәкәтенең бөтен катлаулылыгын күрсәтергә омтылу, аның закончалыкларын ачыкларга теләү безнең социалистик реализм поэзиясендә ике стиль тенденциясен барлыкка китерде: күпбуынлы, күптармаклы катлаулы ассоциативлык һәм шигъри образларның гадилегенә ирешергә тырышу. Бу тенденцияләр бик еш кына бер үк шагыйрь иҗатында да очрыйлар, бергә үрелеп баралар. Моңа мисал итеп мин Сибгат ага Хәким, Хәсән ага Туфан, Нури ага Арслан, Шамил Мәхмүдов, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов, Марс Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, Әхсән Баяновларның кайбер әсәрләрен китерер идем.

Быел чыккан әсәрләрдән мисал итеп Гәрәй Рәхим һәм Саҗидә Сөләйманова шигырьләренә аерым тукталасым килә.

Г.Рәхимнең «Тамыр» дигән шигыре яшәү мәгънәсе, аның күзгә күренми торган кыенлыклары, кеше шатлыгы һәм кайгысының нигезләре турында сөйли. Шигырь әкрен генә катлаулана, сине уйланырга, шикләнергә, көрсенергә мәҗбүр итә. Аннары шулай ук әкрен генә ачыклана, гадиләнә һәм, күңелдә кояш белән кулга-кул тотышып, чәчәк язмышы өчен үзен мәңге җир астында тотарга мәҗбүр итә алган фидакарь, гражданин тамырның гади дә, күпмәгънәле дә образы гына кала.

«Эт һәм аның хуҗасы» дигән шигырендә Г.Рәхим гади генә бер вакыйга турында сөйли. Бала чагында ук күрше бакчага алма өзәргә керә. Хуҗа аңа эт өстерә.

Сукмакларда җырлап йөргән чакта
Өстерде ул...
Ә эт таламады.

Эт аңлады адәм баласының
Балалыгын...
Хуҗа аңламады.

Кемне ничектер, ә мине бу гади генә шигырь бик тә катлаулы уйларга этәрә, миндә катлаулы ассоциацияләр тудыра.

Г.Рәхим шигырьләрендәге ассоциация моментлары катлаулы, саллы булса, Саҗидә Сөләйманова әсәрләрендә алар пәрәвез кебек нәфис, нечкә, матур.

Сагындым.
Сиңа сарылыйм,
Зәңгәр күк, яшел үлән.
Бәйгегә чыга йөрәгем
Яңгырлы яшен белән!

Салават күпере — дуга:
Кызыллы да зәңгәрле.
Кемгә күк капусы ачты
Мәхәббәт пәйгамбәре?

Яфракта чыклар, керфектә...
Бер тирән сулыш, бер җан.
Тәрәзә ачык,
Күңелләр
Пәрдәсез аткан бер таң.

Бу шигырьнең һәм С.Сөләймановaның соңгы елларда «Азат хатын», «Казан утлары» журналларында чыккан башка бик күп шигырьләре дә барлык татар шагыйрьләре әсәрләреннән төсләргә, полутоннарга, челтәрләргә, матур чыңнарга бай булулары белән аерылып торалар.

Буй салам, дулкын-уй салам,
Буйсынам, сынмасам да.
Аккошлар юлыдай елым,
Күлләрдә кунмасам да.

С.Сөләйманова шигырендәге бу күренешләр, бу сыйфатлар бүгенге көн шигъриятенең төп үзенчәлекләре, хасияте белән кисешми, киресенчә, аны тулыландыра гына. Алар офортлар күргәзмәсендә төсле линогравюралар кебек. Өстәп шуны да әйтәсе килә, мәхәббәт турында быел иң матур, иң нечкә, нәфис шигырьләрне кем язды дип сорасалар, С.Сөләйманова шигырьләрен атау дөрес булыр, минемчә. Аның шигырьләрендә хатын-кыз күңеле гаҗәеп нечкә яклары белән ачылып китә. С.Сөләймановaның лирик героинясы — әхлактагы консервативлыкны бүгенге заманның модасы белән органик куша белүче хатын-кыз.

Әхсән Баяновның быел «Казан утлары»нда «Кышкы чәчәкләр» дигән поэмасы һәм 11 нче санда шигырьләренең шактый зур гына җыелмасы басылып чыкты.

Әхсән Баянов шигырьләренә хас киеренке фикерләр, кинаяләп әйтүләр, зур проблемалар турында уйланулар әлеге циклда да бар. Әхсән Баянның бу бик җитди циклын укыганда, мин үземне физикадан да, химиядән дә, философиядән дә, техникадан да бүгенге көн кешесенә тиешле дәрәҗәдә хәбәрдар булган акыллы кеше белән сөйләшкәндәй хис иттем. Һәм исемә Андрей Вознесенскийның «Я не представляю современного серьезного мышления и характера без знаний основ математики и сопромата» дигән фикере килеп төште.

Арада бәхәс уяткан, кызыксыну уяткан фикерләр белән бергә Ә.Баянның кайбер шигырь-фикерләре миңа тәэсир итмәде. Бу шигырьнең начарлыгыннан түгел. Бу табигый хәл. Безнең кайсыбыз соң һәрвакыт барыбыз өчен дә кызыклы, файдалы фикер әйтеп тора ала?

Ә.Баянның «Әйләнмәле сәхнә», «Баш ияргә мөмкин», «Йолдызлар җитә һәркемгә» кебек шигырьләрен мин 1975 елның кызыклы шигырьләре рәтенә кертер идем. Аларда шигырь төзелеше генә түгел, фикер сөрү алымнары да яңача, свежий.

Ә хәзер поэма турында берничә сүз.

1968 елда «Казан утлары»нда 6 поэма басылган, 1969 һәм 1970 елларда — 5 әр, 1971–72–73 елларда — 2 шәр, 1974 елда — 3. Көчле прозалы әдәбиятны романсыз күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек, көчле, нормаль поэзияне дә поэмасыз күз алдына китерү кыен. Поэмага мондый караш — тенденцияме, очраклы хәлме? Моңа җавап бирү бик авыр. Безнең галимнәребез арасында Нил Юзиев, Тәлгать Галиуллин кебек поэма жанрына бик сизгер кешеләребез бар, бу, күрәсең, алар азыгыдыр.

Ә.Баяновның «Кышкы чәчәкләр» поэмасында мораль проблемалар күтәрелә: бер-береңә тугрылык, хыянәт, әхлак ирееге һәм башкалар. Автор үзенең язу алымын Такташча стильләштереп, безне оста итеп Такташ биографиясенә алып кереп китә. Ләкин поэманың герое — абстракт шагыйрь. Абстракт шагыйрьнең мәхәббәте дә, урыны-урыны белән бик бытовой булуына карамастан, тормышчан булып җитә алмаган. Мондый хыянәтле мәхәббәт шагыйрьгә нинди йогынты ясаган? Ул зур рухи дулкын очына басып, дөньяны сүгә башлаганмы, тормыштан ваз кичкәнме? Әллә тагы да ныграк сөяргә өйрәнгәнме? Мораль давылдан, тетрәнүдән шагыйрь күңеле баепмы, ярлыланыпмы чыккан, нинди яңа сыйфатларга ия булган?

Бу сораулар поэмага карата әйтелгән урынлы сораулардыр дип уйлыйм, чөнки аларны поэма үзе тудыра, ә җавап бирми. Моның төп сәбәбен мин поэмага Такташның үзен кертмәүдә күрәм. Поэманың герое Такташ булса, автор бу сорауларга җавап бирүдән котыла алмас иде, поэма уңышлырак чыгар иде, аның социаль, мораль, әдәби җегәре бермә-бер артып, 630 юл шигырь үзен тулысынча аклар иде. Поэмада шушы килеш тә ятлап алырлык матур урыннар күп, ләкин алар гына поэманы югары художестволы әсәр итә алмыйлар.

Киңәш бирү — җиңел, киңәшне тыңлап тору — авыррак, киңәшне тоту — тагы да авыррак икәнен белә торып, Әхсән абыйга шушы киңәшне әйтергә баздым. Бәлки, китапка керткәндә исенә төшәр. Ә Такташ турында поэма бик кирәк.

Ә безнең барыбызга да поэзиянең бу иң көчле жанрын җанландырып җибәрү өчен бер җиң сызганып алырга кирәктер. 1975 елгы шигъри үрләрне билгеләгән әсәрләр арасында Хәсән ага Туфанның «Язып куй тарихка», «Ахыргача», «Ямалган яра эзләре», «Сөйләдең»... дигән бик эмоциональ, ювелирларча төгәллек һәм югары зәвык белән язылган әсәрләре дә, Нури ага Арсланның шәрык колориты белән өртелгән, классик робагыйларга тартым шигырьләре дә, Шәйхи ага Маннурның «менә ул традицион шигырь нинди булырга тиеш!» дип чылтырап торган, яшьрәк шагыйрьләрнең әсәрләре белән чылтырый-чылтырый бәхәсләшкән «Олы чишмә»се дә, Рәдиф Гатауллинның да, Фаил Шәфигуллинның да аерым шигырьләре бар. Болардан соңрак тагын бер өлкән шагыйрьнең әсәрләрен атыйсы килә. Ул — Уолт Уитмен.

Марс Шабаевның зур көч куеп, ирекле шигырьнең бөтен нечкәлекләрен белеп, татар теленең лексик һәм семантик арсеналыннан бик иркен файдаланып эшләгән тәрҗемәләре, минемчә, бүгенге татар әдәби процессында күренекле вакыйга. Заманасында Назыйм Хикмәтнең Ш.Мәхмүдов, М.Ногман тәрҗемәләрендәге шигырьләре бер төркем яшь шагыйрьләргә иҗат ачкычы биргән кебек, М.Шабаевның бу хезмәте дә татар совет шигъриятен тагы да үстерүгә ярдәм итми калмас дигән уем бар.

Традиция буенча хәзер сүз яшь шагыйрьләр турында. Яшь шагыйрьләр арасында инде китаплар чыгарырга өлгергәннәре дә, кырыкка җитеп килүчеләре дә, комсомол яшеннән чыкмаганнары да бар. Соңгы елларда матбугат битләрендә Роберт Миңнуллин, Нур Әхмәдиев, Разил Вәлиев, Шамил Маннапов, Фәннүр Сафин, Госман Садә, Мөхәррәм Каюмов, Венера Туктарова, Сәлимә Шәрипова, Мәхмүт Газизов, Хәниф Хөснуллиннарның шигырьләре актив басыла. Бу иптәшләрнең шигырьләре быелгы ел йомгакларында да телгә алынырга лаеклылар. Ләкин мин бары ике генә яшь шагыйрьнең әсәрләренә тукталып үтәргә телим, чөнки бу ике шагыйрьнең шигырьләрендә күпчелек яшь иҗатчыларга хас күркәм һәм тискәре яклар бар.

«Казан утлары»ның 4 нче санында Мәхмүт Газизовның шигырьләре басылган. Аларның уңышлы ягы — заман, хезмәт киеренкелеген төгәл бирә алучы мәгънәле ритмда, җор теллелектә. Тимер-томыр арасын, төзелешне, завод цехын күңелгә ятышлы итеп, лирик итеп язу хәтта тәҗрибәле шагыйрьләргә дә авыр. Мәхмүт моңа ирешә алган. Әнвәр Давыдовның «Себер тракты» циклыннан соң кырыс, коры темага җылы итеп язылган шигырьләр циклын мин беренче тапкыр яраттым. «Баш уйлый таш турында» шигыре укучыны үзенең драматик ситуациясе белән тетрәндереп җибәрә: күтәргеч краннан тимер-бетон багана ычкынып, кеше өстенә оча. Мәхмүтнең шигыре, әлеге кешенең тартылган нервысы кебек, зыңлап тора. «Таганда» шигыре 1975 елның шулай ук иң уңышлы шигырьләре рәтенә керә.

Бәхет юра, матурым,
аймыл булма, егылма,
кызык та бит таганда,
уймак диләр уенда.

Таганыбыз шул менә:
эш-һөнәре бер генә —
күк белән җир арасын
бер төшә дә бер менә.

Егылмадык моңарчы,
атынабыз һаман да,
без генәме, замана
үзе дә бит таганда!..

Бер таганга эләктек,
ялгыштырмы, чындырмы,
безнең болай булулар
бәеттерме, җырдырмы...

Тормыш — таган шул менә:
эш-һөнәргә бер генә —
кайгы-шатлык арасын
бер төшә дә бер менә.

Мәхмүтне тагы да мактап тормыйча, яңа Язучылар союзы члены булырга вакыт җитмәдеме икән инде диясе килә.

Икенчесе — Фәннүр Сафин. Аның иҗаты безгә шулай ук күптән таныш. Яшь шагыйрьнең буыны елданел ныгый бара, чын мәгънәсендә зур шигырьләре елдан-ел ешрак очрый. «Татар-стан яшьләре»нең 20 ноябрь санында аның «Сез кемнәр?» дигән шигыре басылды.

...Шартлаулар, янгыннар яктыртса,
барыбер караңгы ул төннәр...
Шул төндә яндыгыз, туганнар,
менә бит сез кемнәр, сез кемнәр...

Янды тән, янды кан — җан калды,
шуңамы якты бу ак көннәр?
Һәм шуңа ни булыр җавабың —
Без кемнәр, без кемнәр, без кемнәр?..

Бу инде Фәннүрнең дөнья белән, замандашлары, яшьтәшләре белән җитди сөйләшү алып барырлык шагыйрь икәнен раслаучы юллар.

* * *

Картлар әйтмешли, кырдык, урдык, кибән куяр вакыт та җиткәндер инде.

Күргәнебезчә, әдәби 1975 ел шагыйрьләребез өчен иң беренче нәүбәттә совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуына 30 ел тулуны билгеләп үтү елы булган. Һәр шагыйрьнең диярлек, яше-картының, бу олы юбилейга, совет кешеләренең фронттагы, тылдагы батырлыкларына багышланган, хезмәт ияләрен коммунистик, патриотик рухта тәрбияләүдә ярдәм итә алырлык әсәрләре бар.

1975 елда, IX бишьеллыкның соңгы елында матбугатта хезмәт кешесен данлаучы, хезмәтнең олылыгын, изгелеген күрсәтүче әсәрләр дә күп басылды. Киң катлам укучылар безнең публицистик шигырьләребез, лирик әсәрләребез һәм сатира-юморыбыз белән дә таныштылар. Уйлап баксаң, без кагылмаган тема үзе калмагандыр кебек, без файдаланмаган сурәтләү чаралары, шигырь формалары инде юктыр кебек. Ә «менә ул бүгенге татар шигыре, поэмасы, менә аның колачы, менә аның тирәнлеге, менә аның беркайда да күренмәгән табышлары!» дип байрак итеп селкерлек шигырьләр юк дәрәҗәсендә аз. Безнең иң яхшы дигән шигырьләребездә дә һаман нииндидер аңлатып бетереп булмый торган тарлык, кысылганлык бар. Луи Арагонның бер шигырендә Замана, Эпоха кешеләрдән наз, иркәләү, игътибар көткән хатын образында сурәтләнә. Безнең ни өчендер шундый гомумиләштерүгә, гадәти булмаган зур итү, кечерәйтүләргә кодрәтебез җитми. Бертольд Брехтның «Народ понимает смелые выразительные средства, одобряет новые взгляды, преодолевает трудности формы, если это в его интересах» дигән сүзләрен дә искә төшерәсе килә.

Иҗат алдында һәрвакыт берсенә берсе аерылгысыз бәйле ике олы проблема тора: нәрсә турында һәм ничек? Миңа калса, татар шигърияте алдында бүген беренчел булып торган проблема — ничек язарга, ничек итеп югары идеяле фикерләрне, образларны укучының йөрәк түренә җиңелрәк илтеп җиткерергә, ничек итеп ул фикерләрне аның йөрәгендә озаграк сакларга. Бу шагыйрьләр алдында гына торган проблема түгел. Бу — комплекслы проблема. Ул язучының политик һәм профессиональ әзерлеген үстерүгә дә, әдәбиятның иң яхшы темасы, күтәргән проблемасы белән генә түгел, художестволы эшләнеше белән дә яхшы үрнәкләрен пропагандалый белүгә дә бәйле. Бу мәсьәләләрне нииндидер ачык, аңлаешлы әдәбиятның, халыкның ихтыяҗларыннан чыккан эз-юлга төшерү, минемчә, иң беренче нәүбәттә әдәби тәнкыйтькә йөкләтелгән бурыч. Сикерүче үзеннән дә биегрәк сикерә алмаган кебек, әдәби әсәр дә үзеннән-үзе ерак китә алмый. Үзенең барыр юлына маяк та куеп чыга алмый. Ә тәнкыйть әдәби әсәрдән алга да узып китә ала, арткарак чыгып якякларыннан да күзәтә ала. Безнең әдәби тәнкыйть — әсәрләрнең иҗтимагый-политик нагрузкасын, тәрбияви әһәмиятен шактый тирән һәм компетентлы итеп тикшерә һәм ачып сала белә торган тәнкыйть. Ләкин ул, минемчә, әдәби әсәрне әдәби итә торган күзәнәкләргә, структураларга, сурәтләү чараларының асылына, шигырьнең гомуми культурасына һәрвакытта да тиешле игътибар биреп җиткерә алмый. Җәмгыять аңының идеологик формасы буларак, әдәби тәнкыйть әсәргә социаль-политик яктан да, художество-эстетик яктан да бертигез дәрәҗәдә килеп, тулы анализ, объектив бәя бирергә тиеш. Бүгенге татар поэзиясе менә шундый анализларга мохтаҗ.

Соңгы елларда шигырьләрне эмоциональ һәм рациональ төрләргә, гади һәм интеллектуальгә, җылы һәм салкынга бүлә башладылар. Эмоциональ, җылы булса — әйбәт дип, салкын, гади, рациональ булса — бу шигырь әдәби әсәрме, түгелме дип шикләнүләр күренә башлады. Шагыйрь иҗатында кайнар шигырьләр дә, салкыннары да, җылымсалары да, үтә акыллылары да, беркатлылары да, форма матурлыгына өстенлек биргәннәре дә очравы табигый. Формаль рәвештә шигырьнең температурасын үлчәп, аның авторына сыйфат билгесе тагарга тырышулар да юк түгел. Безнең әдәби тәнкыйть, минемчә, бу күренешләргә күз йомыбрак карый, әдәби процесста барлыкка килгән мондый тенденциягә карата үзенең абруйлы, дәлилле сүзен әйтми. Интеллектуаль, эмоциональ, рациональ башлангычларга бүлү кайбер очракта кирәктер дә, ләкин ул шигъриятнең башка сыйфатларын, мәсәлән, вакыйганың асылына үтеп керергә тырышу һәм аны аңлау-аңлатуны, тормышка актив йогынты ясаучы көч булуын, читкәрәк, караңгырак урынга этәрә. Әгәр шагыйрь акыллы икән, аның акылы рациональ башлангычка бирелеп язган әсәрендә дә, эмоциональ башлангычка бирелеп язганда да ачык күренә. Буш шигырьне бернинди җылылык та коткарып кала алмый. 1975 елда матбугатта чыккан күп шигырьләр моңа мисал була алырлар иде. Эш шигырьнең төрле компонентларын калку итеп күрсәтүгә калган икән, аны акыл, хис һәм осталык эремәсеннән шагыйрь җанында кристаллашкан рухи матдә дип тә буладыр. 1975 елда чыккан шигырьләр арасында, үзебезгә таләпчән булып бәяләгәндә, шушы компонентларның өчесен дә бертигез колачлаганнары сирәк очрый. Шигырьләрнең шундыйлары гына коммунистик эстетика таләпләренә дә, иҗтимагый-политик таләпләргә дә туры килә ала, зур рухи информация алып килгән шигырьләр генә техник революция заманы кешесенең аңында һәм йөрәгендә тоткарланып кала

ала, шундый шигырьләр генә әдәбиятны яңа үрләргә күтәрә. Шигырьләребезнең күбесенә, дөресен әйтергә кирәк, йә акыл, йә хис, йә осталык җитми.

Төрки телләрдә язылган шигырьләргә хас бер үзенчәлек бар — тартык һәм сузык авазларның төгәл тәртиптә чиратлашып килүе, сингармонизм закончалыгы, яңгыравык һәм көйле ижекләр шигырьгә өстәмә образлылык бирәләр. Андый шигырьләрне без рәхәтләнеп укыйбыз, алар безгә җылы, ягымлы булып тоела, шагыйрьләргә һәм тәнкыйтьчеләргә үтә дә художестволы, җегәрле әсәрләр булып күренә. Бу чынлап та шулай. Ләкин андый шигырьләрне тәрҗемә итә башласаң, нәтиҗәдә буш, кызыксыз, мәгънәсез җөмләләр генә кала. Безгә әле шигырь юлларыбызны теләсә нинди очракта да үз мәгънәләрен, матурлыкларын саклап кала алу дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк. Бу шулай ук осталыкка бәйле мәсьәләләрнең берсе.

Димәк, безгә осталык турында, «ничек?» турында җиң сызганып эшлисе бар әле.

*27.01.1975*

# Шигърият шәхестән башлана...

*(Шагыйрь белән тәнкыйтьче диалогы)*

— Шигърият — кеше күңеленең иң хозур,
иң ирекле, иң кешелекле һәм иң матур яшәеше ул...

*Мансур Вәлиев*

**М.Вәлиев.** Үсеш, алга таба хәрәкәт һәрвакыт яңа проблемалар, хәл итәсе конкрет мәсьәләләр, алар турында уйланулар тудыра. Поэзия турында барган сөйләшүне барыбыз да бертавыштан кирәкле һәм вакытлы дип саныйбыз икән — бу да, минемчә, иң беренче чиратта әнә шул хәл белән — татар совет поэзиясенең тагын да үсүе, яңа биеклекләр яулавы белән аңлатыла. Шушы биеклеккә, бүгенге дәрәҗәгә күтәрелгән шигърият әйтерсең үзенең кайда, ничек торуын белергә тели һәм шулай ук, алдагы үрләрне барлап, күзаллап карау нияте белән уйлана...

**Р.Харис.** Әлбәттә, поэзия алдында торган мәсьәләләр гаять күп һәм алар бик зурлар, җитдиләр. Аларның берникадәрен үзебез өчен ачыклау, көчләребезне барлау, фронтыбызның йомшаграк урыннарын билгеләп табу һәм аларга уртак игътибарыбызны юнәлтү вакыты да җиткән иде инде. Ләкин менә сөйләшүебезне башлап җибәргән мәкаләне «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе» дип исемләү (гәрчә монда куштырнаклар кулланылса да һәм «яки» сүзе аша ул күренешне гражданлык белән бәйләргә тырышу булса да) безнең поэзиябез үсүе өчен иң мөһим булган нәрсәләрне, аның иң авырткан җирләрен, үзәк мәсьәләләрен эченә алырдай юнәлеш бирде микән? Биредә, аңлаешлылык мәсьәләсендә, ситуация бик ачык бит: чын шигырь икән, ул аңлаешсыз була алмый. Аңлаешсыз икән — димәк, ул шигырь булып җитмәгән дигән сүз. «Шагыйрь» кешенең, димәк, таланты, осталыгы, тырышлыгы җитмәгән дигән сүз... Ә гражданлык мәсьәләсе менә үтә мөһим һәм поэзия үсешенең генераль юнәлешен билгеләүче мәсьәлә. Тик шундый олы проблеманы поэзия алдында реаль кыенлык булып тормаган аңлаешсызлык күренеше белән бәйләү бераз гаҗәбрәк тоела...

**М.Вәлиев.** Бу мәсьәләдә мин дә сезнең белән килешкәнгә һәм башка авторлар да җитди генә фикерләр әйткәнгә күрә, ул хакта сүзне артык озынга сузып тормыйк. Ә куелган проблеманың үзенә — гражданлык мәсьәләсенә якынрак килик. Бер караганда коры социаль яки чиста фәлсәфи категория кебек тоелган бу төшенчә бүген нигә безнең поэзия өчен үтә мөһим булып тора соң?

**Р.Харис.** Чөнки чын, тирән мәгънәсендәге гражданлык ул — олы шагыйрь шәхесенең асылы, үзәге белән бер диярлек, һәрхәлдә, аңа бик якын төшенчә, шуңа тәңгәл килердәй мәгънә. Чын гражданлык төшенчәсе ул һәрвакыт — саф, эчкерсез күңелле, олы йөрәкле булу, тормышны һәм, гомумән, дөньяны бар тулылыгына якын күзаллау, үзеңнең андагы реаль урыныңны, миссияңне ачык аңлау һәм шул миссияне тормышка ашыру өчен ихлас карашу дигән сүз. Шушындый ук бөек вазифа шигърият өстенә дә йөкләнмимени?! Чын шагыйрьдән халык һәр чорда шул сыйфатларны ук таләп итмимени? Соңгы вакытта еш кына ишетелә торган «поэзия биреша башлады» дигән сүзләрнең төбендә кешеләр, укучылар күңеленең әнә шундый зур рухи ихтыяҗы ятмыймыни?!

**М.Вәлиев.** Әйе, мондый таләп хәтта бүген бер поэзиягә генә дә карамый бугай. Ул башка жанрлар — повесть, хикәя, драма әсәрләре өчен дә — гомумән, әдәбият өчен бик әһәмиятле һәм зарури сыйфатка әйләнде шикелле. Тормышның һәм, аерым алганда, рухи тормышның яңа катламнарга тирәнәюе, кешеләрнең гомумкультура дәрәҗәләре нык үсү әдәбиятка булган таләпләрне хәзер бик күтәрде. Әдәбияттан укучылар үз күңелләренең иң кадерле почмагында ятканны, аның иң түрендәге, иң изге һәм олы, мөкатдәс нәрсәләрне әйтүен өмет итәләр, һәм халыкның әнә шул эчке өмете, күңел көткәне — әдәбиятка бердәнбер һәм ышанычлы стимул, иртәгесе үсешенә ышанычлы ориентир. Әйткәнемчә, бу, гомумән, әдәбият өчен. Ә менә поэзияне аерыбрак алсак, аның үзе алдында гына торган, бары тик аныкы гына булган бурычлары бармы соң? Һәм, гомумән, бүгенге тормыш өчен, безнең заман кешеләре өчен поэзия нәрсә ул? Шигърият бүгенге яшәештә нindирәк урын тота?

**Р.Харис.** Әйе... Мин үз фикеремне дәвам итим әле. Әдәби жанрларның һәм сәнгатьнең дә тамыры бер үк — шигъриятлелек, тормышның, яшәешнең матурлыгын ачу, шул ачышны кешеләр белән уртаклашу...

**М.Вәлиев.** Ә минемчә, поэзия ул — кеше яшәешенең җанлы мизгелләре (басым ясап әйтим, аның һәр мизгеленең) мәгънәсен, матурлыгын, олылыгын ачу һәм шул юл белән кешенең, тормышның бөеклеген, зурлыгын ачу.

**Р.Харис.** Әйе... Мин үз фикеремне дәвам итим әле. Әдәби жанрларның һәм сәнгать төрләренең тамыры бер, уртак дигән идем. Әнә шушы уртаклык аларның җәмгыятьтәге функциясенең дә берникадәр охшашлыгын билгели. Мәсәлән, кешегә акыл, киңәш бирү, нинди дә булса кичерешкә дучар итү, шул халәт аша фикер үткәрү — әдәбият-сәнгатьнең уртак нигезе ул. Ә поэзиягә килгәндә, ул — минемчә, барыннан да элек кешенең әңгәмәдәше. Ләкин бик сизгер һәм нечкә күңелле, укымышлы, аңлы, тәҗрибәле, югары культуралы әңгәмәдәш.

**М.Вәлиев.** Әле менә үзебезнең фикер сөреше турында уйлап алдым: поэзияне безнең югарыдагыча билгеләвебез, аны шулай аңлатуыбыз — ул үзе үк гражданлык принципларының поэзия торышы белән килеп тоташуы дигән сүз бит. Соңгы вакытта поэзиядә гражданлык турында уйлана башлау ул, күрәсең, поэзиянең җитдилеге, чынлыгы, ихласлыгы турында уйлану нәтиҗәседер, шул уйларның көчәйгән авазыдыр ул. Тик бу уйлану, үткәннәрдән аермалы буларак, инде хәзер икенче вакыт яссылыгында — җитмешенче еллар ахыры (әз генә ераккарак карасак, инде егерменче гасыр ахыры да җитеп килгәнен күрербез) яссылыгында бара. Шуңа күрә безнең гражданлык хакындагы таләпләребез нәкъ менә үзебезнең чор вакыйгалары җирлегеннән, үз чорыбыз яшәешеннән туалар. Алар — җитмешенче елларда яшәүче реаль кешеләрнең реаль күңел таләпләре...

**Р.Харис.** Поэзия турында сүз барганда, «җитмешенче еллар» дип бүлеп, аерып куюга мин үзем шикләнебрәк карыйм. Чөнки әллә ничә гасыр элек иҗат ителгән «Илиада»ның һаман яратып укылганын беләм. Аны укып, борынгы заман философиясен, тарихын, культурасын өйрәнеп булганлыгын беләм.

**М.Вәлиев.** Шулай, шигърият үзе мәңгелек, мәңге шиңмәс сихри гөл кебек. Ул кеше күңеленнән шытып чыга, үсә. Ә кеше күңеле — кайчан да кеше күңеле инде ул. Ләкин... Ләкин бит әле кешенең конкрет яшәеше — басып торган җирлеге, көн күргән туфрагы, үтә реаль каршылыклар белән тулы бердәнбер һәм бик конкрет гомере бар. Ул гомернең эчтәлеге дә шактый конкрет һәм күпмедер еллар эченә, «рамкасы»на сыя кебек. Менә шул ноктадан торып, минем үз чорыбызны күздән кичерәсем килә. Ышануымча, һәр заман тормышының үзенчәлекле психологиясе, җаны булган кебек, безнең чорыбызның да үз җаны — үзенә генә хас иң газиз кичерешләре, хисләре, уй-фикерләре, тынгы бирмәс сораулары яши торган, дулкынланып торучы үз сферасы бар. Әнә шул сфера заманның рухи эчтәлеген, аның дөнья үсешендәге урынын, мәгънәсен билгели кебек. Конкрет алып караганда, инде менә җитмешенче еллар узып бара. Ә ул елларның җаны, яшәеше безнең поэзиядә ничектер канәгатьләнү алырлык дәрәҗәдә ачылып, тасвирланып җитмәде кебек. Һәрхәлдә, алтмышынчы елларның рухи яшәеше шикелле үк ачылмады. Сез моның белән килешәсезме?

**Р.Харис.** Юк. Минемчә, һәр заманның җанын кешеләр алдында торган проблемалар, мәсьәләләр, хәл ителәсе эшләр һәм кешеләрнең әнә шуларны тормышка ашыруда ирешкән рухи һәм матди казанышлары билгели. Шул проблемалар һәм казанышлар, әлбәттә, һичшиксез, шагыйрьләр иҗатына да тәэсир итә, йогынты ясый. Аларга багышланган, йә булмаса, шагыйрьнең аларга мөнәсәбәтен белдергән шигырьләр, поэмалар барлыкка килә. Бу, минемчә, заман рухының тышкы чагылышы. Ләкин әле моннан башка заман рухының эчке чагылышы да бар. Ул — шагыйрьләр иҗатының сыйфаты. Шигырьнең сыйфат дәрәҗәсенә карап, теге яки бу әдәбият тарафыннан заман җанының ни дәрәҗәдә аңланганын шәйләп була... Әмма заманның җаны, аның эчтәлеге дигән сүзне, минемчә, артык примитивлаштырудан, аны бик схематик күзаллаудан сакланырга кирәк безгә. Югыйсә еш кына шундый хәлләр килеп чыга: нигездә дөрес һәм бик вакытлы куелган таләпләр бездә, җиңел карашка очрап, бөтенләй икенче төрле яңгырап китәләр. Мәсәлән, төрле темалар турында акланмаган сүз куерту еш кына шактый схематик, әдәбиятның һәм поэзиянең үзенчәлеген искә алмый торган таләпләр куюга китергәләде. Шуның кебек, биредә дә, безгә диалектик карашка ия булырга тырышырга кирәк. Чөнки безнең һәр көнебездә үткәннең китеп бетмәгән очы һәм киләчәкнең конкрет форма алырга өлгермәгән башлангычы бар. Шуңа күрә, минем уйлавымча, заманның рухи тормышын тулаем ачу шул заманның үз эчендә генә мөмкин түгел. Сергей Есенинның «Лицом к лицу лица не видать» дигән сүзләре бар. Алар дөрес сүзләр дип саныйм. Ә болай уйлаганда, алгарак йөгереп чыгып, шушы заманга ерактан — киләчәктән карарга теләү — бусы һәрбер шагыйрьнең хыялы. Шуңа омтылу һәм ирешә алмау — озын гомерле иҗади стимулятор.

**М.Вәлиев.** Җавап биргәндә сез минем сүзләрдән бер моментны искә алмадыгыз. Ә ул кайбер төсмерләрне ачыклау өчен бик мөһим булыр иде. Сүз 60 нчы һәм 70 нче еллар тормышының поэзиядә чагылу дәрәҗәләрен чагыштырып карау турында бара. Биредә бит шактый кызыклы һәм игътибар ителердәй бер күренеш күзгә ташлана: аерым алганда, ул сезнең буын шагыйрьләрнең иҗатында да сиземләнә. Ул буын 60 нчы елларда үзенең шигырьләрендә нәрсәгәдер каршы чыга, нинедер яклый, ул көрәшә, ул даулый. Шигырьдә ярсып яшь йөрәк тибә, йөрәк яши. Һәм әнә шундый шигырьләр укучыга да якынрак, кадерлерәк, кирәгрәк кебек иде. Ничектер укучы үзенең күңелен ул шигырьләр белән тизрәк тоташтыра ала иде, алар белән бер җан булып яши башлый иде. Ә хәзер, сезнең буын шагыйрьләрнең соңгы елларда чыккан шигырьләрендә исә, йөрәк эчкәрәк күчкән кебек, ул хәзер сакланганрак һәм хәтта, шактый гына дәрәҗәдә, акылга таба якынайганрак бугай. Баштагы еллар шигырьләрендәге көчле хис, омтылыш, теләк хәзер күзәтү тирәнлеге, фикер куәте, нәтиҗәләр ясау көче булып әверелгән, әйтерсең кеше башта, дөньяны үзгәртәм дип, зур дәрт белән тотына да...

**Р.Харис.** Шулай ук булды микәнни?!

**М.Вәлиев.** Мин сезнең буынның 60 нчы еллар иҗатын нигездә шул омтылыш билгели дип саныйм... Иҗатның этәргеч көче һәрвакыт — нидәндер канәгать булмау, ләкин дөньяның нык каршылыгына очрап, кеше, гадәттә, дөньяны үзгәртү өчен башта аны аңларга, белергә кирәклегенә төшенә һәм, бөтен көчен куеп, олы дөньяны күзәтә, өйрәнә, нәтиҗәләр чыгара башлый. Зур мәгънәле, тормышның шактый тирән катламнарын колачлый торган нәтиҗәләр... Сүз уңаенда сорыйсы килә: сез шундый эволюция кичергән үз буыныгыз турында бүген ни уйлыйсыз? 60 нчы еллар һәм 70 нче еллар поэзиясендәге аның урыны хакында? Һәм шул вакыт аралыгындагы тормышның поэзиядә рухи ачылуы хакында?

**Р.Харис.** Бик сиздермәскә тырышсагыз да, сезнең тел төбегезне, әйтергә теләгәнегезне аңлыйм. Сез, заманның рухи эчтәлеген ачу дигән булып, шул проблема җирлегендә, безнең буынны бераз гаепләргә, аның чын тормыштан китә төшүенә канәгатьсезлек белдерергә телисез...

**М.Вәлиев.** Хәерле булсын, әйдәгез шулай дип уйлыйк!

**Р.Харис.** Ә мин болай дим: поэзия ул — һәрвакыт көрәш нәтиҗәсе! Аның максаты да көрәш! Әйтик, югары әхлак нормалары өчен, чын матурлыкны яклап, тормыштагы җитешсезлекләргә каршы көрәш. Ләкин ул көрәш төрле вакытта төрлечә импрессивлыкта (тәэсир көче) һәм югарылыкта, тонда була. Бүген шигырьнең тавыш көче кимрәк, ул тынычрак, ул зур аудиториягә түгел, ә күп чагында кешенең үзенә генә адреслана. Без поэтик күренешләргә дөрес бәя бирергә телибез икән — ул күренешләрне үсештә, үзгәрештә, перспективада күрергә һәм тормыш үзгәрешләре белән бәйләнештә карарга тиешбез... Ә заманның рухи эчтәлеген ачу дәрәҗәсенә килгәндә, ул, минемчә, поэзиядәге барлык иҗат итүче көчләр белән эшләнә торган эш. Безнең буын аңа күпмедер дәрәҗәдә үз өлешен генә кертә. Ләкин шуны әйтәсем килә: арабызда бер генә хатын-кыз шагыйрә дә булмау безнең буын шигъриятен ничектер китегрәк итә сыман. Әнә бит Саҗидә Сөләймmanagанова... 

**М.Вәлиев.** Безнең сөйләшү әкренләп урта буын һәм сезнең буын шагыйрьләр иҗаты турында фикер йөртү яссылыгына күчте. Минемчә, бу поэзия турындагы дискуссиянең үзен дә киңрәк колачлы итә. Чөнки моңарчы басылып чыккан язмаларда күбрәк ике генә буын — өлкәннәр һәм яшьләр буыны гына телгә алына иде. Болай тулырак итеп күрергә тырышу безгә кайбер тенденцияләрне сиземләү мөмкинлеге дә бирәдер. Чөнки дәвамлы итеп караганда, үзгәрешләрнең юнәлешен тоемларга, ачыкларга мөмкин. Әле менә югарыда сезнең буынның нинди эволюция кичерүен карап үттек. Ә киңрәк итеп караганда, гомумән, татар поэзиясен колачлап фикер йөрткәндә, без соңгы елларда нindirәк тенденцияләр күрәбез соң? Поэзиянең бүгенге хәлен ачыклау нияте белән сөйләшкәндә бу момент бик мөһим булырга тиеш... Ә минем үз карашыма килгәндә: элегрәк сиземләнгән җанлылык, яшәешнең төрле-төрле күренешләрен аңларга һәм аңлатырга омтылу, шуның белән поэзиянең үзен дә зурайту, аның көчен, миссиясен арттыру тенденциясе соңгы вакытта бераз йомшара төште кебек. Бик примитивлаштырып әйткәндә, соңгы елларда безнең поэзиядә яңадан (минем яңадан диюем 50 нче елларда булып алганнан соң тагын килде дигән мәгънәдә) нindiдер бер шомалык, нормативлыкка буйсыну чаткылары сизелә кебек. Укучыларыбызның күпчелеге проза әсәрләренә ябырылуның да бер сәбәбе шул түгел микән, ягъни поэзиядә җанлы яшәеш нык кимегәнгә түгел микән?

**Р.Харис.** Андый ук нәтиҗә ясарга җөрьәт итә алмыйм. Әмма, соңгы елларда поэзиябездә булган үзгәрешләр турында сүз чыккач, шуны әйтергә кирәк: минем үземне куандырган хәл — ул шигъри сүзнең җегәре арту, аның күбрәк экспрессивлык (кичерешләр) һәм импрессивлык (тәэсир итә алу) сыйфатларына ия була баруы, сүзнең шигърилек функциясе алга чыгу. Сүзнең — җөмләдәге, җөмләнең шигырьдәге җегәре арту. Мисал өчен нибары өч сүз алыйк: йөрәк, колак, саңгырау. Гап-гади сүзләр. Ә шагыйрь Назыйм Хикмәт шул ук сүзләр белән менә нәрсә ди: «йөрәкләрнең колаклары саңгырау». Күрдегезме, өч сүзне ныклап бер тәртипкә тезеп куйгач, һәр сүзнең мәгънәсе ничек артты! Җөмләләрне дә шулай ук тезеп һәм тикшереп була. Минемчә, хәзер шигърият җөмләләр арасындагы мөнәсәбәтләрне дә кызыклы, интенсив итү буенча күп эшли.

**М.Вәлиев.** Сезнең бу нәтиҗәләр татар поэзиясенә дә тулысынча кагыла дип саныйсызмы?

**Р.Харис.** Кагылырга тиеш дип саныйм. Һәрхәлдә, поэзиябездә барган эзләнүләрнең иң файдалылары, иң кызыклылары шул өметне раслый. Ә ул эзләнүләрнең иң җитдиләре итеп мин мәгънәви яктан — риторикадан качарга тырышуны, ассоциацияләр аша сүзнең җегәрен арттырырга омтылуны, ә форма ягыннан — строфалар арсеналын төрлеләндерүне, ак һәм ирекле шигырь мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итүне саныйм.

**М.Вәлиев.** Минемчә, сүзнең җегәре арту тенденциясе һәм аның белән бәйләнгән күренеш — поэзиянең көче, тәэсире көчәю мәсьәләсе чыннан да игътибар үзәгендә торырга тиешле мәсьәлә. Ләкин әле һаман — кеше үз өстенә ябырылган информация яңгырыннан кая керер урын тапмаган бер чорда да — бездә бик озын һәм көпшәк язылган шигырьләр еш очрый. Аларның күбесенең әйбәт нияттән язылган булуын да тоясың, ул әсәрләр җан җылысын җылы юллар, җылы интонация аша бирергә тели. Ләкин күп вакыт, әнә шул җылы интонация үзе генә калып, сүзләр, артык җебеп, йомшап китеп, үз көчләрен югалталар. Алар игътибарны җәлеп итәрлек, үзләренең поэтик информациясен, эчке куәтен белдерә алырлык хәлдә була алмыйлар. Һәм кайчагында бик талантлы гына шагыйрьләрнең дә әнә шундый шигъри әсәрләре очрап куя. Нәтиҗәдә шигырь шагыйрьнең күңелендәге хис, кичерешне укучыга илтеп җиткерерлек булмый. Менә шушы күренешләр турында уйлануларның нәтиҗәсе буларак бер сорау туа: әллә соң бүген шагыйрь шәхесенә булган таләп бераз үзгәрдеме икән? Әллә ул бүген бераз башкачарак булырга, дөнья үзгәреше аркасында килеп ту-

ган яңа якларны да исенә алып яшәргә һәм иҗат итәргә тиеш микән?

**Р.Харис.** Шагыйрьләргә бер дә үзгәрми торган бердәнбер таләп бар. Ул — талант. Ләкин бүген мондый гади җавап кына дөрес булып ук бетмәс иде. Чөнки мәсьәлә катлаулырак. Талантка гына кайтарып калдыру тулы аңлату булмаячак. Элегрәк, поэзия турындагы чыгышымда, Сибгат ага Хәкимнең бер шигырен мин «бөтнек исен аэропорт исе белән органик куша белгән шигырь» дип бәяләгән идем. Шушы ук сүзләрне мин бүгенге көн татар шагыйренә карата да әйтер идем. Һәм тагын шуңа өстәп «чын мәгънәсендә югары белемле булу» дияр идем. Әлбәттә, югары белемне турыдан-туры тормыштан алу да мөмкин. Ләкин югары уку йортында системалы югары белем алу «аңлы шарт» (осознанная необходимость) булырга тиеш. Шигырь нигезендә информация ята. Әнә шул информация инде сан ягыннан да (ул без белмәгән булырга тиеш), сыйфат ягыннан да (җиткерү ысулы, «көтелмәгән» моментлары булу) югары дәрәҗәдә һәм компетентлы булырга тиеш. Ә моның өчен «Ходай биргән» акыл һәм хис белән генә ерак китеп булмый, чөнки хәзер фән-техника революциясе заманы.

**М.Вәлиев.** Безнең поэзиядә әле һаман ниндидер бер «йомшак» як, аңа киң күләмдә яңгыраш табарга, башка халыклар укучыларының да игътибарын җәлеп итәргә комачаулый торган бер җитешсезлекме, тарлыкмы бар сыман. Без үз хәлебездән шактый канәгать яшәсәк тә, үз даирәбездә генә яшәвебезгә инде иялнеп беткән булсак та — барыбер, үзәктә басыла торган журналларны кулга алып уку белән, андагы шигъри әсәрләр арасында үзебезнең халык рухын чагылдырган, аның күңел яңгырашы булган шигырьләр җитмәве үзен бик сиздерә. Билгеле, моңа тәрҗемә белән бәйләнгән кыенлыклар да тәэсир итми калмый торгандыр. Ләкин, минемчә, бу хәлнең төп сәбәбе, иң мөһим сере эчтәрәк ята кебек.

**Р.Харис.** Безнең шагыйрьләрнең бөтенсоюз аренасына чыгу мәсьәләсе — комплекслы мәсьәлә. Монда аерым шагыйрьләрнең шәхес буларак индивидуаль сыйфатлары да, безнең гомуми шигырь культурабыз да, бөтен әдәбиятыбызның абруе да, тәнкыйтьнең дәрәҗәсе дә һ.б. зур роль уйный. Ләкин бер факт бәхәссез: ел саен үзәк журналларда һәм китап нәшриятларында татар шагыйрьләренең әсәрләре чыгып тора, әмма алар бөтенсоюз укучысы алдында татар шигъриятенең абруен тагын да күтәрә алмыйлар. Без сан ягыннан җитәрлек чыгабыз, ә зур итеп яңгырый алмыйбыз. Ни өчен? Минемчә, чын мәгънәсендә олы шигырьләребез аз. Үзенчәлекле, чатнап торган образлы, олы фикерле шигырь, теләсә нинди тәрҗемә киртәләрен дә җиңеп, үзенең асылын саклап кала. Бөтен җитешсезлегебезне тәрҗемәгә генә сылтарга тырышу — безнең ваклыгыбызның, көчсезлегебезнең бер күрсәткече.

**М.Вәлиев.** Хәзер, минемчә, шундый фактны искә алу бик мөһим бугай: гомумкультура үсү белән поэзия әсәренә караш бик нык нечкәрде, олыгайды, тирәнәйде. Укучының зәвыгы үсте. Тирән нәфислеккә омтылыш көчәйде... Ләкин «нәфислек» дидем дә, үзем дә бераз уйланып калдым. Без бит бүген үзләренең «кытыршы» шигырьләре белән танылган Андрей Вознесенскийда да, Олжас Сөләймановта да нәфислек, зур шигърият табып, соклана-соклана укыйбыз. Алар бит югыйсә Сергей Есенин стилендәге шигырьләрдән бик нык аерылып торалар. Ә үзебездә алсак: С.Хәкимнән, Н.Арслановтан, Ә.Баяновтан шигъри дөньялары белән шактый үзгә булган Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалимов иҗатлары да халыкта шулай ук киң танылу тапты. Бер карауга алар бик төрле, хәтта капма-каршы иҗат манерасына ия шагыйрьләр. Ләкин шигырьләрендә ниндидер бер уртак нәрсә бар кебек.

**Р.Харис.** Чын әдәби, югары художестволы әсәргә — нинди генә илнеке, кайсы чорныкы һәм нинди жанрда булуына карамастан — бер нәрсә хас: шигъриятлелек. Шигъриятлелек дип мин менә нәрсәне аңлыйм: олы язмыш, гыйбрәтле ситуацияләр, көтелмәгәнчә фикер йөртүләр белән очрашканнан соң, күңелдә уянган канәгатьләнү хисе ул. Шигъриятлелек кеше гүзәллеге белән бәйле. Ул бер шигырь юлларына гына хас сыйфат түгел. Музыканы, скульптураны, графиканы, архитектураны да кеше күңеленә тоташтыручы, сәнгать итүче ул — шигъриятлелек.

**М.Вәлиев.** Димәк, гадиләштереп әйткәндә, поэзиянең төп юлы да әнә шул шигъриятне тагын да тулырак итеп ачу булырга тиеш. Эзләнүләрнең юнәлеше әнә шул якка таба барырга тиеш. Чыннан да, бик олы һәм чиксез ерак, ләкин матур максат бит ул... Шуңа күрә безнең күптөрле сөйләшүләрдә «поэзиягә яңа эзләнүләр кирәк, алардан башка шигърият үсә, яши алмый» дигән сүзләр еш яңгырый. Ләкин менә реаль тормышта, әдәби процесста еш кына әнә шул чакыруның мәгънәсе онытылып китә, шигъри әсәрләрнең элек күнегелгәнчә, иялнелгәнчә генә язылуы таләп ителә башлый. Мондый караш, әлбәттә, яшьләрнең поэтик индивидуальлеген сүндерә, аны гомумстандартларга якынайта.

**Р.Харис.** Дөрес, «эзләнү» турында без сөйләшергә яратабыз. «Эзләнергә кирәк, эзләнүсез поэзия юк» дип, үгет-нәсихәтне дә еш бирәбез. Бер карасаң, «эзләнергә кирәк» дигән фикер — буш фикер, кысыр фикер, чөнки артык абстракт, артык гомуми, хәтта мәгънәсез. Эзләнергә өндәп була, хәтта эзләнү юнәлешен күпмедер билгеләп тә була, ләкин эзләнергә беркемне дә өйрәтеп булмый. Мин кемнәндер эзләнергә өйрәнәм икән, мин аның ахыр чиктә йә игезәге, йә начар копиясе булам. Сәнгатькә игезәкләр кирәкми. Икенче карасаң, «эзләнүләр кирәк» дигән фикер олы мәгънәгә ия. Поэзия — үзе эзләнү нәтиҗәсе. Хәтта графоман да эзләнә, ләкин ул, чын шагыйрьдән аермалы буларак, таба гына алмый, ачыш ясый алмый, чөнки таланты җитми. Эзләнү — иҗат итү, ягъни иҗат процессы. Ул процесс поэтик табыш белән төгәлләнгәндә генә дөньяга яңа шигырь туа. Процесс күренмәскә, сизелмәскә тиештер дип уйлыйм. Эзләнү иҗатның эчкәреге, яшерен ягы. Аны күрсәтмичә генә укучы аңын шигъри табышка алып барып җиткерә белү осталыктан килә.

Кайвакытта безнең буын шагыйрьләрен формализмда гаепләп куялар. Әйтергә кирәк, татар поэзиясе беркайчан да формализм белән чирләмәде һәм чирләми дә. Эш шунда ки, безнең кайбер шигырьләребезнең әнә шул эчкәреге ягы, эзләнү процессы күренеп-күренеп китә. Билгеле, бу — осталык җитмәүдән генә.

Кыскасы, эзләнү — индивидуаль эш, һәр әдипнең иҗади сере. Эзләнү шагыйрьне үзе генә белгән юллар һәм ысуллар аша табышка, ачышка китерә. Табыш яки ачыш — сүзләр, җөмләләр тезмәсен шигырь итә. Фәкать табышка карап кына шагыйрьнең культура дәрәҗәсен, интеллектуальлеген, талантының зурлыгын чамалап була. Бер очракта шигъри табыш тормышның вак-төякләрен, ә икенче очракта иң актуаль проблемаларын колачлавы мөмкин. Бер үк шагыйрь иҗатында вак «балыкларны» да, эреләрен дә очратабыз. Кайберләребезнең иҗаты мең вак балык янына бер-ике эресе эләккән җәтмәне хәтерләтә. Андый табыш, реаль булса да, «булуы мөмкин түгел» дигәнрәк тәэсир калдыра. Табыш чор кешесе язмышының иң киеренке, югары нокталарын ни дәрәҗәдә чагылдырса, шигырь, шагыйрь шул дәрәҗәдә әдәбият өчен, укучы өчен кызыклы.

Шигырьләрнең үзебез күнеккән тәртиптә язылуын таләп итү, минемчә, табигый нәрсә, чөнки критерийлар яуланган казаныш биеклегендә генә була. Критерийлар һәрвакыт күпмедер дәрәҗәдә консервативлар.

Остазлар яки тәнкыйть тәэсире астында бетә торган индивидуальлеккә шул кирәк — бетсен. Тәнкыйтьне тыңлый белергә дә кирәк. В.Солоухин әйтмешли, художник һәркем сүзенә, бигрәк тә киңәшенә колак салып, беркемне дә тыңламаска тиеш. Безне аерым кешеләр түгел, ә әдәбиятның культура дәрәҗәсе өйрәтергә тиеш. Иҗади шәхесләрне күреп ала белү, аңа, индивидуальлегенә кагылмыйча, уңай йогынты ясый белү — югары культурага ирешкән әдәбиятларга гына хас олы сыйфат.

**М.Вәлиев.** Сүзебезне поэзиянең гражданлыгы турындагы уйланулардан башлаган идек, инде менә аның культура дәрәҗәсе кебек мәсьәләләргә дә килеп чыктык. Һәм, минемчә, бу бәйләнеш дөрес, табигый, кирәкле бәйләнеш. Чөнки гражданлыкның яшәү җирлеге — кешенең реаль тормышы ул, аның ничек яшәвеннән килеп чыга торган күренеш. Чын гражданлык... Аның ныклыгы, ышанычлыгы... Ул нәрсәләргә бәйләнгән соң? Бу мәсьәләләр бүген поэзия өчен генә түгел, ә, гомумән, олы тормышта да бик җитди итеп куела. Бигрәк тә яшь буынны тәрбияләү, аның формалашуы белән бәйле рәвештә караганда бу проблеманың әһәмияте зурая. Чөнки гражданлык шәхеснең иң асыл сыйфатлары булу-булмавын күздә тота. Ә ул сыйфатларның нигезе, иң беренчесе, минемчә, һичшиксез, кешенең табигый, үз күңеленә тугры яши алуы. Бары тик шул чакта гына без шәхеснең һәр урында кешелекле, гуманистик адым ясаячагына ышана алабыз. Минемчә, бүген әле бездә гражданлыкны әнә шушылай итеп — кеше күңеленең табигый дәвамы һәм органик өлеше итеп карау җитми. Кеше җанының бер ягы итеп, олы җанның бер чагылышы итеп. Чын мәгънәсендә көчле, олы җан илгә, халыкка мөнәсәбәтендә дә олы һәм кешелекле була, гражданлык аның асылының, кешелек үзәгенең бер табигый ягы гына була. Ул шәхес өчен бернинди каршылык, трагедия дә тудырмый. Ягъни шәхес омтылышы белән гражданлык омтылышы арасында аерма булмый.

Ә безнең поэзиянең гражданлык көче ни өчен без теләгәнчә түгел соң? дигән сорау куйсак, шигъриятебезнең үз җаны тормыш белән әнә шулай органик берлектә яши алу дәрәҗәсенә ирешкән олы шәхесләрнең, шагыйрьләрнең азрак икәнен күрербез... Олы шәхес бит ул үзенең яшәвендә һәм иҗатында бернинди чикне, кискен бүленешне белми. Без еш сөйли торган темалар бүленеше, актуаль яки искергән нәрсәләр, ярый торган яки ярамый торган фикерләр, хисләр аның өчен, гомумән, юк. Аның яшәве, аның поэзиясе — бер бөтен катлаулы реальлек ул. Олы шәхеснең һәр шигырендә әнә шул тирән катлаулылыкның бер чагылышы була. Бик күп тамырлары, бәйләнеш җепләре белән бергә. Шулай иҗат итүче шәхеснең һәр шигыре, һәр язмасы ул — чын гражданлык сүзе. Ул иң беренче чиратта кешене үзенең ихласлыгы, кешелеге, көче белән җәлеп итә. Ул, иң яхшы лирик шигырь кебек булып, кеше җаны өчен кадерле, аңа тансык сүз итеп кабул ителә.

**Р.Харис.** Әйе, әдәбиятның үсешен шәхесләр билгели. Әйтик, бик уңышлы бер әсәр, әдәбиятның бер жанрын гына түгел, аны тулаем үстереп җибәрә. Үз нәүбәтендә андый әсәр — әдәби шәхеснең үсеп китүе дигән сүз... Әдәбиятка яңа исемнәр килә. Алар, әлбәттә, әдәби процесска да йогынты ясыйлар. Соңгы ун-унбиш ел эчендә безнең поэзиягә шактый кызыклы исемнәр килеп керде. Хәзерге көндә өлкәннәр белән бергә поэзиябезнең төп буынын тәшкил иткән Г.Афзал, Ә.Баянов, Ш.Галиев, М.Шабаев, И.Юзеев, Роб.Әхмәтҗанов, С.Сөләймановаларга тагын яшьләр — Р.Гатауллин, Р.Мингалимов, Г.Рәхим, Р.Фәйзуллин, Рәш. Әхмәтҗанов, Ф.Яруллин, бераз соңрак Зөлфәт, М.Әгъләмов, Ф.Сафин, М.Галиев, З.Насыйбуллиннар кушылдылар. Бу шагыйрьләрнең поэзия үсешенә йогынты ясаулары көн кебек ачык.

**М.Вәлиев.** Димәк, поэзиябезнең бүгенге торышын билгеләүдә башка шагыйрьләр белән бергә аларның иҗатлары да катнаша дигән сүз. Ә ул иҗат дөньяларының көче, әйткәнебезчә, шагыйрь шәхесенең көче, аның дөньяны, тормышны тоемлау тирәнлеге белән билгеләнә. Шигърият, аның күп кенә төп сыйфатлары, шулай итеп, шәхестән, аның кем булуыннан, нинди булуыннан, ничек итеп яшәвеннән башлана. Димәк, безнең поэзия турындагы бу әңгәмәбез дә үз тирә-юнебездәге шәхесләргә багу, карашларыбызны иҗади шәхесләргә юнәлтү белән төгәлләнә... Ышаныч һәм өмет тулы карашларыбызны...

*1978*

# Традицияләр яши, яңара

*(Ф.Мусин белән диалог)*

**Ф.Мусин.** Агымдагы әдәбият турында сөйләшүләр алып бару хәзерге әдәби тормышның мөһим сыйфатына әверелде. Әллә әдәбиятның гомумторышына яки аның аерым өлкәсендәге хәлләргә, әле теге яки бу мәсьәләгә багышланып үткәреләләр алар. Мондый эшнең максаты нindидер мәсьәләне хәл итүдән бигрәк, киң әдәби җәмәгатьчелек игътибарын аңа юнәлтүдә, бу хакта коллектив рәвештә уйлануда, фикерләшүдә.

Башкарак максатлар да булуы ихтимал.

**Р.Харис.** Иҗат проблемалары, аерым әсәрләр, язучылар турында газета-журнал битләрендә, радио-телевидение буенча диалоглар, публичный әңгәмәләр үткәрү — әдәбиятны пропагандалауның иң нәтиҗәле ысулларының берсе. Залдан килгән сораулар да, аларга бирелгән җаваплар да залдагыларда һәм телевидение тамашачыларында бер дәрәҗәдә кызыксыну уяталар. Соңгы елларда Казанда да әдәбият, сәнгать мәсьәләләре турында шундый сөйләшүләр алып барыла башлады. Драматург Туфан Миңнуллин, композитор Фасил Әхмәтов Актерлар йортында әдәбият-сәнгать сөючеләр белән очраштылар һәм аларның зал белән әңгәмәсе телеэкранга да чыкты. Аларның ихлас сүзләре, кызыклы күзәтүләре, фикерләре йөзләгән мең кешегә җиткерелде, аларга иҗат дигән серле дөньяның кайбер аланнары, урман-сулары күрсәтелде. Мондый сөйләшүләр, һичшиксез, иҗатчылар өчен дә кирәкле, әдәбият сөючеләр өчен дә файдалы.

**Ф.Мусин.** Инде әлеге сөйләшүләрнең кыйммәте, язучыларга һәм укучыларга тәэсир көче турында сүз чыккан икән, биредә, минемчә, хәлиткеч рольне әңгәмәдә катнашучыларның тикшерелә торган мәсьәләләрне никадәр тирән аңлавы, аларга шәхси мөнәсәбәте уйный. Матбугатта бер күренү нияте белән генә (кайчак шулай да була) катнашамы ул мондый сөйләшүдә, әллә инде бу хакта сүз әйтми кала алмаганнанмы?

**Р.Харис.** Шәхси мөнәсәбәт, гомумән, иҗатның нигезен тәшкил итә, иҗатның ансыз булуы да мөмкин түгел. Ләкин кайбер әсәрләребездә, шул исәптән тәнкыйть мәкаләләребездә дә, очраштыргалый торган «бу миңа ошый, бусы ошамый» кебегрәк «бәяләр» әле шәхси мөнәсәбәт түгел. Тормыш күренешләрен, ил, халык язмышларындагы вакыйгаларны үз тәҗрибәң биеклегеннән торып, үз эрудицияң ярдәмендә яктыртып күрсәтү — менә художникның шәхси мөнәсәбәте. Ни өчен ошаганын, ни өчен ошамаганын аңлатканда язучының темпераменты да, кыюлыгы да, ихласлыгы да ачык күренә. Ачык әңгәмә үткәрү, йә булмаса, шундый әңгәмәдә катнашу — язучы иҗатының бер төре. Сөйләшүне кызыклы һәм файдалы итә торган иң беренче сыйфат, минемчә, әңгәмәдәшләрнең бай натурасы. Икенчесе — күңел байлыгың белән халык алдында ачыктан-ачык уртаклашу осталыгы. Ә менә бу мәсьәләдә тәҗрибәне байтак җыясы бар әле безгә.

**Ф.Мусин.** Әдәбият ихлас күңелдән сөйләшүне, уйлануны сораучы мәсьәләләрне көн тәртибенә куеп кына тора. Еш кына алар бер бүген генә хасил булмыйлар, елдан елга, дәвердән дәвергә үз әһәмиятләрен югалтмыйча, кайчак, киресенчә, яңа шартларда яңа яңгыраш алып күчеп киләләр. Шундыйларның берсе — һичшиксез, әдәбиятта буыннар бәйләнеше, бүгенгеләрнең үткәндәгеләр тормышына һәм иҗат мирасына мөнәсәбәте. Икенче төрле әйткәндә, традицияләргә караш, аларның хәзерге әдәбияттагы роле.

**Р.Харис.** Татар шигъриятенең традицияләре тирән һәм бай. Шигырьнең эчтәлегенә, жанрларына, төзелешенә, сурәтләү чараларына бәйле традицияләр белгечләребез тарафыннан өйрәнелеп, тикшерелеп торалар. Заманасында Тукай, Такташ традицияләре турында газета-журнал битләрендә зур сөйләшү дә булган иде. Бу дискуссияләрдән соң 10–15 ел вакыт узды. Татар шигъриятендә кызыклы үзгәрешләр булды. Менә бүгенге поэзиядә борын-борыннан калган, Тукайлардан, Такташлардан, Җәлилләрдән килгән традицияләр нишләгәннәр икән, конкрет шагыйрьләр иҗатына алар ничек тәэсир иткәннәр икән? — традицияләрне өйрәнүнең бу яклары, минемчә, безнең алга яңа таләпләр куя. Бүгенге шигъриятебезне башка әдәби традицияләр контекстында карау да бик өлгергән мәсьәлә. Болар, билгеле, шактый катлаулы эш, чөнки үткән буыннардан килгән традицияләр яңа буын иҗатында Кама суы Идел суында югалган кебек эзсез югалалар. Хәтта югалырга тиешләр! Әдәбият кабатлануны күтәрә алмый. Әдәби буын йә шәхес ничаклы көчле булсалар, аларның иҗатында традицияләрнең чиста эзләрен күрү шулчаклы кыенлаша. Гасырлардан килгән традицияләрне үз иҗатында эретеп, аларны башка әдәби традицияләр белән кушып, үз мирасы нигезендә яңа «эретмә» ясый алган шагыйрь генә үзенчәлекле була. Андыйларга, табигый, әүвәл сәерсенеп карыйлар, милли традицияләрне бозуда гаепләргә тырышучылар да табыла. Ә бераздан барысы да үз урынына баса — традицияләрне «бозган» яңалыклар үзләре традициягә әвереләләр.

**Ф.Мусин.** Элек-электән әдәби-эстетик фикернең игътибар үзәгендә торган бу мәсьәләнең безнең көннәрдә үзенә бер актуаль төс алуының үзенчәлеклерәк сәбәпләре дә бар. Мәгълүм ки, соңгы вакытта әдәби традицияләрнең «арыганлыгы» (бигрәк тә зур тарихлы әдәбиятларда), шунлыктан хәзерге язучыларга йогынтысы кими һәм хәтта бетә баруы турында сөйли башладылар. Гадәттә традицияләрне үстерүне берьяклы яки гадиләштереп аңлату белән бәйләгән мондый карашлар, әлбәттә, бәхәс уяталар.

**Р.Харис.** Традицияләрнең «аруы-ялыгуы» белән һич килешеп булмый. Әдәбият алга барган саен, аның традицияләре дә байый, ишәя, ныгый — ябалдашны югары күтәргәндә кәүсә ныгыган, юанайган кебек, тамырлар тармакланган, тирәнәйгән кебек. Традициянең бар байлыгы, барлык мөмкинчелеге, әлбәттә, бер шагыйрь йә бер буын тарафыннан бер үк вакытта бер үк тулылыкта файдаланылмый. Аның кайбер яклары вакытлыча икенче планга күчеп тора, һәм тормыш таләпләре аларны беравыктан яңадан алгы планга чыгара. Ә гражданлылык, интернациональлек, гуманизм, халыкчанлык, идеялелек традицияләре беркайчан да, бернинди ситуацияләрдә дә үз позицияләреннән чигенеп тормыйлар, аларның дәрт-дәрманы чиксез. Традицияләр һаваның кислородын канга күчерүче кан күзәнәкләре кебек: үзләре сизелмиләр, ә аларсыз яшәү, тышкы мохит белән аралашу мөмкин түгел. Әйтик, Һади Такташ, Муса Җәлил иҗатларында аеруча көчәеп китеп традициягә әверелгән иҗади казанышлар хәзерге буын шагыйрьләренә йогынты ясау гына түгел, тагы да үсәләр, ныгыйлар һәм татар совет поэзиясенең публицистик рухын, көрәшче сыйфатларын көчәйтәләр.

Кыскасы, традицияләрнең «аруы»н мин күз алдыма китерә алмыйм.

**Ф.Мусин.** Әйе, алар белән килешеп булмый. Чөнки боларның нигезендә үткәндәге әдипләр эшчәнлегенең бүгенге язучы һәм аның иҗаты өчен әһәмиятен инкарь итү ята. Бу хәлнең үз чиратында әдәбиятта буыннар бәйләнешен, алар арасындагы идея-эстетик күчемлелекне юкка чыгаруга китерүе мөмкин. Менә ни өчен

соңгы вакытта һәм матбугат битләрендә әдәби классикага, бигрәк тә совет классикасына кабат игътибар көчәйде. М.Горький, В.Маяковский, совет әдәбиятына нигез салган башка күренекле әдипләр мирасының хәзерге әдәбият өчен әһәмияте турында зур-зур сөйләшүләр булып узды. Аерата классикларның бүгенге әдипләргә нинди сабаклар бирүләренә, алардан нәрсәгә һәм ничек өйрәнергә кирәклегенә дикъкать ителде. Дөрестән дә, без бүген классиклардан нәрсәгә өйрәнә алабыз соң? Алар безгә нәрсәдә үрнәк була алалар? Иң әүвәл, минемчә, язучының үз хезмәтенә ничек каравында, нинди максатлар алга сөрүендә, кыскасы, аның иҗат позициясендә.

**Р.Харис.** Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким иҗатларында безне һәрвакыт сокландырган сыйфат — көн, заман биографиясен үзләренең йөрәк биографияләре, хис биографияләре итү. Аларның әсәрләрендә көннең аһәңе, кәефе, ритмы, темпы гына түгел, көннең иң әһәмиятле вакыйгалары, иң принципиаль эшләре, көнне алга тартып барган кешеләрнең конкрет язмышлары, кайгы-шатлыклары, уй-фикерләре. Без, шагыйрьләр, моңа сокланабыз икән, димәк, өйрәнәбез дә.

**Ф.Мусин.** Чын поэзиянең бик күптәннән килә торган күркәм бер сыйфаты бар. Аның кайчан һәм ничек хасил булуы турында борынгы легенда болай сөйли. Икенче Мессен сугышы вакытында (безнең эрага кадәр җиденче гасырның икенче яртысында була ул) дошманны үз көчләре белән җиңә алмаячакларына ышанган спарталылар, хәрби ярдәм һәм булдыклы гаскәр башлыгы сорап, афиналыларга мөрәҗәгать итәләр. Тегеләре исә болар урынына аксак укытучы Тиртейны җибәрәләр. Әмма походта вакытта Тиртей үзенең ил азатлыгы өчен көрәштә, батыр ирләр булырга чакырган шигырьләре һәм җырлары белән спарталыларны шулкадәр рухландыра, рухи көч бирә ки, алар бермә-бер көчле дошманнарын җиңеп чыгалар. Ә борынгы грек шагыйре Тиртей тарихта поэзиягә гражданлык мотивларын алып керүче булып танылa. Бу мотивлар, моннан соң гасырдан гасырга һәм буыннан буынга күчеп килеп, поэзиянең асыл сыйфатына әвереләләр. Алар татар шигъриятенең дә иң әүвәлге һәм иң беренчел мотивларыннан. Бу хакта уйлаганда иң элек тарих түреннән Кол Гали алга баса. Инде менә 750 ел дәвамында, халык хәтерендә яшәп килүче атаклы поэмасында, заманының иң күркәм һәм иң изге идеалларын чагылдыру белән бергә, ул бу идеаллар өчен кулына корал тотып та көрәшкән. Шушы нәрсә борынгы шагыйрьнең шәхесен дә, әсәрен дә үлемсез иткән. Кол Галидән соң безнең поэзия нинди генә сынаулар кичермәгән дә нинди генә югалтуларга дучар булмаган! Әмма борынгы сугышчы шагыйрь идеаллары юкка чыкмаган. Дәвердән дәвергә күчә килеп, алар безнең Тукай, Такташ, Җәлилләр иҗатында яңа яңгыраш алдылар. Бу шагыйрьләр дә халык, заман идеаллары белән янып яшәделәр, аларны үз идеалларына әвереләдерделәр, иҗатларын олы максатларга багышладылар. Бу яктан алар бүгенге шагыйрьләргә дә үрнәк булып торалар.

**Р.Харис.** Әмма мин бүгенге татар совет поэзиясенең гражданлык рухы, тормыш белән элемтәсе кимеде дип һич тә әйтмәс идем. Дөрес, кайбер шагыйрьләрнең «Казан утлары» журналында һәм башка басмаларда чыккан аерым әсәрләрендә йә шигырь тупламаларында без әле еш кына «мәңгелек» темаларга һәм проблемаларга фәлсәфә сатулар белән очрашабыз. Кайвакытта без үзебезнең күңел чоңгылларына шулчаклы тирән чумабыз ки, көн белән, заман белән бәйләнеш беравыкка өзелә һәм кислород, яктылык җитмәүдән хәлсез булып яралган, идән астында үргән бәрәңге сабагы кебек төссез шигырьләр дөньяга килә... Һәм шул ук шагыйрьләрнең китапларын, йә булмаса, барлык шагыйрьләребезнең бер ел эчендә язган әсәрләрен алсак, һичшиксез, бүгенге татар поэзиясенең заман белән бәйләнеше ныклы булуын ачык күрәчәкбез.

Ләкин бәйләнеш булу үзе генә әле әдәбиятны үстерүче фактор була алмый. Ул аның нигезе, беренче һәм төп шарты. Заманның, чынбарлыкның төрле якларын художестволы өйрәнү-ачуның тирәнлеге, масштаблылыгы, яңалыгы — бу инде әдәбиятның сыйфатын билгеләүче күрсәткечләр. Заманның космик тирәнлеген фәкать зур әдәби шәхесләр генә буйлый ала. Алар гына йөрәкләренә көннең ритмын һәм тизлеген сыйдыра алалар.

**Ф.Мусин.** Заман белән тыгыз бәйләнгән булу, халык тормышында актив катнашып яшәү безнең әлеге классикларны олы шәхесләр итә иде. Бу хәл аларның биографиясендә дә чагыла. Җәлилне генә алыйк. Биографиясе нинди бай бит аның! Инде биш яшьли ул күпне күрә, күпне башкара. Яшүсмер вакыттан ук ул үзен иҗтимагый актив шәхес итеп таныта һәм зур тормыш тәҗрибәсенә ия була.

Ә безнең хәзерге яшь шагыйрьләр? Аларның биографиясе гадәттә бер биткә сыя. Башта без бу хәлгә иптәш әле яшь, олы тормышка яңа аяк баса дип ташлама ясыйбыз, киләчәккә өметләнәбез. Еллар үтә, әмма әлеге иптәш биографиясендә әллә ни яңарыш күренми. Нәтиҗәдә аның бөтен тормыш запасы һаман шул балачакта күргән-кичергәннәренә һәм матбугат белән китаптан укып белгәннәренә кайтып кала. Табигый, бу хәл аның шәхесе үсешендә дә чагылмый калмый.

**Р.Харис.** Язучыны әдәби шәхес итә торган өч нәрсә бар: профессиональ сәләт, характер һәм биография. Бүгенге яшь шагыйрьләр арасында шәхесләрнең азрак булуын мин дә беренче нәүбәттә биографияләренең ярлы булуында күрәм. Версификаторлык осталыгы да җитәрлек, башка әдәбиятлардан кергән традицияләрне дә яхшы үзләштергән, симпатия-антипатияләре дә анык, кыюлыгы да күренеп тора, ләкин әйтер сүзе, фикере генә юк, ә булган очракта — бик сай һәм беркатлы. Поэзиябезнең житешсезлекләрен барлаганда без һәрвакыт яшьләр иҗатына мөрәҗәгать итәргә яратабыз. Билгеле, яшьләр иҗатында алар күбрәк, әмма тәҗрибәле шагыйрьләрдә дә юк түгел. Бүгенге өлкән һәм урта буын шагыйрьләренең, билгеле, кайберләренең, иҗади престижларын бай биографияләре дә саклап кала алмый. Аларның әйтер сүзләре дә бар, әмма характерлары җитми, профессиональ осталыклары да көн таләбеннән калыша.

**Ф.Мусин.** Кайбер яшьрәк авторларның гражданин буларак акрынрак җитлегүләре аларның үз иҗатла-

рына мөнәсәбәтләрендә дә күренә. Үз язганнарыңа җаваплы һәм таләпчән караш җитми башлый, автор күбрәк матбугатта тизрәк күренү хакында кайгырта. Без үзебез дә кайчак теге яки бу каләмдәшебезгә ул чыгарган китаплар санынннан чыгып бәя бирә башлыйбыз. Биредә тагын классиклар хәтергә килә. Мәсәлән, Ә.Фәйзи үзе исән чакта бөтен язганнарының яртысын гына диярлек дөньяга чыгарган. Калганнарын йә әле укучыларга тәкъдим итәргә иртәрәк дип санаган, йә мондый игътибарга лаеклы дип тапмаган. Менә ул — үз иҗатыңа таләпчән карау үрнәге!

**Р.Харис.** Дөрес, без әдипләрнең юбилейлары вакытында аларның китап саннарын да искә алабыз. Ләкин бу — шагыйрьләрнең иҗатларын бәяләүдәге төп критерий түгел. Ә үз иҗатыңа таләпчәнлек — ул мәңгелек проблема. Ә кем белә бит, бәлки, безнең арада да шигъри айсберглар, ягъни язганнары басылганнарыннан күбрәк булган тыйнак шагыйрьләр бардыр.

**Ф.Мусин.** Күптән түгел мин бер күренекле шагыйрьнең шундый сүзләрен ишеттем: «Поэзия профессиональ яктан үсте, әмма ул үзенең нервысын югалтты». Бу фикердә, гәрчә ул кистеребрәк әйтелсә дә, хаклык юк түгел. Әйе, хәзерге шигырь форма камиллегенә омтыла, ә менә мәгънә ягыннан кайвакыт аксый. Андый очракларда авторларга классикларга хас идея ягыннан омтылышлылык һәм инанганлык җитенкерәми кебек. Бу хәл әсәрнең мәгънәви кабатланган булуына һәм икенчел яңгыраш алуына китерә. Нәтиҗәдә шигырьнең җегәрлеге кими.

Гарәп әлифбасы нигезендә укырга һәм язарга өйрәтү дәресләре, сигез йөз еллык татар әдәбиятын, китап нәшриятлары ярдәменнән башка, бүгенге тормышыбызга алып кайтуда бер практик адым дип санала ала. Казанның үзендә, республикабыз шәһәрләрендә, илебезнең төрле төбәкләрендә яшәп, татар телен өйрәнүдән мәхрүм ителгән 5–10 яшькәчә балаларны өй шартларында ана теленә өйрәтү өчен журнал быелның сентябрь аеннан «Татар теле дәресләре» дигән рубрика ача. Киләсе елның маена чаклы бу дәресләрне республикабызның күренекле методистлары һәм язучылар алып барачак. Бүгенге көндә исә редакция АЭС төзелешендә әдәби постын япты һәм татар мәктәпләрен шефлыкка алу планы турында уйлана. Хокукый дәүләт төзелгән шартларда татар халкының мөмкинлекләрен ачыклау да күз уңыбызда тора. Соңгы 30–40 ел дәвамында татар әдәбияты катастрофага тиңләшерлек бер югалту кичерде. Бу — илебез шәһәрләрендә, шул исәптән Татарстан шәһәрләрендә туып үскән татар кешеләрен ана телебездә укучы буларак югалту. Бу процесс алда да дәвам итәчәк әле. Шуның өчен «Казан утлары» үткәрә торган чаралар гына мәсьәләне хәл итмәячәк. Илебездә татарлар күмәкләшеп яшәгән 54 төбәкнең 50 сендә татар мәктәпләре дә, татар балалар бакчалары да тиз арада мәсьәләне хәл итәрлек күләмдә артмаячак. Безгә «Колобок», «Веселые картинки» тибындагы журналларны күпмедер дәрәҗәдә берләштергән ана телебездә чыга торган журнал кирәк. Хәзергә фәкать шушындый татарча «сөйләшә» белә торган журнал гына Татарстаннан читтә булган регионнарда, Казанда, Чаллыда, башка шәһәрләрдә мәктәп вазифасын үти ала... Халыкның, милләтнең киләчәге балаларыбыз кулында.

Татар халкының иҗтимагый аңын үзгәртеп кору чоры рухында тәрбияләү өчен без журналның әнә шул юнәлешләрен бигрәк тә мөһим дип саныйбыз. «Казан утлары»ның йөзен шулар билгеләячәк, аның барлык

материалларына шулар замана төсмере биреп торачак.

Без «Казан утлары»н Татарстанныкы гына дип түгел, бөтен татар халкы журналы дип хис итеп эшлибез һәм аның статусы, республикабыз җитәкчелеге дә булышса, союздаш республикалар журналлары белән бертигез булыр дип ышанабыз. Әгәр дә съезд хупласа, бу юнәлештәге эшне редакция партиянең XIX Бөтенсоюз конференциясе карарлары яктыртылганда тагы да киңәйтә һәм көчәйтә ала.

Ике съезд арасында татар әдәбияты үсештә булды дидек, ләкин ул электән килә торган кайбер җитешсезлекләреннән барыбер арына алмады кебек. Шуларның мин берсен генә, журнал өчен бигрәк тә мөһимен генә әйтеп үтәм. «Казан утлары»на кергән яңа әсәрләр күрсәтә ки, безнең төп игътибарыбыз колхозлашу, Бөек Ватан сугышы алды, сугыштан соңгы авыр чорларга төбәлгән, һәм бу аңлашыла да — татар әдәбиятының шул еллар хакында әйтелмичә калган сүзе күп, бигрәк тә сталинщина турында. Үзләре шул чорда формалашкан язучыларыбызга аның хакында вакытында язарга мөмкинлек бирмәгәннәр. Без, алтмышынчы-җитмешенче елларда әдәбиятка килүчеләр, шулай ук брежневщина турында берни дә әйтә алмадык. Ишеткән, отып алып үзебез сөйләп йөргән тозлы-борычлы социаль анекдотларның үткерлегенә, кыюлыгына шаккатудан, соклanудан уза алмадык. Күңелдә бер фикер йөртеп, кәгазьгә шуның капма-каршысын язарга күнегеп бетә яздык... Нәтиҗәдә, сихәтле Апрель Пленумы (1985) җилләре исә башлагач та, татар әдәбиятының тирән өстәл тартмасыннан элек язылган һәм үз заманын беразга узып киткәнлеге аркасында гына басылмый калган бер генә әсәр дә чыкмады дисәк тә ярый. Бу уйландыра, иптәшләр.

Үзгәртеп кору гаҗәеп зур мөмкинлекләр ачты. Бүген без әдәби фонендоскобыбызны бернидән дә курыкмыйча, перестройканың күкрәгенә куеп, аның йөрәк тибешен тыңлый алабыз, әдәби градуснигыбызны заманның култык астына кыстырып, перестройканың кайнарлыгын күрә алабыз. Әмма өр-яңа әсәрләребез һәм аларда сурәтләнгән вакыт арасында дистәләрчә елларга сузылган дистанция сакланып килә. Зур романнарга күпмедер ташлама ясап була, ә оператив жанрларга ташлама ясарга сәбәп юк. Әлбәттә, без иске материаллар нигезендә дә үзгәртеп кору рухында язарга тырышабыз һәм уңышка да ирешәбез. Әмма әсәрләребездә үзгәртеп коруны башкаручы кешенең уй-фикерләрен, кылган гамәлен тизрәк күрәсе килә. Ул кешенең рухы, өмете киңәя барган космос кебек, ә тәне-бәдәне көнкүреш мөмкинлекләре кысыла барган чынбарлыгыбызда. Романнар, поэмалар, драмалар нигезенә шекспирча конфликт булып ятарлык киеренкелек түгел мени бу?! Татар әдәбиятының вакытында әйтелми калачак, аннары соңгарып, ерактан торып әйтеләчәк сүзләре, минемчә, бүген үк барлыкка килде инде, һәм бу дефицит «Казан утлары»нда үзен инде бүген үк сиздерә. «Казан утлары» дигәннән — сез беләсезме икән — безнең журнал турында бернинди энциклопедиядә дә, хәтта әдәбиендә дә, бернинди энциклопедик сүзлектә дә мәгълүмат юк. Ә башкортның «Агидел», бурятның «Байкал», каракалпакның «Амударья», карело-финның «Пуналипяу», якутның «Хотугу сулус» журналлары турында БСЭдан да, төрле сүзлекләрдән дә укып була. Без редакциядә бу сәер хәлнең сәбәбе турында уйландык. Юк, моны энциклопедия төзүчеләрнең татар халкына булган игътибарсызлыгы белән аңлатырга ярамый, чөнки һәр сүзлектә татар әдәбияты хакында тирән һәм күләмле мәкалә бар. Моны фәкать татар мәдәниятенең, татар әдәбиятының илкүләм абруе хакында кайгыртырга тиешле даирәләрнең, беренче чиратта үзебезнең Язучылар союзы идарәсе һәм фәнни оешмаларның, дистәләрчә еллар буена шушындыйрак мәсьәләләрне күз уңында тотмаулары белән аңлатып буладыр. Мисал өчен ерак йөрисе юк, хәтта съездыбыз докладында да Язучылар союзы органы булган «Казан утлары» телгә дә алынмады, ә республика рәссамнарының күптән түгел булып узган съездында журнал хакында җитди сүз барды. 1984 елда Татарстан Язучылар союзы оешуның 50 еллылыгына багышланган докладында хәтта партия өлкә комитеты секретаре да дөньяда бердәнбер татар әдәби журналы барлыгын «онытты».

Ярый әле безнең арада «иҗади намуслары саф булмаган» анонимщиклар бар, алар «Казан утлары»ның шактый актив журнал икәнлеген төрле даирәләрнең исләренә төшереп торалар.

Әгәр дә шушындый игътибарсызлык «Казан утлары»на карата гына булса, мин аны әйтеп тә тормас идем. Рус телендә басылган гомумсоюз чыганакларында язучылардан Дәрдмәнд, С.Рәмиев, Ш.Усманов, Ф.Бурнаш, композиторлар С.Сәйдәшев, Ф.Яруллин, рәссам Б.Урманче, галим Ш.Мәрҗани кебек халкыбызның олы шәхесләре дә күренми бит.

Татар халкының, татар мәдәниятенең һәм әдәбиятының халыкара данын балкып туган даһи әсәрләр генә түгел, менә шушындый «вак-төякләр» дә ныгыта икәнен безгә — иҗат союзларына да, фәнни оешмаларга да, республикабызның директив органнарына да онытырга ярамый. Халык милли Ренессанс кичергәндә вак-төякләр булмый ул!

Хөрмәтле иптәшләр, каләмдәшләр!

Тагын берничә көннән «Казан утлары» журналының 800 нче номеры чыгып җитәчәк. Язучылар союзы оешканчы ук язучыларны туплап торган, сталинщина вакытында барлык күренекле авторларын кулга алып бетергәч тә, сугыш елларында авторлары фронтка киткәч тә өзелмәгән, халыкка таба баруын дәвам иттерергә көч тапкан «Казан утлары» журналы — барлык буын татар әдипләренең иҗат эстафетасы юлы ул. Бүген бу юлда без, ягъни шушы залда утыручылар, һәм безгә үзебезгә тигән эстафетаны матур итеп алып барырга язсын!

Безнең халыкка әйтәсе сүзебез соңгармасын, вакытында әйтелсен иде. Бу татар әдәбиятын халкыбыз күңеленә тагы да якынайту юнәлешендә тагын бер хәлиткеч адым булыр иде.

*17–19 май, 1989*

# Каләмдәшләр һәм
# остазлар иҗаты
турында

## Р.Фәйзуллинның «Аҗаган»ы турында

1

Китап — кеше кебек ул. Аның белән сөйләшеп, бәхәсләшеп була, аңардан киңәш сорап була. Әгәр дә китап син уйлаганча гына фикер йөртсә, син инде күптән белгән нәрсәләргә генә ишарә ясаса, дөньяны син тойганча гына тотып сиздерсә, әңгәмәне артык дәвам итеп булмый — үз-үзең белән сөйләшү ич бу!

Шуның өчен дә, китапны кулыңа алгач, «менә-менә үзеңнең дә тел очыңнан тәгәрәп төшәргә торган сүзне көтмисең, ә үзең белмәгән-күрмәгән фикерләрнең, образларның «тәгәрәп төшүенә» өмет итәсең.

Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты Равил Фәйзуллинның «Аҗаган» дигән шигырьләр җыентыгын чыгарды. Р.Фәйзуллинның күп шигырьләре инде, газета-журналларда басылып чыгып, шактый гына шау-шу куптарып өлгергәннәр иде. Кайберәүләр авторны формализмда гаепләделәр, икенче берәүләр үтереп мактадылар. Минемчә, тегеләре дә, болары да үз фикерләрен яшь авторның бер-ике әсәренә карап кына әйттеләр, чөнки Фәйзуллинның чын йөзен күпмедер ачкан тулы җыентыгы юк иде әле. Ул хәзер бар, бер-ике ел элек язылган шигырьләрдән торса да, ул укучыларга үз фикерләрен төгәлрәк итеп әйтергә мөмкинчелек бирә.

Ләкин минем максатым ул түгел. Мин, бит арты бит ача-ача, «Аҗаган»ны укыйм, аның белән танышырга теләп сөйләшәм генә.

> Болай тезсәң, йөз дустың арта,
> болай тезсәң, йөз дошманың!
>
> *«Хәрефләр»*

Дөрес, дөрес! Дөньяда җыр да, шигырь дә — көчле корал. Алар белән аеруча сак эш итәргә кирәк. Аларны кирәкмәгән урында кулланып, дусыңны — дошман, дошманны дус итәргә мөмкин ич. Хәрефләр, сез «Аҗаган»га шигырьләр булып тезелеп, минем, минем яшьтәшләремнең, эне-сеңелләремнең, абый-апаларның дусты була алырсызмы икән?

> Сез балталар уйлап таптыгыз. Башларыгыз
> бүкәннәрдән тәгәрәде,
> үзегез ишкән бауларда маятник күк
> җилдә чайкалдыгыз,
> үзегез койган ядрәләрне тәнегездән эскәкләп
> чүпләдегез,
> үзегез җыйган танклар кулларыгызны
> сытып узды,
> үзегез очырткан корыч кошлар өсләрегезгә
> бомба койды...
>
> *«Гадиләргә гимн»*

Сез, хәрефләр, шушы хакыйкать булып тезелеп, шушы хакыйкать булып яңгырап, кешеләрне рәнҗетмисезме икән?

> Тик шулай да
> Җиргә җыр җитешми әле.
> Тормыш әле җырга тиенмәгән, —

дип, Җирне ачуландырмыйсызмы, хәрефләр?

Ачулансыннар кешеләр дә, Җир дә. Кайбер вакытта ачулану елмаю кебек үк мөһим нәрсә. Әле

> Шулай, энем,
> иртәгәсе иртән,
> бүгенгесе кыйммәт дөньяның...
>
> *«Тукталышта»*

дип, «акыл» өйрәтүчеләр дә, «ике куллап, кысып-кысып, кысып-кысып сыгасы» сагышлар да, ядрәне көчле дию че кешеләр дә, исемен әйткәч үк йөрәк җыерыла торган Бухенвальдлар да, «бер кабахәт иренена ялгыш

кунган» яхшы сүзләрнең аһ-зарлары да бар бу дөньяда.

Ләкин дөнья, бәхеткә каршы, алардан гына тормый: елмаюына төреп конфетлар таратучы стюардесса да, карлыгач очуына карап, бар нәрсәләрен оныткан кешеләр дә, кер чайкаучы кызлар да, күзләренә болытлар, тургайлар, чәчәкләрне сыйдырган сылулар да, «Котсыз суык көнне бүлмәгә яз китерүче» иркәләр дә, яхшылык кына теләп алдалаучы хыяллар да бар бу дөньяда. Шулар безне нәфрәт йомгагы гына түгел, мәхәббәт тулы мәһабәт йөрәкле Кешеләр итәләр. Һәм без, Җир вәкиле буларак, гуманистлар буларак, Кояшка мөрәҗәгать итәбез:

Сөйлә, Кояш!
Бүтән илләрдә
минем кебек егерме яшьлекләр
ни уйлыйлар?
Кырыкка җиткәч нишләмәкчеләр?
Алтмышта?..
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сөйләп җибәр Җир турында,
илләр турында:
Анголада ни хәлләр бар?
Лаоста?
Кубада?

Сиңа мин күбрәк ышанам:
син барсына шаһит,
сиңа барсы мәгълүм.

*«Керфек очындагы Кояш»*

Без, киләчәгебез турында борчылып, кешелеккә мөрәҗәгать итәбез:

Ярылырмы бомба баш түбәмдә?
Белмим.
Әнием дә белми.
Кем белә?
Әйтегез сез аңа!
Әйтегез...

Һәм кешелек безгә җавап бирә:

Әгәр кемнәрдер дөньяга сыймый икән,
аларга каршы,
иңнәргә иңне терәп,
кирәк икән, пирамидалар
күчерелер!
Ак иңгә — кара сабыйны,
кара иңгә — сары сабыйны,
сары иңгә — ак сабыйны куеп,
тере нәфрәт стенасы коелыр!..

Шулай, шулай булыр, «Аҗаган». Бу турыда без озак сөйләшә алыр идек, күрәсең, әңгәмәдәшем була алдың. Шулай икән, нигә безгә мәхәббәт турында да сөйләшеп карамаска? Нигә үз итеп кенә сиңа бераз тәнкыйть сүзе әйтмәскә?

2

«Сиңа багышланган юллар». Кем һәм нинди икән син, берүзеңә җиде шигырь багышлаткан кыз? Нинди икән «Аҗаган», шул шигырьләрне багышлаучы лирик егетең?

Калгандыр нәрсә дә булса
күңелең юшкынында.
Ахыр чиктә шатлыгыңнан
елаган кич турында
хәтереңдәдер...

* * *

Калгандыр нәрсә дә булса,
шулаймы? Әйт, яшермә!
Юк булса, — горур китәрмен, —
күралмассың яшем дә!

*«Бераз үзгә, бераз бүтән...»*

Бик горур икән синең лирик героең, «Аҗаган». Шул вакытта ук бик нечкә күңелле дә икән. Бик кызык!

Котсыз суык көнне
шыксыз бүлмәмә син яз китердең.

Әгәр һәр кергән бүлмәгә яз ясасаң,
миңа күңелле булмас...
Тик шулай да бүлмәләргә,
кемнекенә генә булса да,
көз китермә, яме!

*«Иңемә кулларың орынгач»*

Шуның өстәвенә ул бик олы җанлы һәм киң күңелле дә икән. Кыскасы, менә дигән егет! Тик бераз гына шаянлык та булса!..

Ә кыз мәсьәләсен, кичер, аңламыйм — алар ничәү соң? Соравымны ахмаклык дип санама, циклның исеме аны чын мәгънәсендә җитди итә. Минемчә, җиде шигырь дүрт кызга багышланган. Дөрес, заманында алар синең лирик героең өчен «син» булганнар, ә хәзер, бергә җыелгач, аларга фәкать күплек санында гына дәшеп була. Ләкин андый принципиаль егеткә алай сибелеп-чәчелеп йөрү һич килешми. Бераз гына шаяртканга, «Аҗаган», гафу ит. Без — дуслар ич. Ләкин циклның исеме дөрес булмау һәм аны дөрес төземәү — факт.

Авыз иронияле итеп ачылган икән — шунысын да әйтергә кирәк: синдәге «Минем эти», «Җилфердәүче керләр җыры», «Самолетта. Биеклек — 8000 м» дигән шигырьләр белән сөйләшә алмадым — сөйләшеп булмады: алар ничектер ясалмарак килеп чыкканнар. Бәлки, аларны җыентыкка гомумән кертмәскә кирәк булгандыр?..

3

«Аҗаган»ны укыганда, мин шагыйрь очраттыммы, әллә философмы, әллә университет тәмамламаган студентнымы, әллә чәчләре көмешләнгән карт солдатнымы, әллә тормышның әчесен-баллысын татып өлгергән яшьтәшемнеме — белмим. Тик шунысы ачык: акыллы да, шул ук вакытта бәхәсле дә, күңелсез дә, шул ук вакытта кызык та фикерләр һәм образлар иясен очраттым, ә «Аҗаган» минем дустыма әверелде.

*22 август, 1966*

## «Юл өстендә кояш»

Бу дөнья гаҗәеп катлаулы. Кешенең бөеклеге белән янәшә үк аның түбән эшләре яши, социаль давыллар канатына бер үк вакытта изге хыяллары һәм шомланулары кунаклый, гасырыбызның олы идеяләре, бөек ачышлары белән күршедә кешенең тырнак очы кадәрле, шулай да бик көчле, шәхси мәшәкатьләре кыймылдый. Бу дөньяны аңлау, аны шагыйрьләрчә йөрәккә сыйдыру һәм күңелгә сеңдерү — гаять дәрәҗәдә авыр эш. Шуңа күрә дә Җир, Кеше, ил язмышын беркадәр тулырак сыйдырган һәм чагылдырган шигырь китаплары ел саен туып тормыйлар.

1966 елда Татарстан китап нәшрияты Шамил Мәхмүдовның «Юл өстендә кояш» дигән китабын бастырып чыгарды. Шунысын да әйтергә кирәк, бу китап рус телендә 1965 елда ук чыгып, «Дружба народов» журналында, «Советская Башкирия», «Комсомолец Татарии» һәм башка газеталарда матур-матур рецензияләр дә алып өлгерде. Шуның өчен дә туган телендә беренче мәртәбә дөнья күргән бу китап шигырь сөючеләргә көтелмәгән күчтәнәч булмады.

Шулай итеп, татар укучылары алдында яңа китап, яңа исем.

Әйе, бу китап шигырьләр җыентыгы гына түгел. Аны, романны арттан алга таба укып булмаган кебек, теләсә кайсы битеннән, шигыреннән башлап укып булмый — аңлашылмаучылык килеп чыга. Китапның һәр шигырен бүлек дип атап була, ләкин проза әсәрләрендәге, поэмалардагы бүлекләрдән ул мөстәкыйльлеге, төгәллеге белән аерылып тора. Шул ук вакытта һәр бүлек үзеннән алда килгәненең дәвамы, үзеннән соң килгәненең прелюдиясе.

Менә «Гади әйберләр» дигән беренче цикл.

Җирдә һәркем өчен бар:
яктылык, җылылык, эш һәм аш,
юллар өстендә — кояш, —

дип башланып китә ул.

Бу прелюдия циклның, китапның гына да башы түгел — ул авторның образлы фикерләү конструкциясе йомгагының җеп очы. Шушы юллар Җир, Кеше, табигать, тормыш турындагы образлы фәнгә алып керәләр.

Әйе, бу тормышның нигезендә, материя нигезендәге кебек үк, гадидән гади әйберләр ята. Аларның гадилеге, билгеле, чагыштырмача гына. Иң гади әйбер, мәсәлән, Җир, чөнки ул кешенең иң күптәнге танышы,

кеше аны бик яхшы белә һәм аңлый. «Җир» шигыренең цикл башында булуы да очраклы түгел, ул диалектикага бәйле. Кеше өчен Җир — беренчел нәрсә, чөнки кеше үзе дә, аның барлык шатлык-кайгылары да, өмет-хыяллары да, «бөтен гүзәл нәрсәләр дә башлана Җирдән».

Шул ук Җирдән кешенең иң изге эшләре башлана: ул үзенә оя кора, оясында гаилә булдыра, чөнки «ике яр яшәгән өйләр — иң гүзәл оя Җирдә», чөнки, «кеше кеше дә түгел ул, җирдә оя кормаса, үз оясын, җирен саклап, яуга каршы тормаса!» Чөнки аның өе —

...яңа танышларга, иске дусларга,
язын килгән кошларга,
ак хәбәргә, имин хатка,
хәтта җиде төн уртасында
килеп ишек каккан җиде ятка

ишекләре ачык өй, күңелгә җылы биреп торучы якты күзләре — тәрәзәләре булган өй. Кеше уяу булырга тиеш — ул бит белә: бу тормышның гади әйберләрен кайчакларда кара эшләр пычрата.

Кеше кылә ак дөньяга,
татый аналарның ак сөтен...

Һәм ул барлык кара нәрсәләрне ләгънәтли, аннары — барлык пакь әйберләрне имгәтүче кара эшләргә каршы көрәшкә күтәрелә. Кеше — йөрәге, табигате белән «түбәнлектән котылу, кояшка омтылу» ягында. Көрәш аны аңның югары баскычларына күтәрә.

Менә-менә биеккә,
әйләнәләр кешеләр
үзләре дә
бөеккә!

Һәм хәзер

тормышның
киң ачылган күз бәбәкләрендә
күренә шундый бөек булып
тик кешенең генә горур сыны!

Картларныкымы, яшьләрнекеме ул гүзәл сын, ул сын бөек, чөнки ул — тормышны матурлаучы, чөнки ул — яшәүне дәвам итүче, чөнки ул — җир язмышын хәл итүче көч!

Менә «Гади әйберләр» дигән циклның логик төзелеше. Китапның калган биш циклы да нәкъ шулай төз логикага корылган һәм һәр цикл берсе берсеннән үсеп чыга.

Китапның, циклларның мондый төзелеше үзенә бертөрле сурәтләү чарасына әверелә һәм бу чараның сүз, рифма, ритм, аллитерация һәм башка әдәби чаралар кебек үк мөһим, тормышчан икәнлеге күренеп тора. Бу Шамил Мәхмүдовның китабын башка шигырь җыентыкларыннан аермалы итә. Шулай итеп, беренче цикл дөньяның, аны тәшкил иткән гади әйберләрнең, кешенең гомуми контурларын, бәйләнешләрен, фәлсәфи халәтләрен күрсәтә. «Гади әйберләр»нең дәвамы булып «Йөрәк хәтере» дигән цикл үсеп чыга.

Бу цикл инде дөньяның, яшәешнең трагизмын конкрет сурәтләр аша бирә. Ул — сугыш турындагы сюжетсыз поэма.

Җиргә
яшәр өчен килгәннәр
үлем эзләми җирдә... —

дип башлана да, ул бер-бер артлы авыр, куркыныч сугыш картиналарын күз алдына китереп бастыра.

Менә:

өскә төшәргә тора
тимер баскыч өзеге;
агы купкан стена
чеп-чи ит төсле,
күренеп тора кызарып,
канлы үзәге...

Менә:

Аунап ята трамвайлар —
туктый алмый,
әйләнә дә әйләнә тәгәрмәчләре...
Уйлый бугай алар:
«йөгерәбез, дип, һаман!

*(«Сугышның ике сурәте»)*

Менә егерме ел инде исән калган улын, ялгышып, үлгән улы исеме белән атап йөргән ана сурәте; дога кылган анага охшаган җимерек стена. Ул:

Гүя,
Хәлсез кирпеч кулларын,

куеп күкрәк өстенә,
кайгыдан башын иеп,
пышылдый да пышылдый —
дога укый ул,
дога укый үлгәннәргә:
кешеләргә,
агачларга,
үләннәргә...

Шулай итеп, безнең күз алдыбызга сугышның коточкыч сурәтләре җанлы булып килеп баса. Үле стенаның ләгънәтен укыгач, бөек табигатьнең җан тавышын ишеткән кебек буласың. Табигать тынычлык яклы, чөнки аның гүзәллеген бары тынычлык кына саклый ала, тынычлык кына яклый ала.

Алтын тавыннан да
кыйммәтрәк
тынычлыкның хәтта бөртеге.
Еллар буе төзгән, күтәргәнне
юк итә сугышның бер көне.
Түгел, сугыш сөяр башлар,
идарә итсен дөнья белән
акыл ияләре һәм гашыйклар.

*«Тынычлыкның бөртеге»*

Бу шигырь кешенең генә өметен чагылдырган фикер булып түгел, ә табигатьнең катгый боерыгы булып яңгырый. Һәм бу шигырьдән соң килгән «Җәйге көннәр» дигән цикл турыдан-туры табигать боерыгына буйсына. Моның шулай булуында Ш.Мәхмүдов тудырган лирик геройның да өлеше зур. Чөнки ул лирик герой гади кеше булып кына түгел, ә табигатьнең акыллы, телле, фикерле әгъзасы булып сөйләшә.

Бу циклдагы мәдхияләрне бер-бер артлы укып чыккач, табигатьнең «Менә мин нинди бит! Ә сез, кешеләр, кайчакта...» дигәнен ишетәсең һәм кабат «Йөрәк хәтере» циклы күз алдына килеп баса. Аннары «идарә итсен дөнья белән акыл ияләре һәм гашыйклар» дип, табигатьнең теләктәшенә әвереләсең, күңелеңдә олы гуманизм туа.

Автор яшәеш фәлсәфәсен өйрәнүдә укучыны һаман тирәнгәрәк, мавыктыргычрак һәм катлаулырак дөньяга алып керә бара. Укып үткән һәр шигырь үзенең ассоциатив җебен укучының миенә суза. Ул җепләрдән бер үк вакытта гади һәм катлаулы чигеш барлыкка килә. (Билгеле, бу һәр укучыда да дигән сүз түгел. Чөнки Мәхмүдов шигырьләрен йөгерек кабул итәр өчен укучының зәвык, интеллект, эрудиция ягыннан шактый әзерлекле булуы кирәк. Гади укучының бу китаптагы шигырьләрне бер-берсенә бәйләнешсез генә дә кабул итүе мөмкин. Ул очракта да Ш.Мәхмүдовның шигырьләре үз кыйммәтләрен югалтмыйлар. Бусы исә аның ике төр укучыбызга да азык бирерлек итеп яза алуын күрсәтә.

«Җәйге көннәр» циклы кешедә, аның нинди генә катлаулы, кыен, куркыныч вакыйгалар кичерүенә карамастан, гүзәл сыйфатларның мәңгелек булуы турында сөйли. Кеше холкы, асылы белән беркайчан да төшенкелеккә бирелми. Ул — мәңгелек якты өмет иясе, мәңгелек оптимист, чөнки

Кешеләрнең күңеле —
шул ук туфрак.
Шул туфракта
яра яфрак
яхшылык, гаделлек үсентеләре...

Чөнки ул белә:

Килү
китүдән күбрәк һәрвакыт:
көннән-көн
арта җирдә байлык, акыл,

чөнки ул белә:

кешенең барысы алда —
җиңәсе яулары бар — җиңмәгәннәр,
менәсе таулары бар — менмәгәннәр,
алда әле яулыйсы кыялары...

Юк, алда саналган хакыйкатьне белү генә кешене бөек оптимист итә алмый. Эш бу циклның тулаем фәлсәфәсендә. Аны укып чыккач, табигатьнең гомуми халәте аңга кереп урнаша. Табигатьнең йөрәк түрендәге теләге — тынычлык икән (хәрәкәтсезлек түгел!), ул теләкне эшкә ашыра алучы бердәнбер көч — кеше икән. Кеше өчен бары кеше генә җаваплы. Кеше аңына үзеннән-үзе менә шушы хакыйкать сеңә һәм аны бөек оптимист итә.

Үзебез дә сизмәстән, без «Кешеләр күңеле» дигән циклның берничә шигырен укып куйганбыз икән, һәм алар (бу китап өчен гадәти хәл) «Җәйге көннәр» дигән циклны кабат искә төшергәннәр.

«Кешеләр күңеле» дигән цикл беренче карашка ук «Гади әйберләр» циклын искә төшерә.

Беренче «Бөтен гүзәл нәрсәләр башлана җирдән» дип башласа, бу циклның иң беренче юллары — «Кешеләрнең күңеле — шул ук туфрак». «Барысы алда» шигыре — «Оя»ны, «Төзү дәрте» «Биеклек»не хәтерләтә.

Ләкин Ш.Мәхмүдов үзен-үзе кабатламый. Ул «Кешеләр күңеле» циклында кешегә тагын да якынрак килә, аның табигатьтәге ролен тагын да тирәнрәк күрсәтә.

Кешеләрнең күңеле —
яхшылык яши торган урын, —

дигән юлларны укыгач, кеше белән табигать арасында тигезлек билгесе барлыкка килә. Кеше — барлык сыйфатлары, мөмкинчелекләре, көче белән үзе бер табигать! Табигатьтә кеше һәм башка җан ияләре яшәгән кебек, кешедә яхшылык, яманлык, өмет, бәхет, кайгы яши. Табигать үлемсез әйберләр тудырган кебек, кеше дә үлемсезлек тудыра.

Кешене мөмкин үтерергә,
елмаюны —
мөмкин түгел...

Бу циклдан соң «Мәхәббәт» дигәне килә. Андагы шигырьләр, бер карашка, бик гадиләр. Ләкин алар алдагы циклларда башланган кайбер фикерләрне яңа баскычка күтәрәләр. Әгәр дә «0я» да «Ике яр яшәгән өйләр — иң гүзәл оя җирдә» диелсә, шагыйрь бу циклда

Икәү бергә бер кебек,
моңлы, матур җыр кебек...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бер алмадан ике ярты,
минсез син юк, синсез — мин, —

ди.

Без икәү бергә чакта,
үтәбез мәңгелек сызыгын,
безнең кайнар ирennәргә
үлемсезлек кагыла... —

ди.

Бу циклның төп фикере — кешенең үлемсезлегенә, аның фәкать ак эшләр өчен яралганына ышану.

Ә соңгы цикл («Бөек үзгәреш») — шагыйрьнең дөньяга гомуми карашы. Ул дөньяның бөек үзгәрешләр алдында торуын күрә һәм шул үзгәрешләргә мәдхия җырлый.

Бу циклда шагыйрьнең үз кредосы да бар. Ул циклны һәм китапны төгәлли торган шигырь дә.

Мин ялгышмыйм. Килде шундый мәгънәле чак,
без аңладык, кара кара ул, ак ул ак.
Бу шулай. Ләкин кырыс чынлык дөньясы
үзе турында үзе сөйләп кенә
буяуларны, сүзләрне дөрес,. чын ясый.

Шигъриятнең бар тагын бер кануны:

Һәрвакыт, бигрәк тә кара көннәрдә,
шагыйрь тиеш яктылыкка өндәргә.

Бу юлларны укыгач, китап кабат тулаем искә төшә. Тик бу юлы инде аның бүгенге тормышның иң актуаль проблемалары (сугыш, тынычлык, атом психозы, өмет...) белән нинди нык бәйләнештә булуы тагын да ачыграк күренә.

Бу китап — кешенең бүгенгесе турындагы, бигрәк тә аның киләчәге турындагы поэма. «Юл өстендә кояш»ның төзелеше турында сөйләгәндә, без бу төзелүнең үзенә бертөрле әдәби сурәтләү чарасы икәнен әйтеп үткән идек. Мондый әдәби чаралык чаткылары безнең шигъриятебездә очрыйлар иде инде (Х.Туфан, С.Хәким, Ә.Давыдов), ләкин ул цикл чикләреннән чыкмый иде. Ә Ш.Мәхмүдов аны, цикл эчендә генә калдырмыйча, китап күләмле әдәби чара итү дәрәҗәсенә ирешкән.

Әдәби образ тудыруда да Ш.Мәхмүдовның игътибарны җәлеп итә торган чаралары бар. Китапны укучылар «Юл өстендә кояш»та бер зур «җитешсезлек», «гөнаһ» күрерләр. Кайбер деталь, образ, фикерләрнең шигырьдән шигырьгә, циклдан циклга күчүен очратырлар, бәлки, моның өчен авторны тарлыкта, үзеннән үзе урлашуда гаепләрләр. Ләкин бу «гөнаһлар» Ш.Мәхмүдовның образ тудырудагы, аны тулы итүдәге казанышы, һәм бу очракта авторны гаепләү мөмкин түгел. Әгәр образның фәлсәфи халәтен тулырак, тирәнрәк ачарга теләп, автор үз образларын, детальләрен икенче, өченче, унынчы шигырендә үстерә икән — бу тарлык билгесе түгел. Шул ук ният белән дөнья күләмендә танылган шагыйрьләр хәтта башка шагыйрьләрнең деталь-образларыннан файдаланалар. Мәсәлән: «Авиаэтюды» дигән китапта гына да без В.Гете, Г.Лорка һәм башкаларның фикерләрен, детальләрен күрәбез. Ә «Апофеоз войны» дигән шигыре — Верещагин картинасының шигъри варианты. Ләкин алар барысы да Э.Межелайтис орбитасына буйсынганнар.

Кыскасы, Ш.Мәхмүдовның «үз-үзен кабатлавы» — образ тудыру чарасы, ул образны гомумиләштерү, тирәнәйтү, аны бу китап өчен бер итү чарасы. Мәсәлән: берничә цикл, шигырьгә сибелгән оя образы укыган саен күз алдында конкретлаша, тулылана, тирәнәя бара. Менә оя — кешене тугач ук каршы алучы нәни дөнья, менә ул имгәтелгән әйберләр арасында, менә ул ике яшь кешегә бәхет сәгатьләре бирә, анда кайгы, анда сугышны каргаучы мич, анда бердәнбер әни... Һәм ул тора-бара Җир — оя образына әверелә.

Бәлки, бу «кабатлану»лар Ш.Мәхмүдов иҗатының публицистик рухы белән дә аңлатылалардыр. «Юл өстендә кояш»ны укыганда, авторның укучы белән ничектер якыннан сөйләшкәне тоелып тора. Ә кайвакыт ул трибунага да менә. Шул публицистик рух һәм китапның алда әйтелгән төзелеше, бәлки, авторга кайбер фикер, детальләрне башкарак аспекттан чыгып әйтергә мәҗбүр итәдер. Бит әле шунысын да онытмаска кирәк: үз фикереңне аңлатканда, әңгәмәдәшеңне инде аңа таныш булган детальләр нигезендә ышандырырга тырышасың. Әгәр дә дөнья читендәге әйберләргә ишарә итсәң, фикер катлаулана, буталчыклана гына бара.

Ш.Мәхмүдов шигырьләренең тагын бер үзенчәлекле ягы бар. Ул —метафораларның бик сирәк кулланылуы. Шигырьләр шәрә, ләкин аларның күлмәксез булулары һич сизелми. Күпчелек сүзләр, үзләренең туры мәгънәсендә генә кулланылсалар да, алар артындагы мәгънәнең тулылыгын татыр өчен йә микроскоп, йә телескоп-күңел кирәк. Мәсәлән, «Яңгырый элек ишетелмәгән гүзәл сүзләр», «Шагыйрьгә башкача мөмкин дә түгел» дип башлана торган шигырьләрне тулаем аңлар өчен, телескоп-күңелнең объективын һәрхәлдә бер егерме еллык үткәнгә төбәп, андагы һәр детальне зурайтыбрак, ачыграк итеп күрергә кирәк.

Ш.Мәхмүдовның шигырьләре метафорасыз булса да, күз алдына гаҗәеп төсләр дөньясын, кайвакыт экияти, ә кайвакыт кырыс реалистик күренешләрне бик ачык китереп бастыралар. Ә сәбәп нидә?

Сәбәп — Ш.Мәхмүдов шигырьләренең укучылар аңында зур ассоциацияләр тудыруында. Алда ук әйтеп киткән идек: китапның уртасындагы, йә иң соңындагы шигырьләрне укыганда, безнең хәтеребезгә китапның моңа кадәр укылган образлары, фикерләре искә төшә. Шул ук вакытта яңа гына укып чыгылган шигырьнең фикерләре объектив дөнья хәлләре белән бәйләнешкә керәләр. Алар китапның образын тагы да тулыландыралар һәм үзләре дә, шигырь йогынтысы астында, башка яктан, яңарыбрак күренәләр. Ассоциация — Ш.Мәхмүдовның шигъриятен билгеләүче иң беренче чара. «Юл өстендә кояш»ның да, «Европа уртасыннан репортаж»ның да, «Прага дәфтәре»нең дә, «Солнце на дороге»ның да.

Ш.Мәхмүдовның шигырь төзелеше шигырь сөючеләр өчен дә, әдәбият белгечләре өчен дә, шагыйрьләр өчен дә игътибарга лаеклы күренеш. Ш.Мәхмүдов ирекле шигырьне соңгы елларда татар шигъриятенә беренче булып алып керүче генә түгел, бу форманы кабул итәрлек хәлгә китерүче шагыйрь дә.

Аның ирекле шигыре Көнбатыш шигъриятенең татар теле нигезендәге варианты да түгел. Ул күбрәк Назыйм Хикмәт шигъриятенә якынрак. Әгәр дә без шагыйрьнең аң-белеме, профессиясе, тормыш шартлары аның иҗатында да чагыла дигән фикергә каршы килмибез икән (моның шулай булуында гаҗәпләнерлек берни дә юк), чөнки Ш.Мәхмүдов ун ел дәвамында Н.Хикмәт белән якын элемтәдә булган кеше (татар һәм башкорт телләрендә чыккан Н.Хикмәт шигырьләренең тәрҗемәчесе — Ш.Мәхмүдов). Шуның өстәвенә ул Көнчыгыш телләре белгече (МГУның Көнчыгыш телләре бүлеген һәм аспирантурасын бетергән, М.Горький исемендәге әдәбият институтында укыткан). Монда шунысын да әйтергә кирәк: автор үзенең иң беренче һәм бердәнбер укытучылары итеп Н.Хикмәтне һәм татар халык җырларын саный. Билгеле, Уолт Уитменның, Гарсиа Лорканың, Пабло Неруданың, Рафаэль Альбертиның, Поль Элюарның да йогынтысы бардыр.

Ш.Мәхмүдовның соңгы елларда татар ирекле шигырен кабул итәрлек хәлгә җиткерүче дип әйткәнбез икән — дәлилләргә дә кирәктер.

Ирекле шигырь — хаостан торган канунсыз форма түгел. Ул без белгән, «шакмаклы» дип әйтик, шигырьдән, бәлки, нәзбереклерәк, катлаулырак, чөнки форма монда үзен-үзе онытырырга тиеш, приоритетны мәгънәгә, образга бирергә тиеш. Ә моңа ирешү өчен шигырьнең һәр юлы, һәр фикере укучыны ничектер сихерләргә тиеш. Сихерли торган образлар бирү — шигъриятнең иң катлаулы һәм мактаулы эше. Монда сүз форманың образ-фикер белән тәңгәлләшүе турында бара.

Ш.Мәхмүдовның һәр шигыре — үзенә бертөрле кабатланмаган форма. (Билгеле, шигырьләрнең охшаш яклары да бар. Мәсәлән: һәр шигырь диярлек афоризмнан башлана, аннан йә антитеза, йә тезисны киңәйтү, шигырьнең ахырында фикерне ачык калдыру һ.б. күренеп тора.)

Ш.Мәхмүдов бу формаларны күктән тартып төшерми. Ул безнең традицион формаларның элементларын башкача тезә һәм форманың нигезе булган ритмнарны яңарта. Мәсәлән: «Оя» шигыре. Аның нигезендә татар халык җырларыннан күчкән 8–7ле үлчәм. Ләкин ул үлчәм, ритмик буыны 8–7гә туры килгән башка буыннар белән аралаша: 7–7–8–7, 8–7–8–7, 8–7–4–7, 8–5–8–8, 7–8–8–7, 7–8–7, 8–7–5, 7–8–8–7–4–5.

Иҗек саннары шундый төрле булган юллар бик кытыршы яңгырарга тиешләр кебек, ләкин алар ни сәбәптәндер бик табигый, яңача яңгырыйлар, хәтта үзләренең «кытыршы» икәнлекләрен дә сиздермиләр.

Эш нәрсәдә соң? Ә эш барыбызга да билгеле булган ритмик буыннарда. Әгәр дә «Кара нәрсәләргә ләгънәтне» ритмик буыннарга бүлеп чыксак, без мондый күренешкә тап булыр идек: 4–4–6–6–4–3, 4–4–6–3, 2–4–4–6–3, 4–4–5–4–3–4–3–4–3... ягъни, нигездә, 4, 6, 3 иҗекле ритмик буыннарның башка буыннар белән аралашуын күрер идек. Бу ритмнары шигырьләрнең фикерләре тудырганнар, һәм алар үзләренә бер музыкальлек алып киләләр. Гомумән, Ш.Мәхмүдовның шигырьләре бик музыкальләр. Аларның төзелеше дә музыка әсәрләрен хәтерләтә: иң алдан прелюдия-афоризм, аннан 2, 3, 4 кисәк һәм тәмамлаучы өлеш килә. Музыка әсәрләрендә беренчел тема әсәрне үтәдән-үтә тишкән кебек, һәм үз тирәсендә башка темалар тудырган кебек, Ш.Мәхмүдовның шигырьләрендә беренчел ритмик буын әсәрнең буеннан-буена төрле вариацияләрдә үсеп бара.

Ритмик буыннар нигезендә синтагмалар ята, шигырь кирәкмәгән урында мәгънәгә зыян китереп бүлгәләнми. Ш.Мәхмүдовның шигырьләре — строфасыз шигырьләр, ләкин алар паузалар белән строфа кебегрәк өлешләргә бүленәләр. Бу өлешләрдә фикер башлана да, төгәлләнергә дә өлгерә. Ә калган өлешләр шушы фикергә логик ассоциация белән бәйләнәләр. Әгәр җөмләләрдәге синтагмаларны күз алдына китерсәк, нәкъ шундый күренешкә тап булабыз: фикернең төгәлләнгән буыннары да бер-берсе белән нәкъ шулай бәйләнәләр һәм тагы да зуррак, камилрәк фикер хасил итәләр. Бу параллельдән соң Ш.Мәхмүдов шигырьләренең эчке төзелешен (әгәр дә шулай атап булса) синтагматик төзелеш дип атарга мөмкиндер. Шигырьнең бер зур паузадан алып икенче зур паузага кадәр өлеше — «синтагма». Шул «синтагма»лар, бер-берсе белән логик бәйләнешкә кереп, бер зур образ-фикерне «җөмләгә» (шигырьгә) әйләндерәләр.

Кайбер укучылар рифмасыз шигырь күрсәләр, «Ах, бу иркле шигырь икән!» диләр. Ләкин иркле шигырь рифмалы да була ала, тик анда рифма, фәкать иң кирәкле урында гына кулланыла. Ш.Мәхмүдовның кайбер шигырьләрендә («Альшан зиратында», «Әниемнең йөзе» һ.б.) рифма традицион шигырьдәгегә караганда күбрәк тә. Алар юлның башында да, уртасында да, ахырында да.

Йоклагыз,
җиңел булсын бу туфрак, бу авыр ташлар,
җиңел булсын, ватандашлар, якташлар,
йокыгыз...
Сирәк киләсез дип, тотмагыз безгә үпкә,
ерак бит, булмый бит килеп ешрак һәм күпкә...

Күрәсез, һәрбер сүз диярлек рифмалашкан. Ш.Мәхмүдов шигырьләрендә рифманың төрләре бик бай: яңгырашка корылган рифмалар (барыбер-бәрабәр, агачы — ап-ачык, төзү дәрте — үзгәртү), кончыгыш шигърияте нә хас ике, өч сүздән гыйбарәт рифмалар да, тәңгәл рифмалар да...

Тәңгәл (бер-ике хәрефе белән генә аерылган рифма) рифмаларны Ш.Мәхмүдов рифмалашкан сүзләргә зур мәгънә бирмәгәндә ешрак куллана. Үзе белән зур мәгънә алып килгән сүзне юлның ахырында ул йә бөтенләй рифмалаштырмый, йә аңарга яңгыраш нигезендә корылган рифмалар таба. Һәм бу рифма укучының игътибарын җәлеп итәрлек була. Ә мәгънәле сүз рифмалашмаганда, ул сүзгә кадәр укыла торганнары рифмалашалар һәм мәгънә алып килүче сүзне йөз кара карга арасында бер ак карга кебек итәләр.

Кыскасы, шигырьләр техника ягыннан камилләр, үзенчәлекleләр. Күрәсең, Ш.Мәхмүдов — шигырь техникасы белән заманча коралланган зур культуралы, киң диапазонлы шагыйрь.

*1967*

# На «третьих» чувствах

1

В свою новую книгу стихов[1], вышедшую на русском языке, известный татарский поэт Сибгат Хаким включил в основном произведения последних лет.

Сам выбор стихов в какой-то степени характеризует творческую амплитуду Сибгата Хакима. В книге есть и песни (С.Хаким — автор многочисленных популярных песен), и циклы: «Гнездо», «Поднимайтесь, поэты!», в последний из них отдельной главой включен великолепный в своей публицистичности цикл «Из немецкого дневника» — плод поездки поэта по следам Мусы Джалиля. Этот цикл — неожиданность даже для татарского читателя, ибо он еще не успел войти в книги поэта, изданные на татарском языке. Читатель здесь встретит пышущие восточным колоритом философские «Раздумья» и, читая поэму «Через кручи», невольно станет спутником поэта, шагающего по грандиозному нефтепроводу «Дружба». Погрузившись в теплую грусть, читатель прочитает стихи «В мире убавилось света», посвященные памяти матери. Уход из жизни самого дорогого человека всегда оставляет неизгладимый след. В памяти читателя всплывут стихи Семена Кирсанова, посвященные памяти жены, цикл польского поэта Владислава Броневского «Анка», стихи Мустая Карима, напечатанные в восьмом номере «Юности», и поэт Сибгат Хаким займет свое неповторимое место в сердце читателя...

Циклы этой книги, особенно поэма «Через кручи», — темы самостоятельных больших разговоров. Имея в виду то, что о них местной прессе говорилось достаточно много, я специально не буду останавливаться на них. Только скажу, что они в совокупности рассказывают о жизни современного советского человека, ясно знающего свои цели в жизни и пути их достижения. Они раскрывают мир чувств и переживаний этого человека.

Не касаясь отдельных произведений комментариями типа «вот что этим хотел сказать поэт», я хочу начертить несколько штрихов к творческому портрету Сибгата Хакима, поэта очень тонкого и сложного в своей простоте.

Когда Сибгат Хаким думает, он смотрит на землю, как на фотопортрете, открывающем книгу «Через кручи». Когда говорит или читает стихи, он смотрит в небо — как будто ищет подходящий гвоздь, чтобы повесить на всемирный обзор свои чувства и мысли, рожденные увиденным на земле.

Читая произведения Сибгата Хакима, я всё больше убеждаюсь в том, что эта чисто бытовая привычка

превратилась в нем в поэтический прием.

Снова — пламя и плаха,
И зловещи приметы...
Из кровавого праха
Поднимайтесь, поэты!

Песней мир оглашая,
А не стонами с дыбы,
Весь — от края до края
Шар земной обойти бы.

Вы нужны нашим битвам,
И легендам, и были.
Род людской говорит вам:
Поднимайтесь, Джалили!

*(«Поднимайтесь, поэты!»)*

Эти строчки не могут родиться беспричинно и причиной им — творящееся на Земле. Вновь, с большей ожесточенностью вспыхнувшие репрессии прогрессивных людей, государственных деятелей и деятелей искусства в капиталистическом мире, дискриминация угнетенных народов, разжигание неофашизма и неонацизма, пособничество этому буржуазных правительств родили в поэте ненависть и чувство ответственности за судьбы народов и Земли. В стихотворении он дает кульминацию своих чувств, превратившихся в мысль-призыв «Поднимайтесь, поэты!».

Поэт для Сибгата Хакима — это символ мужества («Поднимайтесь, Алиши[1]! Поднимайтесь, Курмаши[2]! Поднимайтесь, Джалили!»), патриотизма и естественных идеалов природы и Человека, которые сродни с коммунистическими идеалами. А призыв поэта звучит уже не только как призыв к братьям по перу, он приобретает социально-философское звучание. Вот таким образом индивидуальные качества Сибгата Хакима, превращаясь в методологический прием, ложатся в основу произведений.

Это, разумеется, только один из множества поэтических приемов, присущих творческому облику Сибгата Хакима, но он, на мой взгляд, доминирует в его творчестве последних лет. Весь цикл «Из немецкого дневника» написан именно в этом ключе.

Вот поэт в старом Веймаре, в доме Гете, где «комнат одних тридцать три». Он в доме, где гений немецкого народа превратился в великана мировой литературы. И

...Вдруг из Веймара, в мареве лет,
Я увидел в окошке Тукая
В той казанской гостинице — свет.

Шумный «Булгар» больному поэту
Самый жалкий отвел номерок...

Сын татарского народа Тукай дожил всего до 27 лет, но смог вырасти в великана своей тысячелетней литературы. От этого естественно пришедшего сравнения в душе Сибгата Хакима гордость за своего предшественника, за свою землю, способную несмотря ни на какие трудности рождать великих, талантливых.

Есть поэты, пишущие яркими, броскими мазками. Стихи, написанные в такой манере, естественно, в первую очередь притягивают к себе внимание, но зачастую так же быстро отпускают его. Стихи Сибгата Хакима я бы сравнил с дымчатыми импрессионистическими полотнами, на первый взгляд кажущимися плоскими, даже мутноватыми, и которые потом, после внимательного осмотра, начинают играть множеством изящных оттенков и полутонов и являть глубокие, чисто реалистические, но прозрачные образы. Такая поэзия имеет свою прелесть, свой вкус, от такой поэзии никогда не устает душа, а ум становится более тонким, если можно так сказать, чувственным умом. Поэтому Сибгат Хаким не стремится к афористичности своего слога, чем блещут иногда его горские собратья по перу. Его поэтическими находками становятся еле заметные, иногда даже трудно объяснимые психологические нюансы. В стихотворении «В моем переулке» поэт рассказывает о своем приезде в родную деревню.

Шестнадцать домов в переулке моем.
Всего лишь шестнадцать; он мал,
Но в годы военные круглым числом
Полвзвода людей потерял.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Считай, не считай — нет в живых никого...
Спокойные дуют ветра.
Нести чемодан земляка своего
Сбегается детвора.

Их дедов по личикам их узнаю:
Вот этот — Салих, тот — Рахим.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Вот этот Фарих, тот Аюп.

Все друзья
И сверстники.
Старый солдат,
Из всех уцелел в переулке лишь я
И словно бы в том виноват.

Это чувство какой-то вины поэта перед внуками своих погибших друзей и сверстников трудно причинно обусловливать, но оно очень близко душе человека и понятно без всяких комментариев.

Еще одной характерной чертой произведений Сибгата Хакима является отсутствие в них какого-то лирического героя, носителя дум и переживаний поэта. В стихах Сибгата Хакима есть только сам Хаким, и этому образу присуще только то, что присуще самому поэту. Читаешь стихотворение «За песнями своими я летел» — видишь гордого поэта, в стихотворении «Слово моего сердца» перед тобой встает Хаким (кстати «хаким» по-арабски — судья, арбитр), а из «Ходил я в церковь декабристов» смотрит на тебя поэт, который говорит:

Из мусульман, татарин я простой,
Но, веруя в людских сердец союз,
За Пушкина в острожной церкви той
Я вместе с декабристами молюсь.

Ни в одном стихотворении Сибгата Хакима не встретишь резко вырвавшегося крика, ибо и в жизни поэт никогда не кричит, не акцентирует даже мысль, требующую обязательного выделения. Не найти в его произведениях внешне бурлящих, клокочущих форм. Буйство стихии стиха не выбивается на поверхность, а бушует в тех психологических нюансах, о которых было сказано выше, потому что и сам Хаким в жизни не дает волю своим подкатившим к крайности чувствам.

Подобно ключу, что открыт пастухами,
И ты, моя песня, — без желобка.
Подобно ключу под камнями и мхами,
Ты скрытно струишься, чиста и робка, —

говорит поэт о своих стихах в «Раздумьях».

Говорят, что между крайними чувствами (например, радостью и грустью или любовью и ненавистью) бывает только одно «третье чувство», это — безразличие. Читая стихи Сибгата Хакима, можно убедиться в том, что «третьих» чувств очень много и они вовсе не безразличие. Их нужно только заметить, как, вглядевшись в импрессионистические картины, мы выхватываем из кажущейся расплывчатости и многоцветной гаммы естественную конфигурацию образов и вещей. Эти «третьи» чувства как-то неопределенны, но они в составной части психологии человека. Именно в их ключе многие произведения Сибгата Хакима, именно они действуют на чувства читателя.

Рувим Моран, хорошо понимающий татарскую поэзию (он переводил Кул Гали, Мухаммедьяра, Мавля Колыя, Кандалыя, Тукая, Дэрдменда, Джалиля, Энвера Давыдова и т.д.), близко знающий Сибгата Хакима (между ними уже давнишняя творческая дружба), в своих переводах сохранил не только образную систему поэта, его мысли, но и смог передать вот это слияние существа Сибгата Хакима — человека с его произведениями, смог увидеть и показать основу поэтического мироощущения тонкого поэта. Благодаря именно этому русский читатель, прочитав «Через кручи», познакомится не только с искренними и глубокими стихами, не только с интересным поэтом и человеком, он познакомится с основными чертами характера татарского народа, с его прошлым и настоящим, с его великими сынами и деяниями.

*17 сентября 1968*

# Призыв поэта

Читателю важно, что скажет ему книга и как скажет: ведь можно затеять разговор всякий — веселый, но пустой, горячий, но «пушкой по воробьям», тяжеловатый, быть может, редкий, но насущный... Чем подвижней темперамент книги, тем она живее, чем больше «видывал» ее лирический герой, тем она интереснее, чем больше в ней «крика души» самого народа, тем она ценнее.

Я несколько раз прочитал книгу лауреата Республиканской премии имени Габдуллы Тукая, известного татарского поэта Сибгата Хакима «Через кручи», перечитываю сейчас, получая каждый раз новое «первое впечатление». Скорее всего, я не читаю, а веду своеобразную беседу с ней.

Быть может, эту беседу возможно передать диалогом, что сделало бы ее более живой, но надеюсь, читатель и сам уже успел познакомиться с книгой «Через кручи». К тому же беседа с книгой — не только поддакивание или возражение ей, но и молчаливое обдумывание ее образов-мыслей, всевозможные экскурсии по тропинкам-ассоциациям книг Сибгата Хакима «Через кручи».

«Через кручи» открывается большим циклом «Поднимайтесь, поэты!», и это неслучайно.

Снова — пламя и плаха,

И зловещи приметы...
Из кровавого праха
Поднимайтесь, поэты!

Да, этот призыв неслучаен — народу и сегодня нужны слова сильных духом, нужны слова поэтов, своей жизнью и смертью доказавших верность народу, Родине, партии, чьи статьи были и «поддержкой и опорой», и разящим врагов мечом. А таких поэтов у татарского народа много. Каждый знает легендарного Мусу Джалиля и его соратников по борьбе в фашистском застенке поэтов Алиша, Курмаша, Рахима Саттара и других. Мало еще знают воина-патриота Фатыха Карима, всю войну провоевавшего на передовой и создавшего, быть может, не уступающие «Моабитской тетради» пламенные патриотические стихи, поэмы и повести. Именно думая о Фатыхе Кариме, Сибгат Хаким пишет:

От гибели народа спасены,
А в сердце скорбь о гибели поэта.

Гибель поэта — это большая утрата народа, ибо поэт — борец за справедливость, за счастье народа, поэт — часть самой Родины.

Но когда... Лучше еще раз прочитаем отрывок из стихотворения «Безмолвствует знавший...»:

В грядущее мчатся поэты,
Но кровь прерывает набег...
Дымящиеся пистолеты
Дантесы швырнули в наш век.

Фашисты их с лету ловили,
Творили неправедный суд.
Нет мира — ведь новых Джалилей
Застенки все новые ждут...

Это стихотворение имеет большую ассоциативную глубину, ибо оно — образный итог раздумий Сибгата Хакима о судьбе Пушкина, Лермонтова, Тукая и многих прогрессивных зарубежных деятелей литературы и искусства сегодняшних дней, или уже томящихся в тюрьмах, или находящихся в преддверии этой же участи. Эту трудную, но славную судьбу поэта Сибгат Хаким обобщает в образе своего современника Мусы Джалиля.

В этом цикле есть стихотворение «Каждому — свое», написанное поэтом под впечатлением поездки по следам Мусы Джалиля. Вот он (с ним вместе и мы) в Бухенвальде, на воротах которого надпись: «Каждому — свое».

У печей как будто не остыла
Огненная пасть.
Воду бы плеснуть — да страх лишает силы:
Словно можешь сам туда попасть.
И проходят, даже не заплакав,
Помрачнев едва.
Соскоблили уже с беленых стен бараков
Смертников последние слова.

Поэта возмущает, если можно так сказать, каменно-сердечная беспечность, равнодушие некоторых туристов и особенно поведение «хозяев» бараков смерти, потихонечку, помаленьку смывающих со стен страшный документ истории.

В этом стихотворении Сибгат Хаким проводит очень тонкую логическую мысль: потихоньку стирают вопиющие следы преступлений, и бараки смерти все больше теряют свой ужасающий вид, у посетителей начинают меняться сначала впечатления, а потом и суждения о преступлениях фашизма, ибо лучше один раз увидеть, чем сто раз услышать, а посетитель увидит просто обыкновенные бараки, и все. Вот что возмущает Сибгата Хакима! Вот что возмущает весь советский народ и все прогрессивное человечество! И звучит:

Вы нужны нашим битвам,
И легендам, и были.
Род людской говорит вам:
«Поднимайтесь, Джалили!»

Цикл «Гнездо» включает в себя стихи о родной стороне поэта. Гнездо человека — это не только земля, родившая человека, вскормившая, давшая ему кров. Гнездо — это такое место, где живут люди, воспитавшие человека, сделавшие его Человеком, связавшие его со своим прошлым и указавшие путь к будущему. Гнездо — это дух народа. И чем больше помогает это гнездо другим гнездам, тем ценнее и милее оно человеку.

Гнездо Сибгата Хакима очень своеобразно. Вот Первая гора — холм, где когда-то жил студент Владимир Ульянов; вот стена кремля, у которой белочехи расстреляли соратника Ленина Мулланура Вахитова.

На заре розовеет моя Казань,
Только та стена белеет.

В заревую рань
Перед нею стань,
И былым на тебя повеет...

Вот косогор, с которого навстречу тебе спускаются ромашки. Где-то за этим косогором деревня, где

Жил-был солдат. Прогнал Наполеона.
Домой вернулся. Починил забор...

А на окраине того села — одинокая дикая яблонька, чем-то напоминающая гордую татарку, которую зовут в деревню, но «ей нипочем мольба»; а вот переулок поэта, где шестнадцать домов, но который потерял в военные годы полвзвода. В этом переулке много детворы, внуков погибших друзей поэта.

И в этом гнезде звучит голос поэта, нет, не только поэта, а всего народа:

Всю молодость я отдал ей сполна,
У многих жизнь она поотнимала...
Зачем меня преследует война,
Иль даже этого ей мало, мало?

Давно мне дорога мечта одна:
Пожить с полвека без войны кровавой.
Зачем меня преследует война,
Иль на покой я не имею права?

После этих слов вновь в памяти всплывает основной призыв первого цикла: «Поднимайтесь, поэты!», но он уже звучит более обобщенно — как призыв сегодняшнего дня, вобравшего все тревоги Земли и Мира. И уже чувствуешь, что понятие «гнездо» стало глубже, оно превратилось в понятие «Родина, народ и счастье», уже ощущаешь, что между двумя циклами книги перекинулся логический мост, связавший книгу «Через кручи» в единое целое.

Обобщающую силу этому призыву дало еще и то, что развитие мысли поэта до этого призыва шло не только через одноединственное восприятие самого поэта, а через сердца строителей, воинов, философов, народного заседателя, депутата Горсовета и т.д., то есть через сердце лирического героя, обобщившего в себе мысли, думы, настроение и характерные черты всего советского народа.

Книге «Через кручи» дала название одноименная поэма, которую можно было бы включить в цикл «Гнездо», ибо она о гордости поэта — о нефти и нефтяниках Татарстана, прокладывающих нефтепровод «Дружба». Эта поэма очень емкая, насыщенная, и о ней невозможно что-либо сказать в этой маленькой заметке, ибо эта поэма достойна специального большого разговора.

В заключение хочется отметить и то, что благодаря добросовестным переводам Рувима Морана, хорошо понимающего татарскую поэзию, хорошо знающего творчество Сибгата Хакима, русский читатель имеет возможность познакомиться не только с интересным поэтом, но с основными чертами характера татарского народа, с присущими только ему радостями и раздумьями.

*1969*

# О «Мраморе» Р.Файзуллина

По радио передают последние известия...

На моем столе лежит книга стихов Равиля Файзуллина «Мәрмәр» — «Мрамор». Я ее только что прочитал еще раз и поймал себя на том, что мысленно, про себя, начал разговаривать с ее автором. Она вызвала в моем сердце, в моей памяти множество интересных вопросов, на которые я ищу ответы.

Кто я?
Что со мной?
Что буду делать?
Чем и кому я могу помочь?
Подсчитайте всех, кто об этом
Способен задуматься в темную ночь.
Сколько — проклинающих мир?
По скольку на душу приходится
взрывов,
    выстрелов,
        радости,
            ненависти,
                квартир,
                    хлеба
                        и тишины?..
Ты слышишь?
Планете герои требуются!
Ты слышишь?
Народам борцы нужны!

Мать Земля! Ау, отзовись —
много нас для тебя или мало?
Куда мы движемся — вверх?
Вниз?
Что впереди — счастливая жизнь
или кровавая мгла финала?

Чувашская пословица гласит: «Ыра курше хуранташран хакларак!» Да, действительно, добрый сосед дороже родни. Но когда добрыми соседями являются близкие родственники, как татарский, чувашский и башкирский народы, такому соседству цены нет! Веками рядом стояли наши дома и села. Веками наши народы знали языки друг друга. И нет никакой случайности в том, что приблизительно с одинаковой частотностью рождались на одних и тех же землях великие сыны наших народов. И нет никакой исторической случайности в том, что на земле нынешнего Татарстана, в селе Кошки-Новотимбаево Тетюшского района, 150 лет тому назад родился величайший сын чувашского народа, патриарх чувашской письменности и педагогической мысли, энциклопедически образованный просветитель Иван Яковлевич Яковлев. Его юбилей — это праздник и нашей республики. Примите, дорогие друзья, сердечные поздравления по этому случаю Президента Республики Татарстан Минтимера Шаймиева, председателя Государственного Совета Василия Лихачева и премьер-министра Фарида Мухаметшина всему многонациональному народу Республики Чуваш-ень!

С нашей стороны было бы справедливо признание в том, что об Иване Яковлевиче Яковлеве вы знаете намного больше и глубже, чем мы, гости, хотя и в архивах Казани хранится более одного миллиона страниц документов чувашского народа, многие из которых посвящены жизни Ивана Яковлевича. И это естественно, ибо плодами его могучей деятельности в первую очередь пользуется чувашский народ. И поэтому у нас нет стремления удивить вас, дорогие чебоксарцы, сенсационными новостями из жизни и деятельности Ивана Яковлевича. И это, наверное, уже невозможно, так как о своем великом сыне чувашскому народу все основное хорошо известно.

В годы, когда родился Иван Яковлев, на свете не было республики Чуваш-ень, равно как не было и Татарстана, и Башкортостана, и других республик. Родиной ему был, как это ни странно звучит, весь чувашский народ, рассыпанный по российским губерниям. И Иван Яковлевич честно и самоотверженно служил своей родине-народу. И мы, татарстанцы, горды тем, что именно наша древняя земля приняла «унан кавапа юнне» — каплю крови из его пупка, а потом стала колыбелью, а затем в лице Казанского университета — его академией, началом славного пути великого служения просвещению своего народа.

Достойны всяческого уважения люди, посадившие дерево или сад, построившие дом, воспитавшие детей. Но таких миллионы! Достоин восхваления перекинувший через реку мост, протянувший дорогу, построивший храм и школу. Но и таких тысячи. И только единицам судьба дает возможность подарить своему народу алфавит, письменность. И таким историческим счастливцем оказался неугомонный труженик и истинный патриот Иван Яковлевич Яковлев, одаривший чувашский народ новой буквой. А буква — это начало слова, а слово — самое великое, чем обладает человек, ибо в слове соединяются прошлое с будущим, недра с космосом, корни с цветком, простое с гениальным. А слова самого Ивана Яковлевича Яковлева — педагога, ученого, просветителя, литератора — это символ мудрости, трудолюбия, красоты помыслов и патриотизма чувашского народа. И этот символ с каждым годом, с каждым десятилетием и, дай Бог, с каждым веком будет светить все ярче и ярче и станет немеркнущей звездой.

*25 апреля, 1998*
*Чебоксары*

# Дәрдмәнд

Дәрдмәнд (Закир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев) (1859—1921) үзе исән чагында, бу эш өчен чикләнмәгән мөмкинлекләре булса да, бер генә китабын да бастырмаган. XIX йөз ахыры, XX йөз башында Россиянең иң бай кешеләренең һәм иң эре нәширләренең берсе булган ул. Бер журналистның, кызыксынып, нигә шулай соң яза, матбугатта соң басыла башладыгыз дигән сорауларына ул, рухи ирекккә күтәрелер өчен матди ирекккә ирешүгә байтак вакыт сарыф ителде, дип җавап биргән.

Дәрдмәнд үзенең бертуган абыйсы белән бергә Уралдагы берничә дистә алтын приискасы хуҗасы булган. Сүз уңаеннан шуны да әйтик: татар шигъриятенең тагын бер классигы Мәҗит Гафури берникадәр вакыт бертуган Рәмиевләр алтын приискаларының берсендә алтын юучы булып эшләгән һәм бу турыда мәгълүм повестьта язып калдырган. Әлеге приискалар зур табыш китергән; табышның бер өлешен Рәмиевләр уку йортлары, мәчетләр тотуга һәм башка хәйрия максатларына биргәннәр. Шул елларда татар дөньясында иң абруйлылардан саналган «Вакыт» газеты һәм «Шура» журналының оештыручылары булып, аларны нәшер итүне дә үз өсләренә алганнар. Нәкъ менә шул басмаларда башта сирәк-мирәк кенә, алга таба даими рәвештә «Дәрдмәнд» дип имзаланган шигырьләр күренә башлый. Берничә ел дәвамында редакцияләр дә, автор үзе дә псевдонимның серен ачмыйча, яшереп килгәннәр. Ни газет укучылар, ни әдәби җәмәгатьчелек «сагышлы» дигән мәгънәне аңлатучы бу псевдоним белән Россиянең иң имин язмышлы кешеләренең берсе язуын чамаламаганнар.

Дәрдмәнд, мөгаен, шул рәвешле укучыларның, язучылар даирәсенең һәм киң җәмәгатьчелекнең үз шигырьләренә мөнәсәбәтләрен, карашларын белергә, җентекләп өйрәнергә ниятләгәндер. Ул, бары тик шигырьләренең укучылар тарафыннан кабул ителүен, башка авторлар әсәрләрендә үз шигырьләреннән өзекләр

китерелүен күргәч кенә, псевдонимының серен ача.

Ә бу еллар беренче рус революциясе еллары иде. Җәмгыятьттә сәяси мавыгулар кайнаган чак. Алар шигъриятькә дә — рус, татар һәм Россиянең башка халыклары шигъриятенә дә үтеп керде. Публицистикалык ул еллар шигъриятенең кан тибешенә, хәрәкәттә тотучы көчләрнең берсенә әйләнә, һәм менә шул җирлектә Дәрдмәнд шигыре сәяси тормыш ваклыкларыннан өстенлеге, үзенең фәлсәфи сабырлыгы, әйтеп бетермәү серлелеге белән игътибарны үзенә җәлеп иттә. Нәрсә бу? Чынбарлыктан аерылумы? Әллә гасырлар очрашкан чиктә төрле яклап кайнап торган вакыйгалардан авторның үзчикләнүеме яисә, асылда дөньяны үзгәртерлек җитди берни дә булмаячак дигән какшамас ышанычы идеме? Һич юк. Шагыйрь боларның барысын да үзенең нечкә хисләргә бай йөрәге аша кичергән, әмма, сокланусларга төрмичә, бизәмичә, шактый тирән тамыр җибәргән шикләнүләр белән; такмаклы публицистикага салмыйча, бөтен халык тормышындагы кискен үзгәрешләр чорында җан һәм кеше язмышы турында шигъри уйланулар белән.

Кайбер тәнкыйтьчеләр, Дәрдмәнд бу елларда аптырап, каушап калган, дип язалар. Үз фикерләрен раслау өчен аның «Шаулый диңгез... Җил өрәдер...» дигән шигырен мисалга китерәләр. Бу шигырьнең соңгы юлларында «Кайсы юллар, Нинди упкын Тарта безне, җан сорап?!» дигән сүзләр бар. Әмма шагыйрьнең безгә билгеле булган шул чордагы иҗаты, җәмгыятьнең прогрессив катлавы кебек үк, авторның да тормышта уңай, якты үзгәрешләр көтүе хакында сөйли. Әмма кара реакция башлангач, аның да бөтен өметләре, хыяллары чәлпәрәмә килеп юкка чыга. Ул елларда аның күңелендә ниләр булганын, нинди давыл уйнаганын хәзер әйтү кыен, әлбәттә, тик шигырьнең бер генә шигъри юлы да аның каушап, югалып калуын күрсәтми. Телгә алынган сорауга килгәндә, шуны искәртик, аңарда «Инде нәрсә эшләргә?», «Кая барып бәрелергә?» дигән мәгънәләр бармыни?

Дәрдмәнд 1917 ел революциясе көннәрендә дә, Гражданнар сугышы елларында да, күпләр, чынлап та, ни эшләргә белмичә, башларын югалтып Россиядән качкан вакытта да югалып калмый. Ул үз Ватанында яшәп кала. Россиянең кайчандыр иң бай кешеләреннән булган һәм алтын приискаларын үз ирege белән берни таләп итмичә дәүләткә тапшырган Дәрдмәнд 1921 ел ачлыгы «кочагында» 62 яшенә дә җитмичә дөнья куя.

Дәрдмәнднең иҗат мирасы күләме ягыннан әллә ни зур түгел — шигырьләре мең юлдан аз гына артык. Шуңа күрә аның архивының берникадәр өлеше, Гражданнар сугышы елларында урланып, чит илгә чыгарылган дигән хәбәрләр күңелләрдә өмет уята һәм бу юнәлештә эзләнүләр алып бару теләген тудыра. Әмма иҗатының безгә билгеле булган өлеше генә дә татар әдәбияты өчен әйтеп бетергесез әһәмияткә ия һәм, һичшиксез, аның алтын битен тәшкил итә.

*Март, 1999*

# Алтын ачкычлы «резидент»

*(Зөфәр Фәтхетдинов иҗатына бер караш)*

Детектив әдәбиятка Россиядә озак еллар дәвамында тискәре караш булды. Янәсе, ул — сәнгатьлелектән шактый ерак, чын рухи кыйммәтләр бирә алмый торган юнәлеш. Россиядә тумаган, тамыры рус җирлегендә булмаган күп рухи яңалыкларга, бигрәк тә совет идеологиясе чорында, шундый караш яшәп килде. Кирәгеннән дә артык сак булырга өйрәнеп бетә язган татар язучысы, әлбәттә, мондый караш һәм мөнәсәбәт белән чакмага чакма килеп көрәшеп маташмады. Ул, тауны урап үтү хәерлерәк дип, бу жанрның маҗара тармагында җиң сызганып эшләргә кереште һәм, әйтергә кирәк, уңышларга да ирешә...

Ләкин без чын детектив жанрына килергә тиеш идек, чөнки әдәбиятыбызның дөнья әдәбиятының барлык казанышларын да үзләштерерлек җегәре бар иде. Һәм килдек тә. Модага бирелеп кенә түгел, ә Заһир Бигиев, Галимҗан Ибраһимовларның шушы юнәлештә ясаган беренче адымнарын дәвам итеп. Һәм безнең бу хәрәкәтне, минем карашымча, беренче чиратта Зөфәр Фәтхетдинов роман, повестьлары белән бәйләргә ныклы нигезебез бар.

Сиксәненче еллар башында Зөфәр әфәнденең «Тайна стоит жизни» дигән зур күләмле повестен Татарстанда һәм Россиядә укымый калган кеше сирәк булгандыр. Казан тирәсендәге монастырьларның берсе белән бәйле серле хәлләр, үтерешләр тасвирлана анда. Шуларны ачарга тырышучы чекистларга, милиция хезмәткәрләренә ияреп, әллә нинди серле, куркыныч мохиткә килеп эләгәсең һәм, үзең дә сизмәстән, прокуратура тикшерүчесе булып «эшли» башлыйсың. Бу чын детектив әсәрләргә хас үзенчәлекләрнең иң мөһиме, дияр идем мин. Авторның үзеннән дә уздырып җинаятьнең серен ачарга, җинаятьчеләрне фаш итәргә омтылыш биләп ала икән, димәк, синең кулыңда сәнгатьлелеге чамалы булган әсәр түгел, ә барлык хисләреңне акылың белән тоташтырган чын әдәби әсәр. Конан Дойлның, Жорж Сименонның, Агата Кристиның йә булмаса бертуган Вайнерларның, Юлиан Семеновның әсәрләре шундыйлардан түгелмени?!

«Тайна стоит жизни» повестен (мин аны роман дип билгеләр идем) «Казан утлары» журналы 1983 елда «Ачылган серләр» исеме астында бастырып чыгарды. Шушы ук журналда авторның «Ак «Жигули» эз югалта», «Кем — кемне...» повестьлары һәм «Үлем элмәге» дигән романы дөнья күрделәр. «Үлем элмәге» — детектив жанрның барлык таләпләренә туры килгән хәлдә, һичшиксез, аның кысаларына гына сыешмаган әсәр. Аны тарихи жанр белән детектив һәм маҗара жанрларының матур бер эретмәсе дип билгеләргә дә мөмкин. Батька Махно эмиссарларының Казан алтынын кулга төшерү өчен алып барган эшчәнлеген, җирле җинаятьчел төркемнәрнең мәкерле хәрәкәтен, гыйш-гыйшрәт уеннарын, җитди сәяси вакыйгаларны, Гражданнар сугышы чорындагы төрле социаль төркем кешеләренең тормышын, аларның сәяси һәм әхлакый аңын, психологиясен зур осталык белән, ә кайбер очракта үзәк өзгеч итеп сурәтләгән бу роман, әлбәттә, ае-

рым бер тикшерүгә лаеклы әсәр. Әгәр дә татар әдәби тәнкыйтенә яңадан җан керсә, бәлки, З.Фәтхетдинов әсәрләре һәм, гомумән, татар әдәбиятының детектив юнәлешенә багышланган мәкаләләрне уку бәхетенә дә ирешербез. Культуралы әдәбият үзенең һәр күренешен, һәр яңа әсәрен барлап, тикшереп, аларга бәя йә диагноз куеп барырга тиеш.

Аннары Зөфәр Фәтхетдинов киң катлам укучыларны Казанда, Мәскәүдә, Ленинградта нәшер ителгән «Убийство в старом доме», «Сквозь страх», «Резидент «Черная вдова», «Десятый мертвец» дигән роман һәм повестьлары белән сөендерде. «Десятый мертвец» повесте — моннан берничә ел элек Казанны гына түгел, бөтен Россияне тетрәндергән Республика махсус элемтә үзәгендә тугыз фельдъегерьның ерткычларча үтерелүен тикшерүгә нигезләнгән әсәр. Ул вакыттагы Казан прокуроры Сәйфихан Нәфиевнең бу шау-шулы җинаятьне ничек ачуын, Искәндәр Галимов җитәчелегендә Казан милициясенең ничек прокурорга ярдәм күрсәтүен автор документаль төгәллек һәм сәнгатьлелек ярдәмендә киң гомумиләштерүләргә һәм әхлакый, эстетик әһәмияткә ия булган чын әдәби әсәргә әвереләдерә алган. Азмыни ул бездә күләме белән генә журнал мәкаләләреннән аерылып торган повестьлар, хәтта романнар һәм рифмаланганга күрә генә поэма, баллада, шигырь дип йөртелгән газета публицистикасы?!

Зөфәр Фәтхетдинов әсәрләре берничә күркәм үзенчәлеккә ия. Беренчедән, аларның хокук саклау органнары эшен эчтән дә, тыштан да яхшы белгән юрист тарафыннан язылганлыклары, ягъни законны, кеше хокукларын яклаганлыклары, кем әйтмешли, мичкә керсә, койрыгыннан күренеп тора. Персонажларның теле, сөйләшү манерасы, төрле ситуациядәге гамәлләре — барысы да төгәл һәм ышандыргыч. Хәер, моңа артык гаҗәпләнәсе юк, чөнки автор Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлаганнан соң берничә еллар дәвамында Костромада прокуратура тикшерүчесе, аннары прокурор ярдәмчесе булып эшләгән һәм төрле җинаятьләрне ачуда үзе катнашкан кеше.

Икенче үзенчәлеге — ул һәр китабында диярлек күренекле татар зыялылары, кайбер сәхнә, сәнгать әсәрләре хакында үзенең соклануны хисләрен белгертергә урын таба. Аның роман, повестьларында Мәрҗани, Насыйри, Тукай, Сәйдәш, Урманче, Җиһанов кебек классиклар турында афористик әйтемнәр очратасың. Бүгенге күренекле сәнгать әһелләре Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев, Вафирә Гыйззәтуллина һәм башка сәхнә осталары турында да Зөфәр әфәнденең ихлас фикерләрен укыйбыз... Шушы да булдымы үзенчәлек, диярләр кайберәүләр. Әйе, бу — үзенчәлек. Дөрес, без конкрет шәхесләр турында истәлекләр дә, мәкаләләр дә (бигрәк тә юбилейлар уңаеннан) язарга яратабыз, ләкин бик сирәгебез генә драма, роман, поэмаларыбызга замандаш каләмдәшләребезне кертеп зурларга батырчылык итә. Ә аларга читләтеп кенә тибеп үтәргә, кимсетеп узарга дигәндә, без — осталар...

Тагын бер үзенчәлек — Зөфәр әфәнде үзенең әсәрләрендә дөньякүләм мәшһүр философлар, язучылар, галимнәрнең аксиома дип кабул ителә торган фикерләре белән бәхәсләшергә ярата. Әйтик, Ларошфуко, Горький, Гюго, Берже белән ул исемнәрен күрсәтеп бәхәсләшә. Әмма күп очракта — әйтмичә генә. Дәүләт төзелешенә, сәясәткә багышланган максималарында аның большевизм һәм фашизм классиклары, бүгенге «демократлар» белән бәхәсе аеруча кискен. Гомумән, аның әсәрләре афористик фикерләргә, көчле гомумиләштерүләргә бик бай. Менә «Унынчы мәет» повестеннан берничә үрнәк: «Хокукый булмаган дәүләтләрдә урын-дәрәҗә белән җаваплылык арасындагы мөнәсәбәтләр кире тәртиптә төзелә: урын-дәрәҗә түбәнрәк булган саен, җаваплылык арта бара, урын-дәрәҗә югарырак булган саен, җаваплылык кими», «Әдәп-әхлаксыз сәясәтчедән дә кансызрак, астыртын үткенлектә олы масштабка ирешкән башка җинаятьче юк». Мондый максималар Зөфәр әфәнденең китапларына күпләп сибелгәннәр һәм алар, әсәрләрне җитди ямь белән бизәп, иң кирәкле урыннарда балкып алалар. Зөфәр Фәтхетдинов осталыкка ирешкән язучы гына түгел, ул — танылган галим, юридик фәннәр докторы, Мәскәү, Казан университетларының профессоры, дөньякүләм данлыклы «Новый Мир» журналының редколлегия әгъзасы. Галимгә галим белән бәхәсләшәсе авыр түгел, галимгә надан белән бәхәсләшү кыен, чөнки мәгънәсез.

Соңгы елларда Зөфәр Фәтхетдинов талантының тагын бер ягы ялтырап китте. 1991 елда Ленинград нәшриятларының берсендә аның «Откровения XX века» дигән китабы чыкты. Бер меңнән артык афоризм һәм максималардан торган китапка күренекле экономист академик Станислав Шаталин, мәшһүр казах шагыйре Олжас Сөләйманов фатиха биргәннәр һәм бу илкүләм әдәби вакыйгага һәм аның авторына соклануларын белдергәннәр. 1996 елда Татарстан китап нәшрияты шушы мәҗмуганың тулыландырылган басмасын чыгарды. Ул инде 2300 дән артык миниатюраны туплаган һәм «Афоризмы и максимы или откровения XX века» дип атала. 16 бүлектән торган бу китап халык, дәүләт, кеше яшәешенең барлык тармакларын да, нигездә, колачлаган, дисәм, әллә ни хата булмастыр. Академик Шаталин сүзләре белән әйткәндә, китапка кергән «афоризмнар һәм максималарның күбесе фикернең тирәнлеге һәм социаль-сәяси, әхлакый, хокукый, психологик, идарә һәм кайнап торган тормышыбыздагы башка бик күп проблемаларны ачу-яктыртуда яңалыклары белән гаҗәпләндерәләр».

Афоризмнар китабын повесть йә хикәя укыган кебек укып булмый. Һәр афоризмны укып чыкканнан соң, кагыйдә буларак, тукталып уйланырга мәҗбүр буласың. Уең тирәнгәрәк киткән саен, афоризмны яңадан укыйсың, аның төбенә төшеп җитмәк буласың. Ә афоризмның төбе юк. Ул шушы хасияте белән шигырьгә охшаган. Афоризм, шигырь кебек үк, кеше күңелендәге мең йозакка ачкыч. Бер үк афоризмны төрле кеше төрле очракта укып, фәкать үзенә генә тиешле гыйбрәт ала. Әлеге хасият тә бертуган бу әдәби жанрларның тыгыз уртаклыгы хакында сөйли.

Татар әдәбиятында афоризмнарны махсус язган әдипләр бар. Өч-дүрт ел элек кенә «Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел!» дигән канатлы мәкальнең авторы Шәүкәт Галиевнең дә калын тапкыр фи-

керләр китабы чыкты. Ул да мәдәниятебез күгендә йолдыз булып кабынырга лаеклы китап, ләкин әлеге дә баягы мәрткә киткән әдәби тәнкыйтебез аркасында ул игътибардан читтәрәк калды.

Зөфәр Фәтхетдиновның әлеге китабы махсус, ягъни афоризм һәм максималарны мөстәкыйль жанр итеп карап язылган булулары белән генә түгел, ә XX гасырның төп катаклизмаларына, проблемаларына, казанышларына, җитешсезлекләренә, кыскасы, бөтен илләрне, ә Россияне беренче чиратта, иңләп алган вакыйгаларга катгый бәя бирүләре белән башкалардан аерылып тора. Аларда заманыбыз сурәтенең чәчелеп яткан төп кыйпылчыклары. Алар, мозаиканың тупланган өлешләре кебек үк, замана портретын танырлык итеп күз алдына китереп бастыралар.

Зөфәр Фәтхетдиновның берничә ел дәвамында Федерация Советы Рәисе урынбасарының киңәшчесе (советнигы) булып эшләве, заманасында РСФСР Конституциясен язуда катнашуы, бүгенге көндә дә икенче класслы Дәүләт советнигы чинын (ике йолдызлы генерал дәрәҗәсе) йөртүе, әлбәттә, сәяси, социаль, әхлакый тормышыбызның төпкеленә үтеп кереп, андагы күп вакыйгаларның асыл тамырларын күрергә һәм аларга кыю язучы буларак бәя бирергә ярдәм итә. Кырыс аналитик, кешечә, хөкем итмичә генә аңларга һәм аңлатырга тырышучы юрист, үзе ихтирам иткән кешеләргә ярдәм итәргә әзер дус, һәр очракта да чын зыялы, джентльмен булып кала белгән кеше — болар барысы да Зөфәр Фәтхетдиновның сыйфат билгеләре һәм шулар аны кызыклы шәхес, зур язучы итеп таныттылар да.

Өстәрәк мин афоризмны, мәкальне мең йозакка яраклы ачкыч белән тиңләгән идем. Шул фикерне дәвам итеп, бүгенге көндә өч меңнән артык афоризм һәм максима язган Зөфәр Фәтхетдиновка минем «Алтын ачкыч ясаучы «резидент» дигән исем бирәсем килә. Чынлап та, ул үзенең әдәби дөньясында бик күп кызыклы һәм куркыныч, акыллы һәм хәйләкәр, нәфис һәм башкисәр персонажлар белән оста идарә итүче, укучыларына шул дөньядан гыйбрәтле һәм матур хәбәрләр җибәреп торучы «резидент» та...

*2000*

# Сөләйманның шигъри дөньясы

Шагыйрь Сөләйманның — кайберәүләр аны университет профессоры Җәүдәт Шәүкәт улы Сөләйманов дип беләләр — соңгы биш-алты ел эчендә «Ямаулыклар», «Ташъязма», «Күләгәләр», «Мин минсез дөньяда» дигән шигырь китаплары «Мәгариф» кебек дәрәҗәле һәм башка нәшриятларда басылып чыкты. Исемнәреннән үк күренгәнчә, алар ниндидер үзенчәлеккә, алтмышынчы еллар татар әдәби тәнкыйте термины белән әйткәндә — «шаккатризмга» дәгъва итәләр иде. Ләкин безнең әдәби тәнкыйтебез ул китапларны күз ягалай җибәрде. Хәер, бу хәл татар әдәби тәнкыйтенең типик күренешенә әверелеп бара бугай инде... Кызганыч, әдәбиятыбызның мактанычы булырлык күпме әсәр һәм аны үзешчәнлек дәрәҗәсенә төшергән күпме «шедевр» тәнкыйть игътибарыннан читтә калды һәм уңышлы төстә кала бирә... Алай гына да түгел, шул «шедевр»лар дәрәҗәле газета-журналларда басылган була һәм, чыннан да, шаккаткыч, мактала...

Сөләйманның алда телгә алынган китапларын мин басылып чыкканчы да, басылып чыккач та укыдым. Аларны кулъязма хәлендә укыганда, мин күңелемдә ниндидер сәер тойгы урнашканын сиздем... Күңелнең «талдыйн талга кунып» сайраган сандугачлары кәрәзле телефон мачталарына гына басып түгел, ә замананың иң катлаулы техник казанышларына, фәнни ачышларына да кунып сайрагандай булып китте. Аның шигырь юлларына эләгеп, сүзләр җөмләләрдә үзләренең күнеккән урыннарын югалтканнар да башкачарак тәртиптә урнашканнар кебек тоелды. Борынгы Рим шагыйре, «Шигърият фәне» дигән мәшһүр трактат авторы Горацийның «Чын шигырьдә сүзләр үзләренең бер-берсе белән күрше торуларына шаккатырга тиешләр» дигән фикере искә төште...

Ни өчендер Пушкин, Лермонтовның каурый каләм белән язып, ком сибеп киптергән шигырьләре, Тукай, Дәрдмәнднең корыч каләмне кара савытына манып язган кулъязмалары, Сибгат Хәким, Хәсән Туфаннарның каләмле һәм шарикле авторучкалар белән язган кулъязмалары күз алдыма килде.

Һәм мин үземә тиз генә җавап бирә алмый торган сорау бирдем: әллә инде шигырьдә аны язган иструмент та үзен сиздерәме?

Соравыма җавап эзләү юлында мин авторга — техник фәннәр докторы, Казан дәүләт университеты профессоры Җәүдәт Сөләймановка — берничә туры сорау бирергә мәҗбүр булдым. Фәндә ясалма интеллект проблемалары белән шөгыльләнүче, компьютерларны татар телендә уйларга, язарга, сөйләшергә өйрәтүче бу галим белән әңгәмәләр миңа күп нәрсәне ачыкларга ярдәм итте.

Шагыйрь Сөләйман өчен компьютер — каләм ролен үтәүче әсбап булу белән беррәттән, аның үзен шигырь дөньясына алып керә торган тылсымлы ишек тә, шул ишек ачылгач башланып китә торган, уйга, хискә төгәл форма-калып бирә торган дөньяның үзе дә. Компьютер — кешенең хаотик рәвештә, йә булмаса нәүбәтен көтмичә алданрак туган фикерләрен кирәге чыгар әле дип туплап, таслап баручы хәтер капчыгы да. Бу замана машинасы — уй, шигъри детальләр, образлар, телнең сурәтләү чаралары белән төрле экспериментлар үткәрү өчен чикләнмәгән мөмкинлекләре булган җайланма да. Әмма компьютердан әлеге сәләтләрен күрсәттерү өчен син әүвәл шагыйрь булып туарга тиешсең, һәм әнә шул могҗиза-компьютер шагыйрь булып туган Сөләйманга җаны-карынында яралган шигырьләрен заманча итеп дөньяга китерергә ярдәм итә. Шуның өчендер дә аның шигырьләрендә без фән-техника чорына хас күзаллаулар, логик экспериментлар, термин дәрәҗәсенә барып җиткән атамалар һәм башка үзенчәлекләр белән очрашабыз. Әнә шәфәкъ куерма-

сыннан хасил миләш, баланнар, агачның җиргә сикереп төшеп биегән шәүләсе, үзе шул дөньяда булмаган килеш аның буйлап сәяхәт итүче шагыйрь, шигырьгә әверелгән милләт, йөгән-фикер, гәүдә-курчак... Әнә дүрт кат дөнья, җидегә ярылу, бер кат күңел, Тәңре язган Җиһан китабы, тишкәләнгән күңел күге, галәмне тырмалаучы вакыт...

Минем буын язучылары атом һәм космос заманына туры килде. Безнең сурәтләү чаралары да, образ-детальләребез дә, фикер йөртү ысулларыбыз да үз заманыбыз аһәңе, төсе, киңлеге-тирәнлеге белән сугарылган иде. Космоска очулар, синхрофазотроннар, мезоннар, Эйнштейнның чагыштырмалылык теориясе үткән гасырның 60–70 нче елларында әдәбиятка килүчеләрнең әсәрләренә тема булып кына түгел, персонаж, сурәтләү чарасы, шигъри деталь, образ булып та килеп керделәр. Безнең буын шагыйрьләрен дә «мөгез чыгаруда» гаепләргә тырышучылар, «юкны эзләмәскә, барны үстерергә» өндәүчеләр булды.

Физиклар һәм лириклар проблемасы сәнгатьтә бүген дә бар. Ләкин ул, космос, атом-төш процессларына игътибарын югалтмаган хәлдә, күбрәк ясалма интеллект, ген инженериясе, табигатьнең һәм тереклекнең аномаль күренешләрен аңлау-аңлату тирәсендә куера. Кешенең ай-йолдызлар белән генә бәйләнеше — инде искергән этап. Кешенең аңын бөтен җиһан тарта, аны ике параллель сызыкның чиксезлектә кисешкән урыны кызыксындыра. Алга килеп баскан проблема һәр талантлы иҗат кешесендә бу серле ишекне ачу теләге уята — ниләр бар икән ишекнең теге ягында, анда безне нинди гаҗәеп дөнья көтә? Һәм кеше ул ишекне ача да шакката — йә сокланудан, йә куркудан, йә аптыраудан, йә башка бер сәбәптән... Мин үзем сәнгатьнең, шул исәптән шигырьнең дә, нигезендә шаккату ятадыр дип уйлыйм. Ләкин «шаккатризм» түгел...

Сөләйманда шаккату хисе гаҗәеп көчле. Ул катлаулы нәрсәләрдә һәр кешегә аңлашыла торган гади мәгънә күргәндә дә, гади генә булып күренгән әйберләрдән, күренешләрдән шактый катлаулы процесслар актарып чыгарганда да чын шагыйрьләргә хас шаккату белән хисләнә һәм хисләрен үзенә генә хас алымнар белән сурәтләп бирә:

Иңдә — җиһан, билдә — офык, аяклар очак иде... Абынып, очтым упкынга... Ул — синең кочак иде... Йә булмаса менә бу юллар:

Кышның әле көмеш туе — күктә, җирдә ылысларның түбәтәйле, хозур чагы. Ә йөрәкнең үз фасылы... Йөрәк сизә — озакламый бәллүрләнеп килгән кар өстендә умырзая калкачагын.

Менә шагыйрь әбиләр чуагы тукып ел фасыллары арасына элгән чаршауны ача да көзгә кереп бара:

...Балкыш элпә аша кояш карый күзгә, килә чайкаласы ятып пәрәвезгә...

Болар, әлбәттә, шагыйрьнең сокланудан туган шаккатулары. Алар һич көчәнмичә, үзләреннән-үзләре шигырьгә әверелгәннәр кебек. Ләкин аларда мин барыбер заманабызга хас булган фикерләү алымнарын, сурәтләү чараларын аермачык күрәм. Бер уйласаң, һәр чын шигырь — кечкенә генә булса да ачыш, ә ачышка уйлау юнәлешен, фикерләү алымнарын үзгәртеп кенә ирешеп була.

Соклану Сөләйманны шагыйрь иткән бердәнбер хис түгел, әлбәттә. Ул кайгыра да, үпкәли дә, ачулана да, борчыла да, өметләнә дә, кызгана да, уфтана да, чөнки ул, иң беренче нәүбәттә, — мәшәкатьләр тулы Җир кешесе.

Мең җәрәхәт — түзә йөрәк...
Эзен салган һәр теш кысу...
Сабан-телләр һаман сөрә.
Безгә — бәгырь,
сезгә — басу...

Алда китерелгән мисаллар Сөләйманның рәссамлык сәләтен, сүзләрдән затлы, матур фикер-хис тукымалары үрә белгәнлеген дәлилли. Ләкин аларда гына шагыйрьнең төп үзенчәлекләре ачылып бетми. Ул маңгай күзе күргән дөньядан шактый катлаулырак булган, күңел күзе белән генә күреп булган, төпле тирән белем (интеллект) ачкычы белән генә ачып булган дөньяларга сәяхәт кылырга ярата. Сөләйман шул дөньяларда бер генә татар шагыйренә дә охшамаган, яхшы мәгънәдә элитар шагыйрьгә әверелә. Бу җәһәттән аның «Олы сәфәр» дигән, шагыйрь өчен дә, укучы өчен дә принципиаль булган шигыренә тирәнрәк кереп карау кирәк булыр.

Тәңрегә юл ачылганда,
вакыт килеп,
Елмаюга әверелсә соңгы тының,
Димәк, Тәңре сине юкка яратмаган,
Бөек мәгънә тулы икән елмаюың... —

дип башланган бу поэма-шигырьдә кешенең үлем алды һәм шул ук вакытта кеше аңының иң бөек көч, иң олы сер, иң якты тылсым белән тоташуы турында сүз бара. Бу вакытта кеше үзенең Җиһанга да, үзеннән башка җан ияләренә дә, үзенә дә кирәкле итеп яратылганы хакында уйлана. Кешенең тууы — «...Җиһан куермасы Җиргә иңгән мизгел», ә Җир үзе — Галәм, чиксезлек китабында бер сүрә, һәм шул сүрәдә кеше бер аять була алырмы? Кырыс тормыш аның җанын йон теткәндәй тетә:

...күпме сугу, күпме кагу, күпме гамәл.
Тигезләмә чишә-чишә уза гомер,
Син бәхетле — җан тетүгә тапсаң әмәл,
Үзәгеңә тынгы биреп тетелсә җан,

Өч дөньяңны тоташтырса бер көй, бер моң —
Соңгы сулыш тәүге сулыш булыр, Аллам:
Ике дөнья арасында — арадашчың...

Бу әсәр белән җентекләбрәк танышуны мин укучының үзенә калдырам, чөнки анда һәр кеше күңелендә йөргән, йә булмаса йөриячәк моң-хәят турында сүз бара. Ә үз күңелендәгене һәр кеше фәкать үзе генә, үзенчә кенә аңлый һәм аңлата...

Әлеге әсәргә хас үзенчәлекләр Сөләйманның башка бик күп шигырьләрендә дә чагылыш таба. Аларда да виртуаль, ягъни булулары ихтимал, дөньялар, әйберләр, мөмкинлекләр чынбарлыктагыча реаль итеп сурәтләнәләр. Әйтик:

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак дөньяга:
Тәңре яраткан җаннармы
Тәңре корган ояда?

Йә булмаса:

Ошбу тәнсез — фикер өнсез (өйсез мәгънәсендә)
Ошбу тәндә — үзем теләп...
Җиһан-дәрья гизеп йөреш
Өнсез өннең өнен өнәп (ягъни — өйсез-оясыз чынбарлыкның авазын-тавышын ишетергә теләп...)

Сөләйманның тагын бер үзенчәлеге — тарихыбыз, телебез материалларын, гореф-гадәтләребезне әсәрләренең аркау җебе итеп куллану. Белгечлеге буенча шагыйрь — төгәл фәннәр кешесе, математика, электроника өлкәсендә югары фәнни дәрәҗәләргә ирешкән галим. Ул моңа мәктәпләрдә дә, югары уку йортында да, аспирантура, докторантура юлларында уңга-сулга сибелмичә, бераз көтеп тора алган нәрсәләр белән зиһенен чүпләмичә, гаҗәеп максатчан адымнар ясап ирешкән. Тарихыбыз, телебез дөньясының серле ишеген ул җитлеккән галим булгач каерып ачкан һәм... шаккаткан булырга тиеш, дип уйлыйм. Сөләйман әсәрләрендә ерак тарих әкият түгел, ә бүгенге катлаулы нәрсәләрнең гасырлар-дәверләр катламы астында калган сукмакларын бүгенге шагыйрь күз нурлары белән капшап карау. Ул татар халкының Алтай якларына тоташкан тамырларында кан булып ага, уйлана, борчыла.

Мин татармын,
әмма бүлгәләмә!
Каныма да тимә, тамчылап,
Тарих җайлап, өндәп маташмаган,
Татар иткән төеп-камчылап! —

ди ул бер шигырендә.

Бу катлаулы, әмма үтә мавыктыргыч җан сәяхәтеннән алган тәэсирләрен, уй-фикерләрен шагыйрь заманча сурәтләү чаралары белән, һәм иң мөһиме галимнәргә хас төгәллек, яшүсмерләргә хас темперамент, хис белән, аптырашын да яшермичә, укучысына тәкъдим итә. Менә шагыйрьнең үз күңеле белән аңлашкан мизгеле. Ул, күңеле күзенә карап, болай ди:

Йә, ник шулай йокы белмисең син,
текәләсең нигә үтәли,
күңел күзем,
маңгай күзен узып?
Син күргәнне аңлап җитәлмим...

Әле күптән түгел генә сәнгать әсәрләрен бәяләгәндә, без гаҗәеп универсаль һәм көчле булган «халыкчанлык» дигән төшенчә куллана идек. Әйе, әдәби әсәрнең халык массаларына аңлаешлылыгы, аларның идеалларын, мәнфәгатьләрен яктыртырга тиешлеге бүген дә әллә ни бәхәс кубармый шикелле. Ләкин сәнгать әсәре халык массалары югарылыганда гына калса, ул халыкның аңын, әхлагын, эстетик зәвыгын тагы да биегрәк үрләргә күтәрергә ничегрәк ярдәм итә алыр икән соң? Бу сорау да, әлбәттә, бәхәсле. Ләкин һәр халыкның массалардан бераз гына югарырак торган элитар сәнгате, элитар әдәбияты да булырга тиештер. Бу минем өчен бәхәссез. Тик моңа омтылганда бер нәрсәне онытмаска кирәк — йә замана, йә башка халыклар модасына бирелгән кыланчык сәнгать белән югары менталитетлы һәм яңача табышларга бай сәнгатьне бутамаска. Мода, бигрәк тә читтән кергәне, һәрвакыт үтә, сүнә, бетә. Традициягә әверелер өчен модага бик күп тапкыр спираль юлны кабатларга кирәк... Ә Сөләйманның иҗат тамырлары халыкта, тарихыбызда, традицияләребездә, ә ябалдашы заманабыз ирешкән биеклекләрдә.

*2001*

# Мера человеческого участия

*К 60-летию Порфирия Афанасьева*

Поэта Порфирия Афанасьева я знаю так же долго, как и самого себя. Мы с ним оба взрастали поэтами в одни и те же годы, в стенах одного и того же педагогического института в Казани. Даже некоторые преподаватели-профессора у нас были одни и те же. Порфирий был заметным, общественно активным студентом, много писал в институтскую газету, рисовал факультетскую стенную газету, которая выходила длиной в 7–8 метров. В этих газетах я впервые прочитал стихи какого-то Ахванеса Пурхилле, который потом оказался Порфирием Афанасьевым... Эх, найти бы сейчас эти газеты и заглянуть в нашу романтическую студенческую юность, подышать бы атмосферой «хрущевской оттепели», породившей в литературах народов СССР писателей-шестидесятников, которые отличались как смелостью мыслей, так и новизной, раскованностью чувств и форм. Мы — шестидесятники... Он, специалист по русскому языку и литературе, стал писателем, пишущим на чувашском языке, а я, тоже такой же специалист, стал татароязычным писателем. В нас жажда познания другого языка и культуры, что так ценилось и поощрялось, не смогла стать препятствием для заключенной в крови творческой силы. Я хорошо помню: в студенческие годы Порфирий пытался писать и на русском языке, и делал на этом поприще некоторые успехи. Особенно в переводе своих же стихотворений. И в этом он следовал традициям, заложенным выдающимся поэтом Петром Петровичем Хузангаем — литературным учителем и кумиром Порфирия, который отлично писал и на русском языке. Но с молоком материнским впитавшееся волшебство родного языка взяло верх. Мне трудно судить о красоте чувашского поэтического слога Порфирия Афанасьева. Но я верю Юрию Семендеру, который высоко ценит простоту стиля, народность языка Порфирия, который в свою очередь восхищается песенным слогом, философичностью метафор своего собрата по перу... К тому же истинная поэтичность просачивается даже через переводы на другие языки. Стихи Порфирия Афанасьева в переводах на татарский и русский языки меня волнуют, возбуждают мой ум и вводят в богатый мир переживаний и раздумий автора.

В 1990 году в Казани издана книга стихов Порфирия Афанасьева на татарском языке «Чирмешәннең йотым суы» («Глоток воды из Черемшана»). Основным переводчиком этого сборника является известный татарский поэт Кави Латыпов, владеющий чувашским языком. И я с удовольствием перевел несколько произведений Порфирия. Во время составления и работы над этой книгой я еще раз убедился в том, что эпоха на каждого из поэтов накладывает почти идентичные отпечатки, и только истинный поэт превращает их в неповторимо-своеобразные произведения. В книге Порфирия я встретился с великолепными картинами Дня Победы, первого весеннего дождя, вечерней зари, очень убедительно нарисованными портретами осени, весны, коней, соловья, лося, с восторженным отношением автора к своим предкам, родной земле, друзьям, учителям... Я был восхищен его поэтическим открытием в «теории измерений», встретившись в одном из стихотворений с предложением принять за единицу измерения человеческого счастья МИР и ПОКОЙ. Это же действительно так — человеку никогда не обрести счастья, если не будет мира на Земле и в стране, если не будет покоя в душе. Действительно, почему бы их

Нам тоже не сделать мерой
Человеческого участья
К счастью чужому и горю,
К надеждам чужим и порывам?..

Я получил истинное удовольствие от его любовной лирики — неподдельной, искренней. Так называемые «стихи про любовь» уже всем набили оскомину и по сей день скрипят на зубах камнями двух крайностей — или восторга, или проклятия. Палитра чувств Порфирия в любовных стихах изобилует множеством всевозможных красок и оттенков души. И, самое главное, эти цвета, эти оттенки, как я думаю, становятся украшением души каждого искреннего человека, искреннего по отношению к самому себе.

Порфирий Афанасьев — мастер сложного поэтического ремесла. Ему подвластны не только весь арсенал изобразительно-выразительных средств чувашской поэтической речи, но и ее жанровое разнообразие — от национально-чувашского до общепринятого мирового. Многие поэты, к сожалению, налегают в основном на два-три поэтических жанра, ограничивая тем самым свои творческие возможности и оставляя в стороне вопросы дальнейшего развития жанров литературы. Порфирий достигает высокой культуры как в строфичных и нестрофичных, рифмованных и белых стихах, так и песенных текстах и балладах, поэмах и стихотворных драмах. В последних он продолжает и развивает замечательные традиции Ухсая и Хузангая. В то же время поэт успешно работает в области прозы и художественного перевода. Ему принадлежат переводы произведений классиков мировой литературы, литератур народов СНГ, России. Я горжусь тем, что он вместе с Юрием Семендером и Гурием Чаржовым перевел и мою книгу «Юрату сукмаке» на чувашский язык.

Как я уже говорил, с Порфирием Афанасьевым меня связывает многое, и эта связь с каждым годом становится крепче и надежнее. Мы сейчас, к счастью, чаще встречаемся и в Чебоксарах и в Казани, чаще созваниваемся, делимся и радостью, и горем — и того, и другого в нашем возрасте, и это естественно, бывает немало — и помогаем друг другу разместить их в сердце.

Моего земляка — уроженца деревни Новое Ильмово Черемшанского района, — почти что сокурсника по Казанскому педагогическому институту, а самое главное — большого чувашского поэта и общественного деятеля — поздравляю с юбилеем. Я верю в то, что доброе сердце Порфирия Афанасьева будет щедро одаривать нас светлыми и теплыми чувствами, а его изобретательный ум обогатит нас поэтической мудростью,

ведь весь пройденный творческий путь его — это солидная мера участия поэта в судьбе своего народа и родины, имеющая тенденцию расширяться!

*2002*

# Камил Тангалычев шигырьләре

Шигырьләрен рус телендә язучы татар кешеләрен миңа Россиянең һәм элекке СССРның төрле төбәкләрендә очратырга туры килде. Кайберләре үзләренең иҗат җимешләрен укып күрсәттеләр, бәгъзеләре әсәрләре басылган газета-журнал биреп җибәрде, ә кайсыларының инде китаплары да бар иде... Ләкин мин ул шигырьчеләрнең күбесен инде хәтерләмим, күрәсең, шигырьләренең минем хәтеремә эләгеп кала торган ыргаклары-кармаклары тиешле дәрәҗәдә очлы булмагандыр...

Ике ел элек, Һади Такташның туган авылы Сыркыдыга барып чыккач, мин Мордовия газеталарының берсендә эшләүче Камил Тангалычев белән таныштым һәм аның Такташ иҗаты турындагы докладын тыңладым. Ул доклад миңа көтелмәгәнчә тирән һәм бик тә үзенчәлекле булып тоелды. Барыннан да элек, мине Тангалычевның Такташны күзәтә торган урыны сискәндерде — ул урын Җирдә дә түгел иде, күктә дә түгел иде, ә кайдадыр урталыкта, Җирдә һәм күктә яшәүче барлык субстанцияләрнең очрашып фикер алыша торган бер биеклегендә кебек иде... Бу докладтан соң без балачактан бирле яттан сөйләп йөри торган һәркемгә дә төбенә хәтле аңлаешлы Такташ минем өчен яңадан серле, тирән, колачлы шагыйрьгә әверелде...

Ярар, мин сүз уңаеннан гына ул докладны искә алдым. Минем төп сүзем — Камил Тангалычев дигән шагыйрьнең шигырьләре турында. Шунысын да алдан ук әйтеп куйыйм: мисалга китерелә торган шигырьләр рус телендә булыр, чөнки тәрҗемәдә алар үзләренең һәм мәгънәдәге, һәм шигърилектәге, һәм осталыктагы төп хасиятләрен шактый югалтачаклар. Ә шигырьләр мине иң беренче нәүбәттә русчалыклары белән җәлеп итте.

Утыз биш яшьлек Камил Тангалычевның бүгенге көнгә дүрт шигырь китабы һәм ике эсселар, хикәяләр җыентыгы дөнья күргән. Әле күптән түгел генә минем кулыма килеп кергән китабының исеме «Дорога в Казань» дип атала һәм ул элеккегеләре кебек үк зур әдәби җаваплылык белән тупланган шигырьләрдән тора.

Китапка исем биргән шигырендә автор, колхозның ак атына утырып, балачактан бирле кырлар буйлап Казанга баруын сурәтли.

Бесконечно грохочет телега,
И пути мне обратного нет.
Мой народ превратился в младенца,
Я старею — мне тысяча лет.
Первым долгом — жива ли Россия? —
Спросишь строго, когда возвращусь.
И смиренно тебе я отвечу:
Я и есть — первозданная Русь...

Казанга юл авторны туган халкына алып кайта торган юл гына түгел, ул татар халкын үзенең самими сабый чагына, чын татарлыгына алып кайта торган юл да икән әле. Алай гына да түгел, бу юл — шагыйрьгә үз халкының мең еллык тарихи тәҗрибәсен тиз, бер гомер дәверендә туплап алырга ярдәм итә торган юл да икән. Шагыйрьгә Казан юлын күрсәткән һәм Казаннан хәбәр көтеп калган кешегә ул әнә нинди тирән уйларга чумдыра торган җавап бирә...

Шагыйрьнең «Глагол» («Сүз») дигән шигыре алда китерелгән юлларга күпмедер ачыклык кертә кебек:

Как горько полыхал огонь,
Вознесшийся из мрачной бездны!
Спалили на Руси глагол,
Молчанье на Руси воскресло.
Однажды в жгучем феврале
В простой избе горела лампа.
И с зарастающих полей
Вернулась к свету тень таланта.
Пока не гас ночной огонь,
У колыбели вознесенной
Стоял восторженный глагол,
В нерусском доме воскрешенный...

Рус телендә язучы татарлар ни сәбәптер күп кенә әсәрләрен Россия, Руська багышлыйлар. Мин үзем Михаил Львовның, Роман Солнцевның, Равил Бохараевның бик матур шундый шигырьләрен беләм. Татар кешесе өчен бу сүзләрдә, күрәсең, башка халыклар өчен бик үк мөһим булмаган мәгънәләр дә бардыр. Ни дисәң дә, татар белән рус — Европаның бу төбәгендә дәүләт корып яшәгән ике якын күрше. Күп гасырлар дәвамында бу ике дәүләт арасында ни генә булмаган?! Ике дәүләтнең дә, аларны төзегән ике халыкның да тарихи хәтерләре тирән һәм күпкырлы. Болгарның, Алтын Урда һәм Казан ханлыгының рус халкы дәүләтчелегенә уңай йогынтысы дөньяга мәгълүм. Һәм шушы мәгълүмат горур татар кешесе күңелендә горур шигырь-

гә, ә вакчыл татар күңелендә селтеле төкереккә әверелә торгандыр... Камил Тангалычевның да бик күп, хәтта артык күп шигырьләре Русь-Россия турында. Бу шигырьләр рус телендә язылулары өстәвенә чын мәгънәсендә русча язылганнар:

Отступленья, сраженья, победы...
Как просторы России болят!
Никогда драма гибели света
Не закончится в русских полях.

Вновь наряды надев, вдохновенно
Поколенья идут умирать...
Не пора ли мне выйти на сцену,
Чтоб поэта России сыграть?

Чтоб играть, гениально скрывая
От России святые грехи, —
За творенье свое выдавая
Сочиненные богом стихи?..

Йә булмаса «Табунщик» шигыренең ике генә строфасына игътибар итик:

И тройка-Русь в Россию не вернется.
Здесь вместо ямщиков поет гроза.
Табун-Россия по Земле несется,
Испуганно взмывают небеса.

Отвергнут Ленин, нету Чингисхана,
Сорвался кнут со сталинской руки.
Россию понукают ураганы,
И хлещут молодые тальники...

Мондый шигырьләрне, минемчә, «Я и есть — первозданная Русь» дип әйтергә хокукы булган шагыйрь генә яза ала.

Камилнең шигырьләренә үзенчәлек биреп тора торган тагын бер нәрсә — мифологик һәм дини образлар, төшенчәләр. Алар күбесенчә христиан диненнән кергәннәр, һәм шагыйрьнең образлар дөньясындагы төп көчләргә дә, сурәтләү чараларына кирәк булган детальләргә дә, сурәтләү объектларына да, фикергә юнәлеш бирә торган маякларга да әверелгәннәр.

Әлеге фикерләргә алда китерелгән шигырьләр дә мисал була алыр иде. Ләкин тагын берничә мисал китерсәм, Камилнең эстетик һәм фәлсәфи принциплары ачыграк күренер кебек.

В России бог творит себя
Средь пеплещ ее тревожных.
Себя он создает — любя,
Людей любить так невозможно...

Менә «Твое имя» дигән һәм Аллаһка багышланган шигырь:

Без тебя на земле пропадаю.
Жду тебя — каждый миг начеку.
Твоим именем мир называю —
И былинку, и дым, и реку.

Всей Вселенной обрушится зданье,
Если вдруг твой цветок оторву.
А когда ты придешь в мирозданье,
По-другому я мир назову.

В мое сердце пробравшись полями,
Ты в моих поселился стихах...

Һәм, чынлап та, Камил Тангалычев шигырьләрендә боглар, аллаһлар, фәрештәләр, шайтаннар, херувимнар, серафимнар, йорт ияләре, ду китереп, пәйгамбәрләр, Иван Грозныйлар, Сөембикәләр, татар картлары-карчыклары, мордва кызлары белән бергә бик матур гына яшәп яталар һәм аңа шагыйранә шатланырга, кайгырырга, хозурланырга, уйланырга, борчылырга «ярдәм» итәләр. Шул төшенчәләргә таянып, шагыйрь җир тигезлегеннән калка төшә, андагы мәшәкатьләргә, ыгы-зыгыларга, сәяси һәм тарихи вакыйгаларга милли чикләр белән кыршауланмаган биеклектән карарга җай таба.

«Башня» дигән шигырендә Тангалычев Сөембикәнең манарадан сикергәнен сурәтли һәм бу сурәт манара нигезеннән өскә таба карап түгел, ә манара өстеннән очып үткән болытка утырып төшерелгән:

Не башня твоя к солнцу улетает —
Земля твоя сегодня высока.

Ты, сумрачную башню покидая,
И небо оставляла на века.

Луна, тоскуя о тебе, усохла.
Но знала ты — смиренная жена, —
Что нужно богу возвращать высоты,
Когда высоты занял Сатана...

Әлбәттә, Камил Тангалычевның «Ночь сияет. Стог соломы В светлом чреве тишины... Мне уютно в отчем доме В час мерцания луны...», «Я не отыскал к реке тропинок, Но моя увидела душа, Как в тиши сияние кувшинок Золотило горечь камыша...» кебек гаҗәеп җылы, чык сәйләне белән өртелгән шигырьләре дә күп. Ләкин андыйларын без башка шагыйрьләрдә дә еш очратабыз...

«Дорога в Казань» китабына аңлатма биреп, нәшрият Тангалычев иҗатының хасиятен «Его поэзия традиционно отстаивает ценность вселенского всеобщего человека, преодолевающего свою национальную и религиозную ограниченность» дип билгели. Ләкин Камилнең шигырьләре моның нәкъ киресен сөйли түгелме соң?! Минемчә, аның китапларының лирик герое, димәк, күпмедер дәрәҗәдә аның авторы да, милли һәм дини кысалардан арынырга тырышкан кеше түгел, ә ике динне, ике телне, ике гореф-гадәтне бер йөрәккә сыйдырырга тырышкан кеше. Ул — йолдызлар, кояш, ай нурларыннан, чиксезлек салкыныннан, «кара тишекләр» караңгылыгыннан хасил җан һәм аң иясе түгел, ә тәнендә сөя, борчыла, нәфрәтләнә белә торган, колакны куеп тибешен тыңлап була торган йөрәк йөртә. Үзе әйтмешли:

Мое сердце — ком выцветшей глины —
Ты унес в утомленных руках.
Накануне похода в геенну
Ты на глинистых был берегах.

Мое сердце, покоя не зная,
Каменеет от жгучих тревог.
Для фундамента нового рая
Ты в аду обжигаешь его...

Һәм мондый йөрәк фәкать Җир кешесендә генә, җәмгыяви кешедә генә була ала, һәм миңа әнә шундый йөрәк кадерле.

*Гыйнвар, 2003*

# Шигырьләр түшәлгән сукмакта

*(Мостай Кәримгә 85 яшь тулу уңаеннан)*

Мостай Кәрим үзенең бер шигырендә «Әмма мине шагыйрь ясадылар Югалтулар белән сагышлар» ди. Нинди олы югалтулар һәм нинди тылсымлы сагышлар икән алар? Шушы кызыксыну мине Мостай Кәримнең күңел дөньясына өндәде һәм мин шагыйрьнең биш томлыгын башлап җибәргән томның ишек тоткасын тарттым. Ишек ачылды. Шигырь белән түшәлгән сукмаклар күренде, һәм шуларның берсе мине, фикер арты фикер белән ымсындыра-ымсындыра, гаҗәеп бер дөньяга алып кереп китте. Бу дөнья миңа, әлбәттә, таныш, чөнки мин Мостай Кәримнең күпчелек әсәрләрен, бигрәк тә шигырьләрен, җырларын, драма әсәрләрен гомер дәвамында белә килдем. Әмма анда кызыксыну учагымны яңа көч белән дөрләтүче нәрсәләр дә бик күп икән. Дөресен әйткәндә, миңа әлегә хәтле Мостай Кәримнең шигырьләрен хронологик тәртиптә укырга туры килгәне юк иде.

Язучының әсәрләрен хронологик тәртиптә күбрәк әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр укый — йә диссертация язар өчен, йә башка бер максат белән. Мин исә әлеге томның ишеген бүгенге «Мудрый Мостай»-ның, исеме Европа һәм Азия киңлекләрендә яңгыраган олпат шагыйрьнең, оныгым кебек яшь чагын, улым кебек гаярь чагын, үзем кебек гомер көзенә кергән мизгелләрен күрергә дип, аңардан ике генә яшькә өлкәнрәк булган әтием кичерә торган, әле үзем татып карамаган хисләр дөньясында йөреп карарга һәм алда әйткән кызыксыну сусынын басыйм әле дип ачтым.

Менә Мостай Кәримнең унсигез яшьлек чагы. Илдә телләрне тешләткән, авызларга йозак элгән хәтәр 1937 ел. Ул яза:

Шагыйрь тора текә ярга басып,
Горур башы түбән иелгән.
Уйлагандыр шунда: Бәлки, тиздән
Таң да атыр инде илемдә.
Азатлыкны сагынып, ашкынгандыр
Дулкыннарны юлдаш итәргә...

Пушкин турындагы бу шигырь, әлбәттә, ул еллардагы репрессияләрне күреп, ишетеп торган, ул чорның киеренке һавасын сулаган яшь Мостай турында да. Үзенең хисләрен, тойгыларын һәм күңел халәтен укучы-

сына җиткерер өчен ул акыллы юл тапкан. Без дә бүген кайбер очракларда шундый юллар эзләмибезмени?!

Мин йокысыз саташудан айнып,
Май төне һәм Өфө хакында,
Яшәү кебек татлы уйга чумып,
Басып торам урам чатында.

Хәлсезләнеп ерак йолдыз сүнә,
Айдан соңгы нурлар түгелә,
Кызыл диңгез булып, таң җәелә
Республика һәм кала күгенә.

1939 елда язылган бу шигырьдә дә мин сүзләрнең, образларның автологик мәгънәләреннән дә бигрәк аларның металогик, символик мәгънәләрен күрәм. Бирегә хәлсезләнеп сүнгән йолдыз да, соңгы нурын түккән Ай да ерак күк җисемнәре генә түгел минем өчен. Бигрәк тә — кызыл диңгез булып җәелгән таң... Бу шигырь юллары мине Дәрдмәнднең «Дәрыйгъ, нур күз яшен бәллүр санды, Кереп әлванга, ал канга буянды...» кебек үтә сюрреалистик сурәтле шигыренә китереп ялгыйлар. Мондый символлар мине әле дә тетрәтеп куялар. Кеше тәненә күк кереп кызыл чыккан хәнҗәр шикелле... Мондый символларга ирешү турында без бүген дә хыялланмыйбызмыни?!

Алда китерелгән шигырь юллары Мостай Кәримнең кан тамырларының яшьтән үк заманасы капиллярлары һәм артерияләре белән бербөтен булуы хакында сөйлиләр һәм аңа, соңрак сугыш кырлары аша үткән, парламентларга күтәрелгән, планета буйлап узган барлык давылларның тузанын иснәгән ил агасына:

Кендегемне кистеләр дә
Җир шарына ялгадылар, —

дип әйтергә бөек нигез булганнар. Үзе турында шундый сүзләр әйтергә һәр кеше дә хокуклы түгелдер, дип уйлыйм мин. Җир шарын фашист афәтеннән коткарганда шәһит киткән совет солдаты турында рус шагыйре Сергей Орлов «Его похоронили в Шар Земной...» дип, хаклы рәвештә язды. Иле өчен сугыш кырларында канын койган, халкы матур уйласын-сөйләсен дип гомере буе шигырьләр, җырлар чыгарган, киләсе буыннар гыйбрәт алсын дип, пьесалар, повесть-хикәяләр язган, аяусыз публицистикасы белән берничә буын сәясәтчеләрне урыннарына утырткан һәм үзен һаман да замана карынында чәбәләнеп яткан кеше («Кеше» шигыре) итеп күргән шагыйрьнең, минемчә, моңа тулы хакы бар! Мостай Кәримнең Җир шары белән ялганган урыны, әлбәттә, туган төбәгендә. Аның бу чордагы югалтулары-сагышлары да авылдашлары, комсомол дуслары, туган як табигатеннән аерылулар, туганнары, әнисе белән бәйле.

Менә Мостай Кәрим минем балаларым яшендә — аңа 30–40 яшьләр чамасы. Бу сугыштан соң илне торгызу еллары. Шагыйрьгә 30 яшь тулган көнне дуслары аңардан «хәтерлә... иң бәхетле көнеңне» дип сорыйлар. Шагыйрь җавап бирә:

...Һәм булды яралы көе
Көрәштә чигенгәннәр,
Фронтташ дус каберенә
Яшьләрем түгелгәннәр.
Булды якын дусымның да
Хыянәт иткән чагы,
Саф эзләремә дошманның
Пычраклар сипкән чагы.

Булды кайгы татыганым,
Булды җәфа күргәнем,
Тик булмады өметсез көн.
Юк бәхетсез көннәрем!

Ул елларда Мостай Кәрим уйларының доминантасы — өмет. Өмет булганда, көн бәхетсез була алмый!.. Ә бүгенге 30–40 яшьтәгеләрнең хәле ничегрәк соң? Алар арасында Әфган, Чечня, Балкан кайнар нокталары аша узганнары күпме! Югары уку йортларын тәмамлап, эшсез йөргәннәре дә аз түгелдер. «Дедовщина» аркасында имгәнеп кайткан ир-егетләребез дә байтак. Алар да бүген социализм «җимергән» илне торгызып, аны капиталистик юлга бастырырга маташалар: газаплананалар, газаплыйлар, сыналар, өметләнәләр... Алар да бүген, Мостай Кәримнең утыз-кырык яшендә язган шигыренә кушылып, «Кайда ул көн? Туган илгә Ант биргән яландамы?..» дип сорарга хаклылар, ләкин сорамыйлар, чөнки әлегә илдә җавап бирерлек кешене күрмиләр.

Бу елларда югалтулар һәм сагышлар сугыш, солдат язмышы, фронтовиклар, ятим калган балалар, өзелгән мәхәббәтләр белән бәйле. Нәкъ шул чорда Мостай Кәрим «Өченче көн тоташ кар ява», «Россиянмын» кебек ил халыклары теленә кергән шигырьләрен, «Мине тагын ташлап китәсең», «Аерылу юк», «Әйтелмәгән сүз» кебек гаҗәеп җылы дистәләгән мәхәббәт шигырьләрен яза, Башкортостан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Югары Советының депутаты, партия съездлары делегаты, РСФСР Югары Советы депутаты булып эшли, үзен аямый, хәтта:

Аусам иде шулчак бәйгеләрдә,
Йөрәге ярылып үлгән ат сымак, —

дип язып, язмышының олылыгын үзе дә таныганлыгын сиздереп куя. Мин бу юлларны сенсацион үлем турындагы шигырь дип кабул итмим. Татарда «үлеп арыдым», «үлеп йокладым», «үлеп сагындым», «үлеп тору» дигән гыйбарәләр бар. Андыйлар башкортта да бардыр. Алар берәр эшнең, хәлнең, гамәлнең иң югары дәрәҗәсен аңлаталар. Бу шигырь — мине ауганчы эшләргә, иҗат итәргә чакыра торган көр күңелле шедевр.

Еллар — җилләр. Шәфкать көтеп булмый
Алар ваемыннан.
Яфрак кебек коела кай исемнәр
Йөрәк каеныннан.
Әллә кояшыбыз саранланып,
Җайлый көзләр җаен?
Бәлки, безгә акыл утырадыр,
Гомер үткән саен, —

дип, Мостай Кәримгә кушылып, уйлана-уйлана, аның шигырьләре белән сөйләшә-сөйләшә, мин китап битләре буйлап алга, үземнең бүгенгемә таба атлыйм. Менә миңа кырык... Кырык биш... Илле... Үз-үземне онытып, фидакарьләрчә дәүләткә эшлим, борыннан кан киткәнче язам... Барлык хисләр дә җете! Мин генә түгел, бөтен ил шулай, чөнки ышанып коммунизм төзибез, чөнки безгә бу дөньяда бар нәрсә дә кирәк. Һәм «Дусыма» шигыреннән йөгереп чыккан замандашым безне хуплый:

Сиңа бик күп нәрсә кирәк җирдә,
Үтә комсыз синең йөрәгең.
...Хәер, сиңа һични кирәкмәсә,
Үзеңнең дә калмас кирәгең.

Без тагы да җилкенебрәк китәбез — Җир шарын, кыш тизрәк үтсен дип, тизрәк, җәй озаграк торсын дип, әкренрәк әйләндерергә тырышабыз, ләкин сизелерлек нәтиҗә күрмибез.

Чөнки бит Җир шары әйләнә,
Җир шары корылган хәйләгә...

Без аптыраш та калдык, тормышны яхшырту хәйләсен-әмәлен һаман да таба алмадык... «Хәзер инде безнең буш хыяллар Ярсып чапмый кәгазь юртакта...» дип уфтана-уфтана, күңелебезгә олы үкенечләр оялаганын да сизми калганбыз... Ә шагыйрь сизгән!

Үкенәм хәзер: салкын иреннәрем
«Янып сөям!» диде берчакны,
Аска карап, тик утырыр җирдә,
Аягүрә басып кул чаптым.

Гомернең бер тәңгәлендә шулай
Ачынып ук «терсәк тешлибез...»
...Кайгы исә бездән сорап килми,
Үкенечләрне үзебез эшлибез.

Шулай икән шул!.. Шундый икән шагыйрьнең югалтулары, сагышлары... Менә Мостай Кәрим минем хәзерге яшемдә. Күп йөрелгән, күп күрелгән, күп эшләр эшләнгән, «Хезмәт кенәгәсе» сандык төбендә, күчермәсе — райсобеста... Күтәрелгән биеклекләр бар, сикәлтәле юллар артта калган, ваемсыз яшәргә дә хак яуланган.

Ыгы-зыгы, вак мәшәкать тәмам,
Бар эшемнең чыктым очына.
Шуңа күрә һәр көн, таңнан алып,
Күкрәгемнән кошлар очырам.

Ул кошлар — чирлеләргә саулык, көткәннәргә өмет, гашыйкларга бәхет, юлдагыларга уңыш китерә торган тылсымлы, ярдәмчел кошлар. Шагыйрь җәмгыятьнең бер генә категориясенә күңел кошларын җибәрми — ул да булса гамьсезләргә, битарафларга, чөнки белә: шулар аркасында халыкның, җәмгыятьнең иң җаваплы мизгелдә иң кирәкле адымын атлап китәргә көч-куәте җитми. Шулар аркасында!.. Шагыйрьнең ак башына авыр уйлар төшә. Ул һаман да борчыла, чөнки ул һаман да заманасы карынында чәбәләнеп ята, чөнки аның кендеге, туган төбәге, халык язмышы аша, яшь чагындагы кебек үк, Җир шарына ялганган.

Китап юллары буйлап әлегә кадәр йөргән дөнья миңа таныш дөнья иде. Алда Мостай Кәримнең әлегә миңа билгесез, минем сиксән җиде яшьлек этиемә, аның яшьтәшләренә генә якынча таныш дөньясы. Җитмеш-сиксәнне узгач, кешениләр уйлый икән, аны ниләр борчый икән дә, ниләр шатландыра икән? Бу бит инде кешенең:

Замананың хаксыз җәзасына
Әллә күнде җаным. Әллә сүнде.
Утларга ла төшеп янар идем,

Мин янарлык утлар да юк инде, —

дип әйтә торган чагы. Ләкин бу яшьләрдә дә шагыйрьне кешегә хас барлык нәрсәләр уйландыра, борчый, шатландыра икән. Сиксәне тулып килгәндә, менә ниләр турында борчыла ул, әнә нинди тарафта аның югалтулары:

Тискәре җил уңай якка үзе
Борылыр дип, күңел юаттык.
Шулчак илдә көе илсез калдык,
Җирдә көе җирне югалттык.

Эштән бизгән кулларыбыз корый,
Уйдан бизгән аңнар кибәләр.
Ялган гына үрчи. Аны безгә
Яңгыр урынына сибәләр...

Ләкин болардан да хәтәррәк борчулары бар бу заманның:

Ут белән су кушылып ага хәзер,
Күк төбенә таулар ишелә.

Әҗәлләрдән курку бетте инде,
Адәмнәрдән куркып яшәлә...

Шуңа да карамастан тормыш алга бара — «октябрьдә йолдызлар төс ташлый», «ширбәт җыеп кайта бал кортлары», «яңгыр явып китә матур гына»... Шагыйрьнең хисләре элеккечә үк җете, чая мәхәббәте һаман исән, чөнки һаман да яу кырында икән әле!.. Мәхәббәт шигырьләренең кайнарлыгы да элеккеге килеш. Шулай булмаса:

Йөрәгем минем тоташкан
Йөрәгең кылларына.
Ялкын белән җавап бирәм
Очкынлы ымнарыңа.

Бары булды. Туңдырдың да,
Дөрләттең дә көйрәттең.
Ялган аваз гына бирмә,
Шартлатырсың йөрәкне, —

дип яза алыр идемени сиксәнен узган кеше! Кыскасы, Мостай Кәрим ирешкән яшькә таба да курыкмыйча, рәхәтләнеп, язмышның күзләренә туры карап атларга була икән!

Менә шулай итеп мин Мостай Кәрим дөньясының шигырь белән түшәлгән сукмакларының берсе буйлап кына йөрдем, бу томдагы поэмаларына, шигъри драмаларына әлегә кермәдем. Бу сукмакта мин җаныма бигрәк тә якын әңгәмәдәш шигырьләр белән дә еш очраштым. Алар — Тукайга, Такташка, Муса Җәлилгә, Хәсән Туфанга, Әхмәт Фәйзигә, Нәкый Исәнбәткә һәм башка татар зыялыларына багышланган шигырьләр. Менә шуларның берсе, Хәсән Туфанга багышланганы:

Сандугачка нигә буй-сын,
Нәрсәгә аңа бизәк?
Таңда бер сайрап җибәрсә,
Биш кат өзелә үзәк.

Шагыйрьгә нигә чин кирәк,
Нәрсәгә аңа титул?
Патшалар ятлап алырлык
Шигырьләр яза бит ул.

Мостай Кәримнең татар халкына, Казанга булган, яшь чагында ук кабынган һәм бүген дә ялкынланган, олы ихтирамын бүгенге сәяси учактан купкан гомерсез очкыннар түгел, әнә шул якты, җылы, ихлас шигырьләр билгели.

Шигъри сукмакның буеннан-буена нур чәчкән яшьлек, яшьләр турында шигырьләр күп, әмма ул чорны сагыну-сагышлану юк. Картлык, дөнья белән хушлашу турындагы уйлар исә сукмакның уртасын узгач күбәяләр һәм аларда борчылу мулрак, ә соңында аларга караш тынычлана, хәтта бераз шаяру төсмере ала, иронигә урана.

Мостай Кәримнең югалту-сагышларына килгәндә, алар һич кенә дә гайре табигый түгелләр икән ич! Аларны безнең күбебез татыган һәм татый... Әмма һәммәбез дә шагыйрь була алмый, ә булганнарыбыз Мостай Кәрим!!! түгел... Димәк, эш югалту белән сагышта гына түгел, эш башкада да... Ә нәрсәдә?

Менә минем Мостай Кәримнең күңел дөньясы буйлап сәяхәтем әлегә тәмам. Хәзер сезгә ишек ачтым, дуслар, керегез, йөрегез, бәхәсләшегез, киңәшегез, минем сорауга да үзегезчә җавап эзләп карагыз...

# Гыйбрәтле дә, кисәтүле дә

Бер әсәр укып кына язучы иҗаты турында сүз куерту, әлбәттә, бик үк җитди эш түгел, гәрчә А.С.Грибоедовның бердәнбер «Горе от ума»сы үзенең авторын да, хәтта рус әдәбиятын да бәяләргә җитди нигез була алган. Ләкин һәр әсәрнең үз язмышы, үз урыны, үз бәһасе. Шуларны да истә тотып, бәя бирүгә дә дәгъва итмичә, хөрмәтле Әмир әфәнде Әминов, мин Сезнең «Кытайгород» дигән повестегызны укып чыкканнан соң туган фикерләрем белән уртаклашмакчы гына булдым... Чөнки уртаклашасым килде! Ә азмыни ул хәзер безнең әдәбиятларда хуплау сүзе дә, хурлау сүзе дә уятмый торган язмалар?!

Повестьның һәрвакыт артта сөйрәлүче «Алга» колхозы турындагы беренче җөмләсе үк миндә профессиональ кызыксыну уятты — шушы ironияле стиль әсәрнең соңына хәтле сакланырмы, урталарда бозылмасмы, озын бәйгедә, кайбер тәҗрибәсез юртаклар сикертеп чабып киткән кебек, тиешле ритмнан чыкмасмы?.. Юк, ритм бозылмады, ироник стиль үзгәрмәде, повестьның форма төгәллеген билгели торган аркау җебе ныклы булып чыкты. Шуның өчен дә әсәрдәге гротеск һәм аллегория югарылыгына күтәрелгән вакыйгалар җитди рәвештә кабул ителделәр, ышандырдылар. Моңа, әлбәттә, әсәрнең төп фикеренә адекват, тәңгәл итеп табылган стиль булышлык итте, чөнки укучының әсәр эчтәлегендәге яшәү рәвешен иң беренче нәүбәттә стиль билгели.

Ләкин «Кытайгород»ның мине җәлеп иткән ягы, билгеле, формада гына түгел, ә эчтәлектә. Телибезме, теләмибезме, Россияне дә глобализация һәм капитализация шаукымы йота бара. Беркайчан да какшамас дип кабул ителгән төшенчәләр үзгәрәләр. Менә инде дәүләтчелегебез, яшәешебез нигезе булган җир-туфрак та товарга әйләнде — сатырга була, алырга була... Ә аны сатучы менә халык түгел, ә халык исеменнән эш йөртергә яратучы, үзләре өчен файдалы законнар чыгаручы чиновниклар. Милләтләр язмышына, милли телләргә, шул исәптән башкорт, татар телләренә дә, олы афәтләр янаганы сизелә. Әнә рус теле булып рус теле дә коточкыч йогынтыларга дучар булды һәм үзенең лексикасын үзгәртә башлады. Россия сәясәтчеләрен демография мәсьәләсендә Кытай, Корея, Вьетнам экспансиясе борчый. Бу проблема, әлбәттә, милли республикаларда да бар, һәм аңа караш, аны хәл итү юллары һәр республикада үзенчә. Мондый мәсьәләләр яныннан, бәлки, кул селтәп кенә узып китү хәерлерәктер? Бер карашка, алар сәяси проблемалар ич! Бәлки, сәяси, икътисади эшләрне сәясәтчеләргә генә тапшыру дөресрәктер, аларны хәл итүне әдәбиятка йөкләү урынсыздыр? Әллә инде ничек бара шулай дәвам итсенме, Ходай гына белгән нәтиҗәгә барып чыксынмы? Әллә инде, берәр төрле җаен табып, карышып караргамы?..

Сезнең «Кытайгород»ыгыз, Әмир әфәнде, укучыда менә шушы һәм шуңа охшаш уйлар уятуы белән дә кызыклы. Әмма әдәби әсәр өчен «уйлар уяту» гына аз әле. Уянган уйларга юнәлеш биргәндә генә әдәби әсәр үзенең төп максатларының берсенә — гыйбрәт дөньясы булуга әверелә һәм Сез үзегезнең повестегызда уңышлы итеп моңа да ирешә алгансыз.

Минем бер шигырем «Галилей хаклы булганда, бөтен башка кешеләр, халыклар, илләр хаксыз булган...» дип башлана. Дөнья әдәбияты, гомумән алганда, аерым кешеләрнең, шәхесләрнең, бик еш булмаса да, төркемнәрнең хаксыз булган чакларын тәнкыйтьләргә ярата. Мондый караш безнең татар, башкорт әдәбиятына да хас. Ә менә җәмгыятьне, халыкны, бигрәк тә милләтне тәнкыйтьләү бик сирәк очрый торган хәл. Мин узып барышлый гына халыкка тибеп үтү, йә булмаса милләткә пычрак атып китү кебек «бравада»ларны беркайчан да җитди эш дип санамадым һәм санамыйм. Халыкңны, милләтеңне тәнкыйтьләү, гомумән, каһкаһәле булырга тиеш түгел. Чит милләт-халыкларны бигрәк тә! Андый эшләр — иң гөнаһлы әхлаксызлык! Сез, Әмир әфәнде, үз җирләрен Кытай бизнесменына сатырга дип стратегик ялгыш карар чыгарган Һыбай халкын хаклы рәвештә гаеплисез. Бу гаепләү беркатлы гына түгел. Һыбай халкын айнытып җибәрү өчен газета мәкаләсе дә җитәр иде. Монда халыкларыбызның «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!»дигән мәкаленә тәңгәл ишарә, киная бар! Һәм ул башкортка да, татарга да, чуваш теленә тәрҗемә ителсә, чувашка да, башка халыкларга да бик ачык аңлашыла. Аңлашылачак һәм дөрес кабул ителәчәк, чөнки повестьтагы «кытай» кытай гына түгел, андагы «Һыбай» бер башкорт авылы гына түгел. Кыскасы, мин монда авторның гражданлык кыюлыгын һәм җаваплылыгын күрәм. Ләкин иң мөһиме — тәнкыйтегез яратудан гыйбарәт булган һәм чын күңелдән эшләнгән гамәл. Әсәрдә мин автор яратмаган бер генә персонажны да очратмадым. Хәтта Һыбай кешеләрен тамырларыннан аерган Кытай бизнесменында да авторның каһәрләвен күрмәдем. Һыбай халкына яхшылык теләп, аларны ялгыш карарга китереп терәгән район, башкала чиновниклары да, шәһәрдәгечә театр-концертлы тормыш турында уйланган яшьләр дә, җылы бәдрәфләр, кранын ачкач ук ага башлый торган кайнар су турында хыялланган, утын кайгыртып тәмам алҗыган картлар да, үз шикләнүләрен халык ярдәме белән җиңәргә тырышучы Фәйзулла карт та, үз җиренең чүгендерчесе генә түгел, ә хуҗабикәсе булып киткән Нәгыймә дә, ике ут арасында калган министр урынбасары да, кытайлылар эшли алганны ник үзебез эшли алмадык икән дигән уйга калган Мансурлар, Белдекләләр дә автор мәхәббәтенә манчылган каләм белән язылганнар. Авторның олы сызлануы, ачыну-хәсрәтләнүе үз авылларын таба алмыйча кайтып баручы халыкның чарасызлыктан, гарьлектән, аяныч хәлләрен үзгәртеп булмаячагын тану ачуыннан башланган аракы мәҗлесен сурәтләгәндә аеруча калку күренә. Шунысын да әйтим: ностальгия (җирсү) моментларын тагы да үзәк өзгечрәк итәр өчен, ә бу исә әсәрнең иң мөһим урыннарының берсе, Сезнең, Әмир әфәнде, шактый мөмкинлекләрегез файдаланмыйча калган кебек күренде миңа. Әсәрне кабатлап басарга әзерләгәндә, йә булмаса тәрҗемәгә биргәндә, бәлки, шуны да истә тотарсыз.

Һыбай халкы, үз җирләрен читләргә сатып, бик нык ялгыша. Ул үзен кисеп бәллүр вазага утыртылган тамырсыз-туфраксыз чәчәк хәленә куя. Халыкка аның ялгышуын, хаталануын әйтү-күрсәтү, әлбәттә, язучының гражданлык кыюлыгы. Халыкны аның җанын рәнҗетмәслек итеп тәнкыйтьләү — язучының иҗади осталыгы. Халыкка аның үз хаталарын һәм казанышларын гыйбрәт итеп күрсәтеп бирү — язучының иҗади

һәм гражданлык позициясе. Сезнең «Кытайгород»ыгыз, Әмир әфәнде, алдагы өч җөмләдә әйтелгән фикерләрне раслаучы җитди әсәр булып чыккан. Милләтләр, милли республикалар дәүләтчелеге, милли телләр һәм мәдәниятләр баш өстендә глобализация һәм тоталитаризмның Дамокл кылычы эленеп торган бер мәлдә халыклар һәм аларның җитәкчеләре өчен гыйбрәт һәм кисәтү булырлык актуаль әсәр язгансыз. Безгә — татарга, башкортка, чувашка, мари, мордва, удмуртка — җиребезне югалту, ул милли җирлегебезне, нигезебезне, ахыр чиктә үзебезне Җир йөзеннән юк итүгә алып бара торган куркыныч проект. Һәм бүген, чыннан да, бик күп дәүләткүләм, республикакүләм, районкүләм проектлар фәкать икътисади йә сәяси табыш һәм файдага карап кына кабул ителәләр. Аларның нәтиҗәсе хакында уйланмыйлар кебек. Бәлки, уйланалардыр да...

*7 ноябрь, 2004*

# Семь молитв Тургая

Издание книг национальных писателей России на русском языке, к великому сожалению, стало такой редкостью, что каждый подобный случай можно назвать явлением в культурной жизни многонационального общества страны. Во всяком случае я так воспринял книгу стихов народного поэта Чувашии Валери Тургая «Ночь-мелодия», изданную недавно Чувашским книжным издательством на русском языке. Все-таки тоска по друг другу, по былым литературным общениям жива еще у нас, жива!..

В связи с этим я хочу высказаться об одной странной тенденции, существовавшей и поныне здравствующей в некоторых национальных республиках, в том числе и в Татарстане, хотя она прямого отношения к Тургаю и не имеет. Она заключается в том, что некоторые широко известные на родном языке писатели начали как-то пренебрежительно относиться к переводу своих произведений на русский и языки народов России: дескать, я служу своей нации, и с меня этого вполне достаточно. В то же время каждый из нас не отказался бы от перевода на английский язык, да вот беда — никто не обращает там на нас внимания... Разрушение института художественного перевода в России в силу экономических, политических, организационных и каких-то еще причин только усугубило эту тенденцию. Однако вновь наступает пора прозревания — многим теперь ясно, что замыкание национальных литератур только на себе приводит писателя к зашоренности, а зашоренность — к скудомыслию, тенденциозности, ограниченности. Поэтому появление любой переводной книги российского писателя я воспринимаю как реальный шаг к разрушению той негодной тенденции и радуюсь. Воистину умные книги принадлежат всем народам, а глупые... Их сейчас — пруд пруди, и не о них разговор.

Ну а теперь — о книге стихотворений чувашского поэта Тургая «Ночь-мелодия». Ее полностью перевел Аристарх Дмитриев непосредственно с чувашского языка и поэтому сумел в основном сохранить краски, «аромат» и «температуру» оригинала.

Эта книга, по сути, — исповедь человека, размеренную, чистую душу которого взбудоражила, возможно, и взбаламутила Перестройка, уже превратившаяся в бесконечную череду нерадостных реформ, породивших социальные потрясения, столкновения между Разумом и Чувством человека, его амбицией и возможностями. Нестабильность жизни общества качнула баланс души человека в сторону агрессивности или апатии, что толкнуло его на опасную черту, за которой может произойти разрушение личности.

Книга Тургая привлекла меня тем, что она заговорила со мной устами человека, который все это остро переживает, который больше любит, чем ненавидит, который вдруг открыл для себя, что люди — «цепочка слез на Лике Божьем», и дал мне секундную возможность ощутить себя одной из этих слезинок, хотя я — мусульманин, а у Аллаха лика нет. И мне захотелось успокоить взбудораженных, приласкать обиженных, сказать каждому человеку такое, от которого он стал бы чище, добрее, терпимее, увереннее, милосерднее, ибо

Как неуютно нынче и темно
На этом равнодушном белом свете!
Но каждый в сердце держит все равно
Хоть каплю сострдаданья на примете...

И эти необходимые капли-слова я нахожу в стихах Тургая. Почти каждого встречного-поперечного, на которого обрушилась вся «прелесть» бессердечных реформ, успокаиваю:

Или тебе одному нынче больно?
Или тебе показалось, что вдруг
Против тебя мир сегодня настроен?
Это ошибка — так думать, мой друг!

Потерпевшему фиаско в любви говорю:
«Так не грусти. Не сиди одиноко.
Сердце стучит? Грудь пылает огнем?
Все хорошо. Выше голову, сокол!
Эта не любит — другую найдем...»

Изрядно нагревшим руки в круговерти нынешних социальных потрясений и на миг задумавшимся о со-

деянном говорю:

Ты немало нагрешил
На крутом пути,
Вновь покаяться решил:
«Господи, прости!..»
Ты опять удаче рад
В жизни и труде.
День за днем бегут назад...
А икона где?..
Позабыл ты к ней и след... —

укоряю я его, одного из творцов и жертв нашей бездуховной жизни. А вот его антипод — вялый, безвольный, омерзительно покорный, не знающий ни любви, ни ненависти, не владеющий ни мечтой, ни надеждой:

Вот породили
и живем
воз Жизни
тащим за собой
коль породили нас...
не спрашивая разрешенья
и с нами не советуясь

*(Орфография автора)*

Но для него и для таких хлюпиков у поэта нет слов, ибо они недостойны ни сострадания, ни утешения. Не слишком ли суров, беспощаден и бескомпромиссен поэт? Может быть, это — очередная ошибка его? Ведь он без утайки говорит:

Я столько натворил ошибок!..
Не раз в обманутых ходил...
Порою был не слишком гибок,
О черном — «белое!» твердил...

Нет, это — позиция поэта, во многом продиктованная периодом бесконечных реформ, это — боль его в отношении тех, кто позволяет обижать, унижать себя, кто не находит сил расправить плечи. В книге есть стихотворение «Вечер. Трое» о деревенских старушках, беседующих о том, что «в стране порядка нету, всюду болтовня», «нынче кто живет вольготно? Жулик, вор и мот. Всю страну растащат скоро. Нужен укорот», «если так пойдет, наконец расправит плечи и простой народ»... И хлюпики, которым жизнь кажется возом, на фоне даже этих старушек достойны и сожаления, и презрения.

Лирический герой книги Тургая живет в мире, где «с двух сторон — две правды», где «снится что попало... После Рая — Ад», где «вожди — по уши во лжи. Не солгать — карьеры не видать», где жизнь представляется Домом сиротским. Однако он не пасует перед ней: «Пока живу я, жизнь все крепче обнимаю... людей я лучше понимаю... врагов все чаще я прощаю... к живым все больше прикипаю», так как все еще верит, «что ночной порою взмывает солнце в высоту... лютою зимою бывают яблони в цвету...». Поэтому ему бесконечно дорог мир живых, общество современников, пытающихся преодолеть ошибки своих вождей и ищущих путь к истине, к счастью. Поэтому он предстает перед алтарем, с мольбой простирая руки.

О Боже!
«Бога нет» — внушали мне...
...О Боже!
Как немного было их
до сей поры,
не говоривших мне,
что Бога нет.
И мать моя — одна из них.
Продли ей век земной,
о Боже!

Во второй своей молитве он обращается к Всевышнему с просьбой хранить дом, где живет его семья — жена с дочерьми: «Отпущенные им страданья Ты на меня переложи. У них ранимы очень души и сумеречно впереди... Храни мой дом всегда, о Боже!»

Третью молитву он посвящает друзьям и спутникам и просит Всевышнего хранить их, ибо они правду говорят в глаза.

Четвертую и наиболее эмоционально насыщенную молитву, молитву со слезами и кровью вперемешку, он относит к своему древнему народу, который давно уж провозглашает имя Божье на своем родном языке, на языке, которому сегодня угрожает исчезновение:

Чем не бездомный пес — Родное Слово:
всяк может камнем запустить.
О Боже правый,

дай ответ:
чем провинился мой народ?
Кого обидел он?
Чьи оборвал надежды?...
И почему же норовят
Народа Слово закопать?
И... заживо притом?..
О Боже!
Сохрани же мой народ!

Пятая молитва — об Отчизне, которая как громадина-корабль, попавшая в окружение льдов, опасно накренилась: «О Боже, не оставь ее! Не дай уйти в пучину вод! Грехов немало у нее. И все же ради всех страданий прости ее и осени надеждой — наполни свежим ветром паруса. Авось, надежду обретя, она себе проложит верный курс».

Шестая молитва — о Земле, о ее обитателях, непрестанно играющих с огнем: «О Боже! Образумь людей! И отведи смертельный пламень как от Земли, так и от нас, о Боже!»

Последняя молитва — о любви, без которой люди — увядшие побеги, засохшие колодцы, обломанные крылья...

Мы без Любви —
остывший серый пепел...

Так обрати
ЛЮБОВЬ
в священный дух на свете,
о Боже!

Молитв, разумеется, может быть бесконечное множество, так как причин и позывов молиться также не счесть. Однако душа поэта выбрала именно эти молитвы. Конечно, они актуальны для каждого из нас. Но сочетание и совокупность именно этих семи молитв — семи вечных и всеобщих ценностей — делают лирического героя Тургая своеобразным, неповторимым и привлекательным.

Книга «Ночь-мелодия» богата и на лирику. На ее страницах читателя ожидают и страстные любовные стихи, и раздумья о смысле жизни, смерти, дружбы. Большое внимание уделяется размышлениям о духовности и бездуховности. Есть и строки, которые удивляют своей необычностью, например, такие:

Когда запрещают слова —
запрещают детей

когда запрещают слова —
не могут
явиться
Боги

*(Орфография автора).*

Но примечательно то, что все стихи книги «Ночь-мелодия», разнообразные по тематике, стилю, накалу страстей, форме (иногда грешащей модничанием), подтверждают цельность как лирического героя, так и души замечательного чувашского поэта Валери Тургая.

# Юл эзләгәндә

Менә инде ике дистәдән артык ел дәвамында җәмгыять үзгәрешләр чорында яши. Кичә генә аксиома булып кабул ителә торган рухи кыйммәтләр бүген инде кискен бәхәсләр кузгата, кичә генә телдән төшмәгән әсәрләрне, исемнәрне башкалары — әлегәчә күләгәдәрәк торганнары алыштыра. Юкны бушка авыштыру гына түгелме бу? Әллә алгарышмы? Кеше күңеле көтмәгәндә рәшәткәләре эреп юкка чыккан читлек кошы хәлендә — кинәт килгән ирек аңа кыйбласызлык, ихтыярсызлык, максатсызлык булып яный...

Язучы, әдәбият галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Фоат Галимуллинга нәкъ менә шушы кызыклы һәм кызганыч, өметле һәм аяныч елларда, иске гасыр яңа гасырга, үткән меңьеллык килгән меңьеллыкка эстафета тапшырган дәвердә татар әдәби хәрәкәтенең башында торырга һәм аптырашта калган татар иҗтимагый аңына юл-юнәлеш эзләшергә туры килде. Аның безнең кулдагы китабы, минемчә, әле озакка сузылачак эзләнү-эзләшүләрнең бер этабы, бер вакытлыча тукталышы гына.

Китапта иң күренекле урынны, әлбәттә, әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм әдәбият белеме материаллары алып тора. Әдәбияттагы һәр яңалыкны, барлыкка килгән һәр тенденцияне йә булмаса юкка чыккан, төсен югалта башлаган һәр хасиятне тәнкыйть жанры күрә, барлый, нәтиҗә ясый, һәм, шулай итеп, иҗтимагый аңны тәрбияләүдә, җәмгыятькә әхлакый, эстетик юнәлеш бирүдә иң үтемле рухи көчкә әверелә. Бу — идеалда шулай. Ә бүгенге чынбарлык исә әлеге көчкә ихтыяҗның сүнеп, үлем хәленә якынлашып баруын күрсәтә. Бу чир белән килешергәме, әллә, диагноз куеп, аңардан котылу юллары эзләргәме? Шушы чорда Фоат Галимуллин, тәнкыйтьче буларак та, галим буларак та эшчәнлеген киметмәгән, әдәби әсәр һәм укучы күңеле арасында ышанычлы арадашчы булган, әдәбиятыбызның сафлыгы, саулыгы сагында торган. Фоат Галимуллин-

ның фәнни хезмәтләренең һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләренең бу еллардагы үзенчәлеге, минем карашка, бүгенге көндә дә үзен сиздерә килгән вульгар социалогизм калдыкларыннан татар әдәбияты фәнен һәм белемен тәмам арындырып бетерүдер. Әлеге «калдыклар» нәрсәдән гыйбарәт соң? Әгәр дә үткән гасырның вульгар социалогистлары үзләренә кадәр иҗат иткән бөек әдипләрне, фәкать сыйнфый күзлектән карап, хаким сыйныф вәкилләре ярлыгы тагып, әдәбият арбасыннан төшереп калдырырга тырышсалар, бүгенгеләре исә чорыбызның күренекле язучыларына коммунистик режим тарафдарлары дигән ярлык тага башладылар һәм аларны чор арбасыннан төртеп төшерергә теләделәр. Фоат Галимуллин бер ярдан икенчесенә үзе дә сугылып йөрми, әдәби әсәрләрне бәяләгәндә дә иң ышанычлы булган югары әхлаклылык, гүзәллек, тел һәм форма камиллеге, тирән мәгънәлелек принципларына таянып эш итә. Социалистик реализм дигән иҗат методына типкәләп китү модага әверелгән бер чорда Фоат әфәнденең, язучы, әдәбият галиме, әдәби хәрәкәт башында торучы кеше буларак, ныклы принципта калуы, әлбәттә, игътибарга лаеклы. Бигрәк тә рухи юл эзләүләр чорында!

Китапта авторның публицистик һәм җәмәгать эшчәнлеген чагылдырган мәкаләләре, интервьюлары һәм башка язмалары да урын алган. Аларда да заманабызның киеренке сулышы, актуаль проблемалары. Фоат Галимуллин бу мәкаләләрендә бәрелә-сугыла базар мөнәсәбәтләренә кереп баручы җәмгыятьтә иҗат оешмаларының эше турында да, иҗатчы һәм дәүләт, иҗатчы һәм халык, иҗат һәм икътисад кебек катлаулы проблемалар турында да галимгә хас үҗәтлек, җәмәгать эшлеклесенә хас җаваплылык, язучыга хас ихласлылык белән фикер йөртә. Татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән хәзерге мөнәсәбәте дә, татар менталитетында «евразиялек», шәркыйлек микъдары да, халкыбызның бөек шәхесләре һәм үзебезне цивилизацияле милләт итеп танытуда аларны файдалана белү дә, мәктәпләрдә, югары уку йортларында әдәбиятны укыту мәсьәләләре дә, бүгенге интеллигенциябезнең тел, сөйләм культурасы да авторның игътибар үзәгендә. Төрле әдәби чараларда, бәйрәмнәр һәм юбилейларда топкан нотыклары да миңа гыйбрәтле булып тоелды: аларда тешкә тия торган төчеләнү, чырай сыттыра торган купшылык юк, аларда Фоат әфәнденең барлык мәкаләләренә хас җитдилек һәм нәсергә хас форма төгәллеге. Алар бербөтен эсселар һәм тулы канлы мөстәкыйль әдәби әсәрләр булып яшәргә хаклылар.

Бай фактик материал туплаган, аналитик акыл һәм хисле каләм белән язылган китапка кереш мәкалә кысаларында гына тулылыкка дәгъва итә торган бәя дә, характеристика да биреп булмый. Мин үз алдыма андый максат та куймадым. Шунысын гына әйтим: әлеге тупламны чорыбыз елъязмасының Фоат Галимуллин сүзе һәм хисе белән беркетеп калдырылган җитди һәм кызыклы бер бүлеге дип тә кабул итәргә була. Андагы мәкаләләр бүгенге буынга да, киләчәктә үсеп чыгачак тикшеренүчеләргә дә безнең заман әдәби хәрәкәте, иҗат атмосферасы хакында шактый бай мәгълүмат бирерләр дип уйлыйм.

*Апрель, 2005*

## Истәлекләр

# Гади кеше

*(Ибраһим Гази)*

Ибраһим абый «Яшь ленинчы»* газетасы редакциясенә еш кереп йөри. Аңа без почтабызда булган кызыклы хатларны укытабыз. Хатлар Ибраһим абыйга үзенең малай чакларын исенә төшерә һәм ул хәтерендә яктырган кайбер хәлләрне безгә дә сөйли. Сөйләп бетергәч, без аңардан: «Ибраһим абый, шушы сөйләгәннәрегезне язып бирегезче», — дип үтенә башлыйбыз. Бер сөйләгәнне язу артык читен эш түгел кебек бит инде һәм язучының «Ярар, һичшиксез, һичшиксез!..» дип әйтүен өмет итәбез. Ә ул: «Вәгъдә бирмим, үтәп булмаса, бик яман була», — ди. Шуннан соң, атналар, айлар үткәч, редакция өстәленә «Сиртмә койрык», «Ак сирень» хикәяләре килеп керә.

— Менә, китердем, — ди Ибраһим абый, — теге чакта, сезгә сөйләп, мин аларны сынап караган идем...

Аннары күзлеген сала да, пыяласын иске газета кисәге белән сөртә башлый. «Типография буявы пыяланы бик яхшы чистарта — сезгә дә тәкъдим итәм», — ди. (Редакциябез күзлеклеләре шуннан бирле Ибраһим абый киңәшен тоталар һәм: «Чыннан да шәп икән!» — диләр.)

Ибраһим абый күзлеген кия дә тәрәзә аша әллә кая еракка карый. Бүлмәнең тәрәзәсе зур, өлгеләре дә бик күп. Бер өлгенең пыяласы чатнады да без аны вакытлыча гына тар кәгазь тасма белән ябыштырып куйган идек. Аркылы-торкылы рамнарга һәм кәгазь тасмага карап, Ибраһим абый: «Тәрәзәгез сугыш вакытындагы кебек икән...» — дип куйды. Аннары Казаннан Сталинградка, Сталинградтан Ростовка, Кырым, Карпат, Белоруссияләр аша Берлинга илткән юлда күргән-тойганнарын сөйләп китте. Әкрен генә, салмак кына, бер карасаң, тонык кына сөйләп, Ибраһим абый безне әллә нинди киеренке, дәһшәтле вакыйгалар эченә алып керде. Без, сугышны китаптан гына укып белүчеләр, үзебезне сугыш кырында итеп хис иттек. Бүлмәдә көлү дә, шаулашу да юк... Менә шушы урында Пират исемле этнең ничек фашист самолетларын тануын, аның ничек бер песи малае белән дус булуын, аларның ничек итеп Ибраһим абыйга ияләшүләрен сөйлисе иде дә бит — ярамый, бәлки, ул язылачак тагын бер хикәясен сынап карагандыр, бәлки, ул хикәя, тиздән язылып, газетабыз битләрендә басылып та чыгар. Минем сөйләү һичничек тә язучы тасвирын алыштыра алмас шул. Аны уку «Канатланыр чак», «Ак сирень», «Сиртмә койрык»ны һәм Ибраһим Газиның һәр әсәрен уку кебек үк мавыктыргыч, гыйбрәтле булыр. Аннары, безне киеренкелектән арындырырга теләп булса кирәк, ул үзенең ки-

ез итек табанына ничек итеп такталар бәйләп, июнь аена кадәр бүрек киеп, фронтлар буйлап йөргәннәрен сөйләде. Ул сугышка доброволец булып киткән һәм «Кызыл Армия» дигән татарча фронт газетасында эшләгән. Без аның маҗараларын тыңлап көлешәбез, безгә кызык, ә Ибраһим абый күңелендә сугыш хатирәләре дәвам итә булса кирәк. Ул Польшада күргән бер вакыйганы сөйли. 7–8 яшьлек биш-алты малай шартламыйча калган снаряд белән уйныйлар икән. Шунда снаряд шартлый һәм малайларны... Кыскасы, төтен, тузан таралганда алардан бернәрсә дә калмый. Бу вакыйга, күрәсең, Ибраһим абыйны кабат үзенең малай чагына кертеп җибәрде.

— Мин дә унөч яшемә дә җитмичә үләсе кеше идем бит, — диде ул. — Тик бу поляк малайлары кебек түгел, ә озак һәм газаплы үлем белән — ачлыктан, ялангачлыктан...

Революциягә кадәр һәм аннан соңгы елларда Ибраһим абыйга теләнеп йөрергә туры килгән. «Теләнеп» сүзен ул пышылдап кына, үтә уңайсызланып кына әйтә — кычкырыбрак әйтсә, күптән үлгән бу сүзнең әйтерсең лә яңадан терелүеннән курка. Олысына, кечесенә фәкать иминлек, исәнлек, шатлык теләгән язучы, күрәсең, бу шыксыз сүзнең безнең телебездә, тормышыбызда тагын да кабатланмавын тели...

— Беләсезме, шул вакытлардан минем күңелемә бер курку урнашып калды — этләрдән курку. Капка шакылдаткан саен, мине усал этләр каршы ала иде... Хәзер дә этләрдән куркам мин. Хатыным да моны белә. Икәү урамнан барганда эт очраса, хатыным эт ягына чыга. Джентельменнарча түгел инде түгелен — нишлисең бит...

Ибраһим абый елмаеп куя. Елмаюында уңайсызлану...

— Ярый әле революция булды да, ярый әле Балалар йортына эләктем, ярый әле ул Йорт миңа белем алырга ярдәм итте, юкса гомерем буе, бәлки, капка шакылдатырга туры килер иде.

Ибраһим абый сәгатенә карап ала. Без дә карыйбыз — төшке аш вакыты үтеп бара. «Кайтып эшкә тотынырга вакыт җитеп килә», — ди ул һәм пальтосына үрелә. (Ибраһим Газиның бик сирәк очракта гына бозыла торган көн тәртибе бар. Ул вакытында эшли, вакытында ял итә, саф һава сулый, кешеләр белән аралаша.) Кара көрән якасына ак җеп ияргән икән. Ул аны алды да, идәнгә ташламыйча, кәгазь кәрзиненә очырды. «Малай чакка тагын бер матур сәяхәт булды әле бу», — дип чыгып китә.

Ул китте, ә «сәяхәт» язучы тирәсендә һаман дәвам итте. Аның күзәтүчәнлеге турында да, дөнья әдәбиятын шәп белүе хакында, язучылар арасындагы абруе турында да озак сөйләштек. Кемдер аның бөек рус рәссамы Врубель турында сөйләгәннәрен, «Пан», «Царевна-Лебедь», «Демон» картиналарын сынлы сәнгать белгечләренчә аңлатуын искә төшерде. Беребез: «Гади дә инде бу Ибраһим абый!» — дип сокланды. Икенчебез аның кызыклыгы, матур итеп сөйли белүе хакында сүз әйтте. Өченчебез: «Ул бер дә «Онытылмас еллар» авторына охшамаган», — дип куйды. Кемдер аны бер генә сүз белән бәяләде: «Кеше». Кемдер аңа үз өстәмәсен бирде: «Гади Кеше».

*1966*

# «Кончить жизнь со знаком плюс»

*(Памяти поэта Михаила Львова)*

Когда на страницах газет и журналов я вдруг вижу стихи своих любимых поэтов, другие материалы как бы исчезают с поля зрения, становятся невидимыми для меня. То же самое случилось, когда я открыл последний, пятый, номер Литгазеты, увидел стихи Михаила Львова и стал читать:

Мне б кончить жизнь
со знаком плюс...
Покамест
нет мне угомону —
Проснусь —
живым — и тороплюсь
обнять вас —
хоть по телефону.

И только дочитав это стихотворение, я увидел имя Поэта в траурной рамке... Поэт Михаил Давыдович Львов умер. Рус-ская литература потеряла большого писателя, татарский народ потерял одного из своих талантливейших сынов.

Только в прошлом году мы радостно отправляли ему в Москву поздравительные телеграммы по случаю 70-летия со дня рождения, а сегодня с печалью оживляем в памяти все многочисленные встречи, интересные разговоры с этим неимоверно бескорыстным, светлым, теплым, жизнерадостным человеком и поэтом, «коронованным тюбетейкой Тукая» и «от счастья сочиняющим песни на великом русском языке». Много труда вложил он в перевод многовековой татарской поэзии на русский язык — первая антология татарской поэзии на русском языке хранит и организаторскую энергию, и творческий вклад Михаила Давыдовича в это благородное дело.

Одним из основных свойств души Михаила Давыдовича, на мой взгляд, было неудержимое стремление помочь другим и стихами, и конкретным делом. Потому он всегда был весь в заботах, потому у него было

очень много друзей и среди ровесников-фронтовиков, и среди молодого поколения.

Мы, татарские писатели, к нему почти всегда обращались по имени — Рафкат ага, и это ему очень нравилось. Имя, данное родителями, наверное, было для него как бы магическим «включателем» детства, а для взрослого человека, да притом поэта, что может быть сладостнее, чем воспоминания об этой всегда прекрасной поре?! А детство Михаила Давыдовича было тяжелое, сиротское, молодость была отдана войне, а вся жизнь — поэзии и друзьям.

Если попытаться определить основное свойство искрометной, энергичной, очень биографичной поэзии Михаила Львова, то, на мой взгляд, в первую очередь нужно отметить ее искреннюю оптимистичность. Пусть кое-кто пытается утверждать, что стихи от радости не пишутся, а Михаил Давыдович свои лучшие стихи и поэмы писал от счастья: от счастья победы, встречи с друзьями, нахлынувшей любви, от счастья, что «на лучшей Родине рожден». А в трудные мгновения жизни он писал с верой в счастье:

Да, я верю в удачу и в счастье,
Верю в честные в жизни пути,
В проходящий характер ненастья
И в возможность до цели дойти.
Несмотря на нередкие беды
В сложной жизни живого певца,
В окончательность верю победы,
В несдаваемость сердца бойца.
Верю в то, что за все я в ответе,
И порой — к окончанию дня —
Верю: где-то кому-то на свете
Невозможно дышать без меня.

*3 февраля, 1988*

# Тавышсыз җыр

*(Мөхәммәт Мәһдиев)*

Минем өчен, әйтик, АКШ вице-президенты, йә булмаса Венгрия президенты, Франция, Төркия премьер-министрлары турында истәлек язу артык авыр булмас иде, чөнки аларны гомеремдә бер генә тапкыр күрдем. Бер күргән берегебрәк кала икән ул! Дөрес, күргәнең күренекле булганда... Ә менә тарихтагы, кеше күңелендәге эзләре премьер-министрларныкыннан кимрәк булмаган язучылар, галимнәр, рәссамнар, композиторлар, башка һөнәр ияләре белән, еллар үткәч бөек дип бәһаләнәчәк кешеләр белән көн саен очрашып яшәгәндә, эш башкачарак: сөйләшкән сүзләр дә, кигән киемнәр дә, бергә ашаган ризык та, көннәр-айлар-сәгатьләр дә хәтергә тонык булып сеңеп кала. Көндәлек хәлләргә игътибар җитми шул, җитми...

Без Мөхәммәт абый Мәһдиев белән шактый гомер аралашып яшәдек. Ничә еллар дәвамында һәр яз саен Тукай-Кырлайга барулар, төрле мәҗлесләрдә табындаш булулар, җыелышларда, Мәскәүдә узган язучылар съездларында катнашулар. «Казан утлары», «Татарстан хәбәрләре», «Яшь ленинчы» редакцияләрендә очрашулар, аның йә минем басылып чыккан әсәрләребез турында фикер уртаклашулар, нефть якларына, Чаллыга, Түбән Камага, илнең ераграк төбәкләренә бергә сәяхәт кылулар... Болар барысы да булган хәлләр. Әмма алардан хәтергә уелып калган эзләрне истәлек итеп тергезү алда әйткән сәбәпләр аркасында бик үк җиңел эш түгел...

Мөхәммәт абыйның хәтере әйбәт иде, һәм ул ике-өч елга бер җаен китереп, Әлмәт якларында булган бер сөйләшүне искә төшерә иде. Ул нефть суырта торган «торна»ның, ягъни насосның, уннарча еллар бертуктамый эшләгәнен күреп, бу безнең әниләр кебек икән, дигән иде. Мин аңа «сат бу табышыңны, мин, шул күзәтүне кулланып, әниләр турында шигырь язармын» дигәнмен. Ул миңа «яз гына, бушлай бирәм» дигән булган. Мөхәммәт абый миннән егерме еллар әнә шул шигырьне көтеп йөргән, ә мин, вәгъдәсез, язмаганмын.

Дөрес, булган хәл. Шул күзәтүдән файдаланып шигырь язмавым өчен Мөхәммәт абыйның рухы алдында гафу үтенергә генә кала. Нишлисең бит, минем дә үз принципларым бар — нинди генә сокландыргыч, кызыктыргыч булмасын, башка язучылар тапкан, тотып алган шигъри детальләрне, күзәтүләрне, чагыштыруларны үземнең әсәрләремә үземнеке итеп кертмәскә. Әлбәттә, эпиграф итеп алырга, йә булмаса авторын күрсәтеп файдаланырга бик мөмкин.

Мөхәммәт абыйның кунакчыл, тыйнак өендә дә берничә тапкыр булырга туры килде. Ул Казан университетында укытканда алган Галиев урамындагы квартирасында бик озак яшәде. Тукай премиясе лауреаты, халык язучысы дигән исемнәргә лаек булгач кына Чехов урамындагы «түрәләрский» (үзе шулай дип әйтә торган иде) өйгә күчте. Ләкин анда озак яши алмады...

Алар өенә беренче тапкыр керүем бер егерме биш, егерме җиде еллар элек булгандыр. Шунысы ныграк истә калган. Беренче тапкыр булгангадыр инде... Мин ул вакытларда Язучылар союзы идарәсендә җаваплы сәркатип идем. Язучылар союзы Бауман урамындагы Матбугат йортының икенче этажында иде әле. Проза секциясеме, шигырь секциясеме утырышыннан соң без, бер төркем яшьрәкләр, күрәсең, богема йогынтысына бирелепме, бәхәсләрне «суыныбрак» дәвам итәр өченме, Матбугат йорты каршындагы «Елочка» дигән мороженое кафесына кереп киттек. Арабызда Мөхәммәт абый да бар иде. Кафеда, билгеле, мороженое ашап

салкын тидертмәс өчен ликер, коньяк, коры шәраб кебек төрле җылыткычлар да саталар иде. Шагыйрь Нәби ага Дәүлинең, минемчә, матбугатта күренмәгән бер эпиграммасы бу ханәгә бик төгәл бәя бирә:

Матбугат йорты каршында
«Елочка» дигән йорт бар.
Үзе кечкенә булса да,
Матбугат йортын йоткан...

Менә шул кафеда бераз «йотылып» утырганнан соң, безне Мөхәммәт абый үзләренә алып китте. Сәбәп: ул үз сүзләрен дәлилләр өчен нииндидер кульязмалар, нииндидер китаплар күрсәтергә теләде. Һәм без аның өенә ике таксида барып төштек. Без дигәннән, хәтерем ялгышмаса, Фәрваз Миңнуллин, Рәдиф Гатауллин, Рөстәм Мингалимов һәм тагын кемнәрдер бар иде. Ул торгынлык елларында ни өчендер таксилар күп һәм таксофоннар да пассажирга карата шактый ихтирамлы, мәрхәмәтле иде.

Фәнни бәхәсне без ул көнне бик тиз тоттык. Эштән Мөхәммәт абыйның хатыны Лилия апа кайтты. Кунакларга рәтле өстәл дә әзерләмәгәнсең, дип, ирен битәрли-битәрли, ул тиз генә табын корып җибәрде... Кыскасы, мәҗлес башланып китте. Һәм мин шунда беренче тапкыр Мөхәммәт абыйның җырлавын ишеттем. Без гармунсыз-нисез генә берничә халык җыры җырлаганнан соң, Фәрваз бугай, әйдә, Мәһди, үзеңнең теге Гайнавалыңны сузып җибәр әле, диде. Мөхәммәт абый, артык кыстатып тормастан, тамагын кыргалап куйды.

— Дөрес, егетләр, бу җыр «Ташкыннар» драмасыннан Гайнавал җыры, ну аның сүзләре Таҗи Гыйззәтнеке булмаска тиеш. Әнә карагыз Батырҗан ариясен, йә булмаса теге «Өмә җырын», башка җырларын исегезгә төшерегез... Сәйдәш язганын да, башка композиторларныкын да... Гайнавал җыры халыкчанлыгы белән аерылып тора. Менә игътибар итегез әле, — дип, ул җырлап җибәрде:

Телеграмм баганасын
Саныйсым калган икән.
Күз керфекләрем талганчы,
Карыйсым калган икән.

— Сиздегезме? — ул халык җыры. Аның исеме — «Телеграмм баганасы» булырга тиеш. Мөхәммәт абыйның тавышы ул вакытта да, соңгы елларда да көр иде. Баска якын баритон белән ул салмак итеп, җырлаган һәр сүзен мәгънәви хис белән сугарып, тамагы авазын җаны белән тыңлап җырлый иде. Аһ, шушы сәләт кайбер профессиональ артистларда да булса икән! Башкаручылар бик күп, ә җырчылар бармак белән генә санарлык. Башкаручы булыр өчен көчле тавыш (хәзер исә яхшы микрофон) һәм махсус белем дә җитә, ә җырчы өчен болар гына аз. Чын мәгънәсендә Җырчы булыр өчен, башкару осталыгына күңел байлыгы, югары культура, кешелеклелек сәләте дә өстәргә кирәк. Ә Мөхәммәт абый, сәхнәләргә чыкмаса да,, җырчы иде... Ул җырның нечкә күңел белән генә тоеп була торган эчкәреге серләрен яхшы белә иде һәм шул серләрдән үзенең роман, повестьларын, хәтта публицистик йә тәнкыйть мәкаләләрен язганда да бик оста файдалана иде. Аны әсәрләренең укучы күңеленә нык тәэсир итү көчен кайберәүләр оста тотып алынган тормыш детальләре, бизәкле, җор телле булуы белән аңлаталар. Алар да хаклы, әлбәттә. Әмма Мәһдиев әсәрләренең төп үзенчәлекләреннән берсе булган җылы, бераз моңсу лиризм — җырлардан. Повесть, хикәяләрендәге кайбер абзацлар, хәтта бүлекләр дә, гаҗәеп рәвештә киңәйтелгән җыр куплетларын хәтерләтәләр. Аларның хәтта үз көйләре дә бар кебек. Ишетә белергә генә кирәк. Мөхәммәт абыйның китапларын яңадан укый башлау белән, миңа әллә кайдан еракта төрле көйләр ишетелә башлый. Еш кына шуның берсе башкаларын басып китә, үзенең тибрәнүенә мине дә суырып кертә. Үзем аның китабын укыйм, үзем әкрен генә, эчтән генә, тавышсыз гына җырлап җибәрәм:

...Сагынасыңмы дип сорыйсың,
Сагынмаган кая ул...

*8–9 март, 1996*

# Хәсән Туфанның җылы кулы

«Гаҗәеп фотогеничный кеше инде Хәсән Туфан!..» Бу сүзләр Бакый ага Урмаченыкы. Дистәләгән персонажлы фотосурәттә Хәсән ага булса, күз карашы иң әүвәл аңа барып төртелә. Аның ач яңаклы озынча йөзендә, чекерәеп елтыраган күзләрендә, йә буранны, йә язгы ташкынны хәтерләткән чал чәчләрендә нииндидер тылсым бар. Бу тылсымны мин шигърият дип атар идем. Әгәр дә шул ук фотосурәттә бер шагыйрь дә бар дисәләр, минем уемча, һәркем Хәсән Туфанны күрсәтер иде... Бик күп күренекле танышларымның төс-битләре күземнең хәтерендә инде тоныклана башлады, ә Хәсән аганың портретына вакыт янгырлары тимәгән...

Мин гомер буе күңелемнән Хәсән ага Туфан белән бәхәсләшеп яшәдем. Җитмешенче еллар башында булса кирәк, «Татарстан яшьләре» газетасында аның «Юкны эзләмәскә, барны үстерергә» дигән мәкаләсе басылып чыкты. Бу мәкаләсендә Хәсән ага алтмышынчы елларда татар әдәбиятына килгән шагыйрьләрнең иҗаты турында сүз алып бара һәм мәкаләнең исеменә әверелгән нәтиҗә ясый. Ә без ул вакытта татар шигъриятенең сугыштан соңгы хәлен, яшьләргә хас булганча, кистереп, шактый түбән бәяли идек. Ул елларда рус шигъриятендә Евтушенко, Вознесенский, Рождественский, Белла Ахмадуллиналар исеме белән бәйле гаҗәеп көчле күтәрелеш бара иде. Рус поэзиясе эстрадаларга, стадионнарга ташып чыкты, аның сәяси җегәре Маяковскийлардан мирас булып калган традицияләргә барып тоташты һәм иҗтимагый-эстетик көчкә әве-

релде. Шигъри форманың төрлелеге, интонацияләр байлыгы, публицистика белән шигърилек симбиозыннан туган заманчалык, әлбәттә, һәрвакыт яңалыкка омтылган татар шагыйрьләренең күңелләрен бик тиз яулап алды. Рус поэзиясе белән чагыштырып караганда безнекенең «җитешсезлекләре» бик күп булып күренде.

Нәкъ шул елларда ул вакытта Мәскәүнең М.Горький исемендәге әдәбият институтында укытучы шагыйрь Шамил Анак Казанга кайтып йөри башлады. Аның белән бергә татар шигъриятенә Европа верлибры (ирекле шигырь) һәм әдәбият, татар шигыре хакында укымышлы бәхәсләр кайтты. Кайберләребез бу алымны татарча җигә башлады һәм матур-матур уңышларга да иреште. Бигрәк тә Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов һәм Рәдиф Гатауллин.

1970 елның 4 декабрендә Татарстан язучылар союзы идарәсендә шигырь секциясенең утырышы булды. Ул вакытта Язучылар союзы Бауман урамындагы Матбугат йортында иде, ә секция җитәкчесе Марс Шабай. Утырышны да ул алып барды. Әле күптән түгел генә Рәдифнең «Күңел ташлары» дигән китабы чыккан иде һәм без, яшьләр, аны куанып каршы алдык. Күзен арыш кырларыннан аерып, йолдызлар арасына, яңа дөньяларга, яңа рухи биеклеккә омтылган замандашның хисләре безнең күңелләргә хуш килгән иде. Ә Хәсән агага Рәдифнең яңа китабы ошамаган икән. Дөрес, сүзне үзенә хас салмаклык белән Сибгат ага Хәким башлап җибәрде.

— Рәдифнең беренче китабын укып, мин шагыйрь килә дип куанган идем. Матур образларга, төгәл детальләргә бай иде ул китап. «Күңел ташлары»... бераз... абстрактрак булып тоелды... Яшьләрнең һәр яңа китабы турында секцияләрдә сөйләшергә кирәк...

Хәсән ага сүз алды. Һәрвакыттагыча дулкынланып, үз сулышыннан йотлыга-йотлыга, турыдан ярды:

— Рәдифне коткарырга кирәк... Китап шигырьләре язу — Рәдифнең шагыйрь буларак үлеме ул... Башына сугып, якасыннан алып, бик нык бер селкеп, егетне акылына утыртырга кирәк...

Дипломатия саклауны Хәсән ага бу юлы да кирәк дип санамады. Бу юлы да дип шуңа әйтәм — мин берничә мәртәбә Язучылар союзы китапханәсендә Хәсән Туфанның Шамил Анак белән сөйләшкән-бәхәсләшкәнен тыңлап тордым. Хәсән ага шигырь теориясе белән җитди һәм ныклап шөгыльләнә иде булса кирәк, ә Анак аны тирәнтен белә. Безнең буын шагыйрьләре дә бу мәсьәләдә төшеп калганнардан түгелләр иде.

— Син, Шамилкай энем, модачы, экспериментчы... Сезнең буын, гомумән, ялгыш юлдан, формализм юлыннан бара... Без үттек инде аны, Маяковскийларга ияреп. Менә мин яңадан гасырлар буе чарланган классикага кайттым. Син дә кайтачаксың... Иртәме, соңмы... Ташла бүген үк татар теленә ят, килешмәгән бу экспериментларыңны, бозып йөрмә яшьләрне...

Мондый минутларда Хәсән аганың бит очларына алсулык йөгерә, күзләре очкынлана, тынгысыз алгы чәчләре җыерчыклы маңгаена ишелеп төшә, мишәр акценты тагы да көчәя... Ул тагы да матураеп китә. Бакый ага Урманченың югарыда китерелгән сүзләре, мөгаен, шагыйрьнең нәкъ менә шундый чагын күргәч туган сүзләрдер. Рәссамның әйтүенчә, Хәсән Туфан аның белән дә бәхәсле сөйләшүләр алып барырга яраткан, ләкин миңа, ни кызганыч, андый очрашуларның шаһиты булырга туры килмәде.

Шигырь секциясендә Рәдифкә дип әйткән сүзләр, әлбәттә, бер Рәдифкә генә юнәлтелмәгәннәр иде. Әлбәттә, алар татар шигъриятен кайгыртып, татар әдәбиятын модага бирелүдән саклап калырга тырышып әйтелгән сүзләр. Ләкин мода гына булды микән соң безнең ул еллардагы эшчәнлегебез? Бу сорауга җентекле җавапны әдәбият белгечләре, галимнәр бирделәр инде. Шул елларның матур эзе татар шигъриятен яңа формалар белән генә түгел, яңа интонацияләр, сурәтләү чаралары, яңа темалар белән дә баетты. Татар шигыренә урбанизм дулкыны бәреп керде һәм шигъриятебезнең башка хасиятләрен кысрыкламыйча, үзенең әйтерсең лә алдан әзерләп куйган урынын алды. Ә иң мөһиме — шагыйрь җаныннан кайбер идеологик тышаулар алып ташланды, шагыйрь үзен иреклерәк тоя, иркенрәк тота башлады...

Ә күренекле шагыйрь Рәдиф Гатауллинга карата ул чакларда әйтелгән киңәшләре ни дәрәҗәдә актуаль һәм урынлы булган? Бу сорауларга җавапны әдәбият белгечләреннән ишетү кызыклы булыр иде, чөнки бик күп вакытлар узды, шагыйрьнең яңа китаплары чыкты, яңа иҗади мавыгулары ачыкланды... Миңа калса, Рәдиф Гатауллинның иҗаты хаксыз рәвештә әдәби тәнкыйть игътибарыннан төшеп бара...

Хәсән ага Туфан иртә яздан кара көзгә чаклы язучыларның Аккош күле дигән иҗат йортында, дөресрәге, иҗат бакчасында яши иде. Соңгы елларындагы күп әсәрләре аның Кече тирән күл буендагы шушы бакчада язылды. Бакча уртасындагы беседкада көзләрен «авыл хуҗалыгы күргәзмәләре» булып, анда һәр язучы гаиләсе түтәлендә үстергән яшелчәсе белән катнаша. Кемнәрдер кабак, кишер, чөгендер, кәбестә куя, ә Хәсән ага күргәзмәләрдә фәкать чәчәкләре белән генә катнаша һәм барыбызны да сокландыра иде. Бакчаларыбыз күрше булганга, минем өлешемә аның белән очрашып сөйләшүләр бәхете дә төшкәләп торды. Күп очракта сөйләшүләр хәл-әхвәл белешүдән узмый иде. Кайбер вакытта гына татар театрларының репертуары белән кызыксына. Мин җитмешенче елларда культура министры урынбасары булып эшләдем һәм ел тәүлегендә 50–60 яңа спектакль кабул итүдә катнаша идем. Мин, әлбәттә, үзем белгәнне сөйли идем, ләкин Хәсән аганың ни дәрәҗәдә театрал булуын әйтә алмыйм.

Чыбык очы туганым очучы (ул хәзер язучы да) Рәшит абый Ибраһимов Сочи якларыннан иң беренче черешняларны алып кайта иде һәм безнең гаиләне сыйлый иде. Һәм без һәр елны шул черешнядан Хәсән агага да өлеш чыгара идек. Шундый көннәрнең берсендә хатыным Лилия бер кәнди черешня алып Хәсән ага өенә кереп китте дә, йөзе агарынып, әйләнеп тә чыкты. Күчтәнәче кулында.

— Ренат, Хәсән агайга анда нидер булган, ахры...

Аны-моны уйлап тормастан, мин Хәсән ага янына йөгереп кереп киттем. Тәрәзә пәрдәләре ачылмаган бүлмә. Хәсән ага караватка чалкан яткан. Күкрәгендә «Спидола» радиоприемнигы. Ниндидер шомлы музы-

ка яңгырый. Хәсән аганың уң кулы күкрәгендә, ә сул кулы идәнгә асылынып төшкән. Йөрәгем жу итеп китте. Мөнҗия апаның, күрәсең, шәһәргә азык-төлек алырга киткән чагы булгандыр. Мин куркып кына Хәсән аганың идәнгә асылынып төшкән кулын күтәрә башладым. Йа Хода, кулы җылы... Ул арада, черешнялы кәндиен тотып, Лилия дә кереп җиткән... «Ни булган?.. Кем анда?» дип, шагыйрь уянып китте... Мин аңа күчтәнәчне суздым.

— О! Черешня! Быел да!.. — дип, Хәсән ага торып утырды. — Лилия сеңел онытмый инде мине, онытмый...

Мин әле дә кызыклы агач ботакларыннан кул таяклары ясарга яратам. Шул елларда бер алмагач ботагыннан матур гына таяк ясаган идем. Тоткасы — бөркеткә ошаган кош, ә кәүсәсендә «Шигырьчылар бер көтү, көт, шигырь бөркете!» дигән язу. Сабантуй алды көннәренең берсендә бу таякны Хәсән ага күреп алды.

— Ба! Синдә мондый осталык та бармыни?.. Нинди язу ул анда?

Мин укып күрсәттем. Таякны алып, үзе дә укып чыкты.

— Бу синең безнеңчә, мишәрчә булып чыккан. Казаннар «шигырьчеләр» дип язалар... — дип, минем хатамны төзәтте. Ләкин мин әле дә булса таяктагы язуда хата юк дип яшим. Татар «шигырь» дип гарәпчә язса да, «шигыр» дип төркичә әйтә, «Рязань»не «Рәзан» дигән кебек...

— Монда бит двойной мәгънә... «Көт» сүзең ударный булып чыккан. Аны тегеләй дә, болай да аңлап була... Әйтик, көтүгә әйләнгән шигырьчеләргә көтүче бул, дип тә. Бер көтү шигырьчеләр типтереп яшәгәндә, син үз чиратыңны көтеп утыр әлегә, дип тә... Кайсын уйлап яздың?

Мин, әлбәттә, ике мәгънәне дә күз уңында тотып яздым, бигрәк тә рифманың матурлыгына кызыгып. Ләкин шигырьнең адресаты турында уйламаган идем. Һәм кинәт:

— Сезне уйлап яздым, — дип җибәрдем, үземнең үтә тапкырлыгыма куанып...

— Чынлапмы?.. Минем «тегендә» (ягъни сөргендә) көтү көткәннәремне белепме?..

Таяк аңа ошады булса кирәк, шул таякны махсус сорап алып, Хәсән ага ике ел Аккош күле буендагы сабантуйларга барып кайтты. Алдагыларына да «резервировать» итеп куйган иде дә, барып чыкмады булса кирәк...

Бүгенге көндә дә ул таяк исән. Ул шәһәрдәге фатирымда саклана. Аңа кагылган саен йөрәгеп бәйләтергә җылы кул эзләгән олы шагыйребезнең үз куллары җылысын тойгандай булам... Һәм йөрәкне үкенү хисе кысып ала — ник таякны шагыйрьнең үзенә бүләк итә белмәдем?..

Кеше-күрше мөнәсәбәтләре, минемчә, әнә шулай шактый җылы иде безнең. Шигырь остасы, иҗат океанында давылларны шактый күргән, татар шигърияте дә үз мәктәбен тудырган шагыйрь Хәсән Туфанның формада экспериментлар ясаудан баш тартмаган, метафораларда «мөгез чыгарырга» яраткан, юкны эзләү юлына баскан башка мәктәп укучысы Ренат Хариска принципиаль карашы шәхси мөнәсәбәтләргә бәйле түгел иде... Кем әйтмешли, пәри — башка, җен — башка...

*Сентябрь, 2000*

# Два сердца Назиба Жиганова

Бесспорно, композитор Назиб Жиганов является выдающимся сыном татарского народа не только потому, что оказал мощнейшее воздействие на развитие его культуры, но и потому, что своим великим творчеством вывел ее на международные просторы и тем самым дал современный блеск имени своего народа. Таких людей в позднейшей истории татар пока не очень много, но с каждым годом их имена все больше и больше возвращаются из тьмы памяти на солнечный свет. Вернулись Юсуф Акчура, Садри Максуди, Мирсаид Султангалеев... И дай нам, Аллах, мудрости и силы, чтоб не заболеть новым беспамятством...

А Назиб Гаязович Жиганов, как почти все великие люди, был даже слишком простым и доступным для понимания человеком. Основанием для такого утверждения являются наши многолетние контакты, эпизоды из которых сохранили мои дневники.

В 1975 году я работал заместителем министра культуры Республики Татарстан и вел там сферу профессионального искусства. Естественно, мне приходилось очень часто посещать Казанскую государственную консерваторию и правление Союза композиторов республики. В те годы ректором консерватории и председателем правления Союза композиторов работал Назиб Гаязович Жиганов. И там, и тут чувствовались твердая рука, кипучая энергия и непререкаемый авторитет их руководителя. Слово Жиганова имело очень большой вес, и к нему всегда прислушивались как в Казани, так и в Москве и дальше. Такое положение Назиба Гаязовича в общественной и творческой жизни Татарстана и страны у разных людей, к сожалению, вызывало разную реакцию, порождало пахнущие завистью сплетни... Но об этом как-нибудь потом... А сейчас я хочу открыть свои дневники...

Как правило, каждый четверг в Союзе композиторов устраивалось прослушивание новых сочинений композиторов и их обсуждение. Очевидно, 24 апреля 1975 года был именно таким днем, и я пришел к нему — в его кабинет ректора консерватории. Он набирал чей-то телефонный номер. Я поздоровался.

— А я тебе названиваю... Проходи давай, проходи!..

— Четверг же, Назиб Гаязович, вот и пришел послушать музыку нового балета Анатолия Луппова...

— А разве не нашу с тобой песню?

— Она разве сегодня исполняется?

— Рафаэль Сахабиев поет. Пойдем послушаем его в классе...

Мы пошли по коридору второго этажа и зашли в какую-то аудиторию. Нам сказали, что он в классе Алевтины Миркиной, на третьем этаже. Мы поднялись туда. Оказалось, что Рафаэль пошел в столовую обедать. Алевтина Миркина послала кого-то за певцом, а мы с Назибом Гаязовичем вернулись в его кабинет. Вскоре пришли Миркина и Сахабиев.

— Как, Рафаэль, кушаем крепко — поем громко, что ли?

— Смогу ли вообще... — отпарировал студент. Миркина села за знаменитый белый рояль, и Сахабиев запел.

Про войну говорят старики.
В лесах, на полях щемящая тишь...
Не будем мешать старым солдатам
И будем внимать тихим их словам...

*(Подстрочный перевод)*

Сахабиев потряс меня исполнением последней строки этого куплета. Это был плач, и не плач, а какое-то неведомое, но понятное состояние души. Нет, не моей души, возможно, и не души певца... А души человека, в чьем сердце свили вечные гнезда птицы скорби и сожаления, и он всегда слышит их пенье... До сих пор перед моими глазами Назиб Гаязович, слушающий эту песню. Он слушал ее стоя, находясь за спиной аккомпаниатора, глядя на ноты, в какие-то мгновения в такт кивая головой и вытягивая подбородок. И мне показалось, что поет не Рафаэль, а сам Назиб Гаязович. Глаза его я не видел, так как стоял за его спиной у рабочего стола. Когда Рафаэль закончил пение, Назиб Гаязович в первую очередь поблагодарил Алевтину Миркину, взяв ее за оба плеча, потом обнял студента Рафаэля Сахабиева, потом только подошел ко мне и сказал: «Ну как?»

Я волновался, так как песня была моей первой совместной работой с этим великим композитором, и, естественно, не помню своего ответа на его вопрос...

Затем 26 мая Назиб Гаязович позвонил и пригласил меня в радиокомитет для прослушивания записи этой песни. Автомашины министерства были заняты, и Назиб Гаязович прислал за мной свою ...

В кабинете музыкальной редакции мы встретились с Сарой Садыковой. Клара Тазиева принесла магнитную запись, зарядила воспроизводящий аппарат. И мы замерли в ожидании песни. И она зазвучала в исполнении Рафаэля Сахабиева. Назиб Гаязович слушал ее как-то волнуясь. На лице появились багровые пятна. Часто поправлял очки и слуховой аппарат... Сара ханум почти легла на стол, вытянув свои изящные руки и чуть сгорбившись.

Когда прозвучали последние звуки, Сара ханум быстро встала, подошла к Назибу Гаязовичу и сказала:

— Дай-ка, Назиб, поцелую тебя. Песня получилась красивой и глубокой. Ты здорово написал!.. Правда! Ну вот это место я бы сделала примерно так... — и Сара ханум спела фрагмент песни по-своему.

— Нет, нет, Сара ханум! Так песня выйдет за рамки жанра. Это — грустная баллада... Нельзя... Содержание не позволяет...

— Ладно, ладно, тебе виднее. Я советую тебе не как композитор, а как певица...

После взаимных поздравлений разговор перешел к вопросам житья-бытья.

— Ты, наверное, никогда не состаришься, Сара ханум!

— В ближайших планах не предусмотрено, Назиб! Не предвидится. Пока поем, пока слагаем песни — живем, Назиб, служим народу. Ведь наше поколение вообще живуче! И ты вот как парень молодой...

— У меня ведь, Сара ханум, два сердца. На днях говорю врачам, чтоб меня проверили на наличие второго сердца. Смеются. Однако возле сердца копошились дольше обычного. Только одно, говорят. Не знают ни черта. Во мне точно два сердца, а вот в тебе, Сара ханум, наверняка целых три, если не четыре...

Сара апа, довольная, засмеялась, села за фортепьяно, взяла несколько аккордов и запела сложнейшую «Сайра, сандугач!», выделывая рулады. От удивления и восхищения у Назиба Гаязовича брови полезли на лоб.

— Я же говорю, что у тебя три сердца! Ты же... ты же удивительное существо, прекраснейшая из шайтан, музыкальное чудо...

Еще больше окрыленная и вдохновленная, Сара апа пошла дальше — она запела какую-то малоизвестную народную песню, украшая ее колоратурой.

— Пока не ушла в мир иной, хочу молодых научить вот такой колоратуре, братишка Назиб. Ты только послушай, как она звучит в моей обработке... — Она была очень довольна тем, что сумела удивить такого мастера, как Назиб Жиганов. И он поддержал ее полет, предложил изложить эту обработку и передать в библиотеку консерватории.

— Чтоб ею могли пользоваться музыканты будущих поколений, — сказал он, прощаясь.

30 октября состоялось прослушивание новой оперы Энвера Бакирова «Тукай» на либретто Ахмеда Исхака. Большой зал консерватории был полон — композиторы, писатели, артисты театров, ученые, представители партийных и правительственных органов с нетерпением ожидали первую оперу о великом Тукае. Ф.Насретдинов, Ф.Тимирова, И.Гиззатуллин, З.Сунгатуллина, Р.Мифтахова, Р.Аббасов, Р.Сахабиев и М.Якупов исполнили арии, ариозо из оперы, А.Арсланов прочитал текст либретто оперы. В обсуждении приняли участие Б.Урманче, Н.Даутов, С.Хаким, З.Хабибуллин, И.Нуруллин, музыковеды и ученые. Тон об-

суждения был доброжелательный, все хотели скорейшего появления оперы на сцене. Однако было очень много существеннейших «но». Чувствовалось, что все ждут слова Назиба Гаязовича — самого опытного, самого компетентного композитора в этой области музыкального искусства. Автору восьми опер, нескольких балетов, многих симфоний, наверное, было что сказать об этом, к сожалению, до сих пор не состоявшемся произведении. Он заметно волновался и, вместо обстоятельного разбора оперы, поделился воспоминанием Мансура Музафарова:

— Мне когда-то рассказал покойный Мансур ага Музафаров о том, как мальчишкой он разносил газеты по Казани. Оказывается, он заносил газеты и Тукаю в гостиницу «Булгар». Однажды он зашел к Тукаю, а он сидит на кровати раздетый. И Тукай сказал Мансуру: «Эй, малай, я всю эту ночь разговаривал с ангелами. А ты когда-нибудь видел ангела?» Так вот, что касается меня... то я представляю Тукая в каком-то полете, с высоты которого он разговаривает не только с ангелами, но и с эпохой, со Временем. Опера о Тукае должна быть соразмерна его образу...

...Закрываю дневник, но между его страницами есть еще закладки и они, конечно, там, где фамилия Назиба Гаязовича. Надеюсь, со временем эти закладки будут вынуты, ибо воспоминания о великом человеке вселяют в сердце вспоминающего новую силу и новую жажду творить.

...А в ушах до сих пор звучит чуть глуховатый, но уверенный голос Назиба Гаязовича: «А у меня ведь два сердца!..» И я в это верю! Одно из них разорвалось в 1988 году в Уфе, после триумфального исполнения концертного варианта оперы «Джалиль», а другое сердце композитора Назиба Жиганова бьется в его нетленной музыке.

*Сентябрь, 2000*

# Гариф Ахунов белән бер сәяхәт

Гариф ага Ахунов минем кырык елдан артык дәвердә иң күп аралашкан язучыларымның берсе. Безнең арада сер бүлешүләр дә, киеренке сөйләшүләр дә, минем хаксыз чакларым да, аның хаксыз чаклары да булды, әмма бер-беребезгә булган ихтирам һәрвакыт өскә чыга килде. Мин аңа һәр очракта ага итеп карадым, ә ул мине тиңдәше дәрәҗәсенә күтәрергә шулай ук җай таба белде.

Миңа Гариф абый белән бергә Мәскәүдә дә, Казанда да, Советлар Союзының башка төбәкләрендә дә олы әдәбият-мәдәният бәйрәмнәре оештыруда һәм аларны үткәрүдә катнашырга туры килде. Гариф абыйның партия өлкә комитетында, Министрлар Советында, язучылар, галимнәр, чит илләрдән килгән делегацияләр алдында, авыл клубларында, мәктәпләрендә ясаган чыгышларын хәтерлим. Аңа иң җаваплы җыелышларда, партия коференцияләрендә, Россия язучылары съездларында трибуна бирәләр иде һәм ул һәрвакыт аудиторияне тотып тора торган сүз әйтә иде. Аның иң мәртәбәле мәҗлесләрдә телле яшен сыман ялтыраган тамада чаклары да, «Туп-туп кына басып килә...» дип, меңенче тапкыр җырлаулары да, ияген күккә чөеп, «һа-а!...» диеп көлүләре дә, матәм җыелышларында елатырлык итеп хушлашу сүзләре әйтүләре дә күз алдымда тора. Әле булса мин аның яңгыравык тавышын ишетәм кебек...

Халык «ун тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр күр!» ди. Бәлки, ул хаклы дадыр... Ләкин барыбер маңгай күзе күргәнне КҮҢЕЛ КҮЗЕ аша кичермәсәң, ялгышуың бик ихтимал. Хәзер Гариф ага Ахунов безнең арада юк... Үзенә һәм әдәбиятка, дусларына карата әйтелгән кайбер хаксыз фикерләргә дә җавап кайтара алмый ул, ягъни үзенең безнең хәтерләрдә калган образына яңа төсмерләр дә кертә алмый, булганнарын да яшерер чарасы юк... Һәм мин аңа фәкать күңел күзем белән генә карый алам. Ә күңел күзе ул бөтен нәрсәне берьюлы берләштереп күрсәтүче күзлек кенә түгел, ә кешенең төп сыйфатларын вак-төяктән аерып алып үлчи торган әхлакый бизмән дә...

Гариф ага Ахунов безнең республикада әдәби тормышны оештыручыларның иң активы булды дисәм, ялгышмам дип уйлыйм. Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, Идарә рәисе, «Казан утлары» журналының баш редакторы булып егерме елдан артык эшләве моның һәркемгә дә күренә торган тышкы, рәсми ягы булса, үз иҗатының эстетик, әхлакый, сәяси юнәлеше — бусы язучының асылы — шул еллар татар әдәбиятының зәвыгына сизелерлек йогынты ясадылар. Бу йогынтыны һәр язучы, әдәбият галиме, һәр чор үзенчә билгеләр... Ләкин шунысы бәхәссез — үзәге ныклы, көчле шәхесләрнең генә әдәбият мәйданында үз эзен калдырырга хәленнән килә. Социалистик реализм теориясе, сәнгатькә партиячел караш чәчәк аткан, хезмәт темасы байрак булып җилфердәгән чорларда язган әдипләрнең иҗатларына хәзер ревизия ясарга омтылу сизелә. Гариф аганың күпкырлы иҗаты, минемчә, бу шаукымны Галимҗан Ибраһимов, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Атилла Расих иҗатлары кебек үк уңышлы узар.

Мин язучыларны, аларның башка сыйфатларын читкәрәк куеп торып, ТЫРЫШЛАРГА һәм ИРЕНМӘҮЧӘННӘРГӘ бүләм. Тырышлар башлаган эшләрен, әллә нинди каршылыкларны җиңә-җиңә, максатларына таба алып баралар. Иренмәүчәннәр исә, язылачак әсәрләргә кирәк булып куюы бар дип, теләсә нинди шартларда материал туплыйлар. Гариф абый менә шушы олы сыйфатларның икесенә дә ия язучы иде. Гомумән, ул барлык әсәрләрендә персонажлары мохитен, тарихи документларны тирәнтен өйрәнеп яза иде. Моның бер мисалы итеп мин Гариф абыйның бер сәяхәтен сурәтләп үтәм.

Гариф ага Ахунов «Идел кызы» романын яза гына башлаган елларда, кыш көннәренең берсендә, без аның белән Ульяновск өлкәсенә, мин дөньяга килгән Кәшә авылына кайттык...

Бу авылның гаҗәеп кызыклы кешеләре турында мин аңа сөйләштергәли идем, һәм ул, бер дә иренмичә,

минем сөйләгәннәрне куен дәфтәренә теркәп тә куя иде. Яза торган романы «комга төртелде» микән, әлеге язмалар бик вакытлы исенә төште микән, Гариф абый миңа Кәшәгә барасы килүе хакында әйтте, һәм мин әлеге сәяхәтне оештырдым. Гариф абый ул чакта Язучылар берлеге рәисе иде, ә мин — мәдәният министры урынбасары.

Кәшә халкы СССР Верховный Советы депутатын һәм үзенең якташын матур каршы алды. Буранлы көн булуга карамастан, клубка халык та шактый җыелган иде. Гариф абыйга сораулар да күп булды. Ул аларга, һәрвакыттагыча елмая-елмая, үзенең әсәрләреннән һәм үзе тәрҗемә иткән М.Шолохов китапларыннан кызыклы мисаллар китерә-китерә җавап бирде. «Хуҗалар», «Ардуан батыр» турында берничә бик конкрет һәм төпле сорау булды. Әле күптән түгел генә авторына Тукай премиясе китергән бу әсәрләр әдәбият сөючеләр телендә иде. Гариф абый алар турында аерата тәфсилләп, дулкынланып сөйләде. Бер нефтьченең төнлә, ялгышып, күршесенең пешкән итен ашавы хакындагы эпизодны укып, залны озак кул чаптырды. Күренеп тора — сораулар язучының күңеленә хуш килгән. Минем болай да күтәренке кәефем тагы да күтәрелеп китте — сораулары аша якташларым авылның, халыкның чыннан да кызыклы, затлы булуын күрсәттеләр. Мин шул вакытта тагын бер мәртәбә куанычның горурлыкка әверелүен тойдым...

Шулчак Гариф абый көтелмәгән бер эш эшләде. Ул, залга мөрәҗәгать итеп, болай диде:

— Сез миңа сорауларны мулдан яудырдыгыз. Мин аларга рәхәтләнеп җавап бирдем. Хәзер мин дә сезгә бер-ике сорау бирим әле... Менә Ренат миңа Казанда сезнең авылдагы Ләлек-мамык-чыбыркы һәм шундыйрак кызыклы кушаматлар турында сөйләде... Тагын нинди кушаматлар бар? Алар кайдан килеп чыккан? Миңа шулар турында сөйләмәссезме?

Зал шаулап көлеп алды. Кемдер: «Ә нәрсәгә кирәк ул сиңа?» — дип кычкырды. Гариф абый шунда үзенең «Идел кызы» дигән роман язуы турында сөйләп китте. Кемдер «Алай булгач сүләмибез...» дип кычкырды. «Сүлик, китапка кереп калыйк...», «Ничек язма келидер бит әле...» дигән тавышлар да яңгырады... Очрашу шактый сузыла башлаган иде инде. Кичәне йомгаклап, «Ярар, үзебез сүләрбез!» дип, «Волга» колхозы рәисе Харис ага Газизов безне кичке чәйгә алып китте...

Кичке чәй бик күңелле узды. Катнашучылар арасында, авыл, колхоз, партия оешмасы җитәкчеләреннән тыш, заманасында «Чаян» редакциясендә фельетончы булып эшләгән Галимҗан Насыйров (Шадра) һәм аның даими партнерлары булып шаяртучылардан минем абзам укытучы Әнвәр Фәезов, Исмай Насыйров (Кәнәч) һәм тагын берничә укытучы бар иде. Алар Гариф абыйга кайбер кызыклы кушаматларның тарихын сөйләделәр. Көлә-көлә тиргә баткан Гариф абый шунда: «Сезгә, егетләр, төрек солтанына Кәшә мишәрләре хаты язарга гына кирәк мондый тел белән...» — диде. «Беренчедән, Төркиядә күптән инде солтан юк!» диештеләр тегеләр, «Икенчедән, без, Гариф брат, мишәр тегел...» дип, яңа бәхәс кузгаттылар... Гариф абый, хуҗаларны үпкәләттем, ахры, дип борчылып, дөньядагы бик күп атаклы татарларның мишәр булуы хакында, бүгенге көндә Татарстан җитәкчеләре арасыда да мишәрләрнең байтак булуы хакында сөйләде.

— Безнең беренче секретарь Табеев мишәрләрне «высший сорт татар» дип әйтә! — дип юатырга тырышты Гариф абый һәм, теманы кискен борып, юморга бай Кәшә халкы өчен бик матур тост күтәртте... Гариф абый оста итеп көлдерә дә, матур итеп көлә дә белә иде һәм, иң мөһиме, үзе дә иң кырыс шаяртуларны да егетләрчә күтәрә иде...

1978 елда «Идел кызы»ның беренче китабы басылып чыкты. Анда Кәшә материалларының урын алуы бүген дә минем күңелемне җылытып тора. Гариф абыйның Кәшәгә тагын бер барып кайтасы килә иде. Бу хакта аның миңа берничә мәртәбә әйткәне булды. Мин дә берничә мәртәбә теге сәяхәтне кабатларга вәгъдә бирдем, ләкин ул вәгъдәләр, кызганыч ки, үтәлми калдылар һәм искә төшеп сызландыра торган үкенечкә әйләнделәр.

*Июнь, 2001*

## Кодрәтле оста

*(Марсель Сәлимҗанов)*

Мин аның белән балыкка йөрмәдем. Ә үзенең бик тәмләп сөйләгәннәрен ишеткәнем булды. Балачакның иң матур хатирәләренә әверелгән бу шөгыльгә бик сирәк җай чыгара алдым. Балык каптырып утыру ул ау да түгел, спорт та түгел, ә бәхетле ялгызлыкка бирелү мөмкинчелеге. Балыкка йөрү — философлар шөгыле... Иҗат кешесе ялгызлыгында илаһи азатлык яши. Ялгызы гына уйланып утырганда, кеше матур була, хәтта уйлары авыр вакытларда да. Җае чыкканда якыннарыгызның шундый чагына игътибар итегез, йә булмаса Роденның «Фикер иясе», Урманченың «Сагыш» скульптураларын, Васнецовның «Аленушка», Таир Салаховның «Кара Караев» дигән картиналарын исегезгә төшерегез... Шуның өчен дә мин Марсель Хәкимовичка ияреп йә үзен ияртеп балыкка йөргән кешеләргә бераз гына көнләшеп карыйм, чөнки алар бу гаҗәеп кызыклы, энциклопедик әңгәмәдәшләренең әнә шул матур чакларын күп күргәннәр, аның әнә шул бәхетле ялгызлыкта гына телгә иңә торган фикерләрен ишеткәннәрдер, бәлки.

Хәер, миңа да гомер барышында Марсель Сәлимҗанов белән очрашу-сөйләшүләр аз тимәде. Без озак еллар бер ишегалдына чыккан йортларда яшәдек. Эт уйнатырга чыккан сәгатьләрендә очрашсак, ул минем белән күбрәк сәяси мәсьәләләр турында сөйләшә иде. Минем «Эт уйната берәү кала уртасында...» дигән шигырем шундый очрашуларның берсеннән соң языллды... Марсель Хәкимович, һәр яңалык белән кызыксынып

баручы кеше буларак, дөнья сәясәтендәге һәр мөһим хәлдән хәбәрдар булды. Аны беренче нәүбәттә сәяси вакыйганың асылы түгел, ә андагы интрига, аңа бәйле шәхесләрнең үзара мөнәсәбәтләре, һәм нәтиҗәдә шул шәхесләрнең алдагы язмышлары кызыксындыра. «Әйтте диярсең, фәләнне үстерәчәкләр, төгәнне урыныннан алачаклар...» дип, фикерен дә әйтә. Һәм күп очракта ул ялгышмады. Марсель Хәкимовичның бу сәләтен мин аның киң эрудицияле, кызыксынучан, аналитик акылга ия шәхес булуы һәм режиссерлык профессиясенә бәйләп аңлыйм һәм аңлатам, һәр спектакль, асылда, — интрига, ягъни персонажларның бер-берсе белән бәрелеше, вакыйгаларның персонажларга бәйле рәвештә хәрәкәте һәм — киресенчә. Театр сәхнәләрендә йөзләрчә спектакль куйган кеше, әлбәттә, интриганың барлык серләрен дә диярлек белә. Гомумән, режиссерлар һәм драматурглар — интриганың иң зур осталары, һәм бу табигый дә, чөнки моңа сәләт аларның профессияләре нигезен тәшкил итә, дип уйлыйм.

Акылы аналитик булмаган кеше, минемчә, шулай ук режиссер була алмый, чөнки вакыйгалар хәрәкәтендәге логик сәбәпчеллекне, персонажлар характерындагы эзлеклелекне күрер өчен дә акылның шушы хасияте кирәк. Мин Марсель Сәлимҗанов куйган күпчелек спектакльләрне беләм. Алар стиль һәм логика мәсьәләсендә камил була торганнар иде.

Миңа 1973–1982 елларда Татарстан мәдәният министрының профессиональ сәнгать буенча урынбасары булып эшләргә туры килде. Ул чорда республикадагы барлык дәүләт театрларының һәр спектаклен министрлыкның кабул итү комиссиясе карый һәм спектакльне халыкка күрсәтү-күрсәтмәү мәсьәләсен хәл итә иде. Ул комиссиядә, әлбәттә, сәхнә сәнгатенең танылган остасы буларак, Марсель Хәкимович та эшләде. Билгеле, аны Әлмәт, Бөгелмә, Минзәлә театрлары спектакльләрен кабул итешергә сирәк чакыра идек, чөнки ул үзе һәрвакытта диярлек үз сәхнәсенә яңа әсәр кую белән мәшгуль булды. Гомумән, театрларның баш режиссерларын төп эшләреннән бик мөһим очракларда гына аера идек.

Шул комиссиянең рәисе буларак, миңа, яшь һәм тәҗрибәсез министр урынбасарына, еш кына Марсель Хәкимович белән киңәш-табыш итешергә туры килде.

— Ну, Харис, син моны үзең дә беләсең инде, — дигән булып, ул миңа театр һәм сәхнә сәнгатенең мин белмәгән серләрен аңларга, проблемаларына төшенергә ярдәм итте.

Комиссия утырышлары спектакльне караганнан соң ук баш режиссерлар кабинетларында була торган иде. Марсель Хәкимович, спектакль аңа ошамаган очракта, залдан кабинетка күченештән файдаланып, утырышка калмый. Күрәсең, профессиональ әхлак таләпләре аңа үзенең коллегасына тәнкыйть сүзе әйтергә рөхсәт итми иде. Спектакль ошаса, ул, коллегасының уңышларын күрсәтеп, этрафлы чыгыш ясый, спектакльне тагы да камилләштерү юлларын күрсәтә. Аның киңәшләренә опера театрында да, Качалов исемендәге театрда да, яшь тамашачыларныкында да күп вакытта колак салалар иде. Гомумән, Марсель Хәкимович коллегалары янында эреләнмәде, үзен гади, тыйнак, әмма күзгә күренерлек сак тотты. Ә үз театрында, бигрәк тә үзе куйган спектакльләр турында фикер алышканда, Марсель Хәкимович азартлы бәхәсчегә әверелә. Комиссиянең кайбер әгъзалары аның татар әхлагына туры килеп бетмәгән сурәтләү чараларын еш куллануын, аларның спектакльдән спектакльгә күчеп йөрүен тәнкыйтьлиләр иде. Аларның кайсыбере матбугат битләренә дә бәреп чыкты бугай. Мондый тәнкыйтьне Марсель Хәкимович авыр кичерде. Тамашачыга ошый бит дигән сылтау белән акларга тырышты, бөтенләй үк булмаса да, спектакльнең андый урыннарын төзәтте. Ул үзенең мин-минлеген авызлыкта тота белә торган олы сәнгатькяр иде.

Билгеле, әңгәмәләребез сәясәт кысалары белән генә чикләнмәде. Мин «Казан утлары» журналының баш редакторы булып эшләгән чорларда анда басылган уңышлы һәм уңышсызрак әсәрләр хакында да сөйләшкәннәребезне хәтерлим. Әйтик, Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы турында. Бу әсәр аңарда матур тәэсирләр калдырган иде. «Бәлки, сәхнәләштерергә кирәктер аны?..» дигән тәкъдимгә ул болайрак җавап бирде:

— Сәхнә өчен артык зур һәм күп планлы, ә менә күп серияле кинофильм өчен суйган да каплаган инде...

Марсель Хәкимович татар әдәбиятын да, Советлар Союзы халыкларының рус телендә басылган әсәрләрен дә күзәтеп бара, аларның иң күренеклеләрен күпләрдән элегрәк укыган була иде. Ул татар әдәбиятыннан, бигрәк тә аның драматургиясеннән күпне көтте, өмет итте. Бик еш кына «Менә фәләннән пьеса килде, төгәннекен укыдык... Тар шул, тар! Татарда никтер маңгай тар...» дип көрсенде. Бу аның күптәнге һәм ныклы фикере иде.

Җитмешенче-сиксәненче елларда язучыларның «Әдәби ел йомгаклары» дигән гомуми җыелышлары ныклы әзерлек белән үтә иде. Анда республиканың иң күренекле әдәбият белгечләре, галимнәр, сәхнә осталары докладлар белән чыгалар. Докладлар шактый таләпчән һәм кырыс була. Юк, «күсәк» тәнкыйте түгел иде аларда, ә ярманы көрпәдән аерып бирә торган, һәркемнең иҗади уңышын күрергә тырыша торган принципиаль тәнкыйть иде. Әдәбиятыбызга алтмышынчы елларда килгән язучыларның күпчелеге әнә шундый «Әдәби ел йомгаклары»ның шифалы йогынтысында формалашты.

Хәтеремдә, 1976 елның шундый җыелышында драматургия турындагы докладны Марсель Сәлимҗанов ясады. Мин аның язганны укып ясаган чыгышын хәтерләмим. Ул барлык чыгышларын да, Россия культура министрлыгындамы, партиянең өлкә комитетындамы, теоретик конференцияләрдәме, телдән генә, тезисларга карап кына (еш кына аларсыз да) ясый һәм уңышка ирешә иде. Бу юлы да Марсель Хәкимович үзенә хас традицияне бозмады... Шул чыгышында да ул татар драматургиясенең ул еллардагы төп җитешсезлекләрен: «бытовизм» чиреннән арына алмавын, ясалма психологизмны, конфликтларның примитивлыгын, сүз комизмы белән артык мавыгу, ситуация комизмына сирәк ирешү, геройларның философик җегәрсез, очерк персонажлары дәрәҗәсендә генә булуларын дәлилләде. Ялгышмасам, нәкъ шул чыгышында ул татар драматурги-

ясенә яңа тын бирүдә безнең буын шагыйрьләренә өмет багълавын әйтте һәм шигыребездә булган заман сулышын, яңа формаларга төрелгән заман идеяләрен, метафоралар кискенлеген драматургиягә дә алып кирәргә өндәде, безгә өмет багълавын әйтте. Аның урынлы һәм мөһим чакыруына шагыйрь Рөстәм Мингалим генә җавап бирде булса кирәк...

Марсель Хәкимовичның хәтере искиткеч яхшы иде. Ләкин мондый хәтер безне, бигрәк тә киләсе буыннарны, үтә кыйммәтле байлыктан — маэстроның үз сүзләре белән әйткән эстетик һәм философик фикерләреннән — күпмедер мәхрүм дә итте. Хәер, ул заманнарда һәр җыелышның протоколы җентекләп теркәлә иде. «Әдәби ел йомгаклары»нда сөйләнгән докладларның да уңышлылары «Казан утлары»нда басылды. Бәлки, Язучылар берлеге архивында йә булмаса «Казан утлары» битләрендә бу чыгыш тулырак рәвештә сакланып та калгандыр...

1975 елның яз башында Рәшидә ханым Җиһаншина Г.Камал исемендәге театр директоры урыныннан китәргә дип сүз кузгатты. Мәдәният министрлыгы өчен көтелмәгән хәбәр булды бу. Үз вазыйфасын чын иргетләрчә башкарган Рәшидә ханымны без китмәскә шактый озак үгетләдек, әлегә директор булырлык кешене күрмибез, дип тә карадык. Һәм ул, безгә булышу йөзеннән, драматург Туфан Миңнуллин кандидатурасы турында уйлап карарга киңәш итте... Егерменче-утызынчы елларда үз театрында директор булып эшләгән, псевдоним куеп үзенә үзе җибәргән пьесаларын озак еллар сәхнәсенә менгермәгән мәшһүр немец драматургы Фердинанд Брукнер хәтеремә килде... Мин Марсель Хәкимович белән киңәштем. Бу кандидатураны ул хуплап кабул итте. Җаны-тәне белән театрга бирелгән кешенең директор булып эшләвендә ул үзенә генә мәгълүм перспективалар да күрде булса кирәк. Икенче тапкыр сөйләшү вакытында Марсель Хәкимовичның логикасы үзгәрәк иде инде. Ул Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Габдрахман Минский, Мирсәй Әмир кебек өлкән буын драматургларыннан инде берни дә көтмәве турында ачыктан-ачык әйтте, Хәй Вахит, Юныс Әминов, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахуновлар буыныннан да атом, космос заманы балкышларын өмет итү авыр инде, диде. Шәриф Хөсәеневнең аз язуы хакында ничектер җиңелчә генә әйтеп китте. Әгәр дә Туфанны да, драматургиядән аерып, административ эшкә җибәрсәк, дөрес булырмы икән дигән, бик аңлашыла торган сорау куйды. Әгәр дә Туфан бу эшкә алына калса, аның белән рәхәтләнеп эшләячәген дә белдерде. Әлбәттә, мин директорлык эшен Туфанга тәкъдим итеп карадым. Әлбәттә, ул, иҗатында тизләнеш ала баручы драматург, безнең тәкъдимне кире какты һәм, минемчә, дөрес итте.

Әлеге сөйләшүне дә, Марсель Хәкимовичның әдәби ел йомгакларында ясаган чыгышын да, драматургиягә яшь шагыйрьләрне, прозаикларны өндәүләрен дә, Казан театр училищесындагы, Казан культура институтындагы педагогик эшчәнлеген дә истә тотып, мондый нәтиҗәгә килергә була: ул, иң абруйлы татар театрының баш режиссеры, гомумән утыз еллап татарның режиссерлык мәктәбе җитәкчесе булуы белән генә чикләнмичә, үзенең җилкәсенә үзе теләп татар театры дигән катлаулы дөньяга да үз тәртибен һәм зәвыгын урнаштыру җаваплылыгын да алган чын мәгънәсендә олы шәхес, кодрәтле оста иде. Аның һәр эше үз театры чикләреннән ташып чыга иде, ә йогынтысы Татарстаннан читтәге татар театрларында да сизелә. Ул үзенә кирәкле драматурглар, артистлар, театр рәссамнары, театр композиторлары тәрбияләде, үзенә кирәкле пьесалар яздырды, язылганнарын үзенә кирәкчә төзәттерде, үзгәрттерде, режиссерлык сәнгатендә дә, театрны оештыруда да традицияләр булдырды. Шуның өчен дә аны, кулны йөрәккә куеп, татар театр сәнгатенең классигы дип атап була.

1997 елның октябрь аенда язмыш безне Республика клиник хастаханәсендә очраштырды. Икебезнең дә бөерләребезгә операция ясарга кирәк булып чыкты. Шушы катлаулы адымга әзерләнгәндә, минем күз алдыма ап-ачык булып еракта калган бер вакыйга килеп басты... Ул елларда СССР һәм РСФСР культура министрлыклары репертуар буенча киңәшмәләр үткәрәләр иде. Мондый киңәшмәләр илнең төрле шәһәрләрендә узды. Ялгышмасам, 1973 елгымы, 1974 елгымы киңәшмә октябрь аенда Пермь шәһәрендә булды. Татарстан делегациясе Пермьгә иң соңгылардан булып килде. Алдан килгән — урын өчен, диләр, безгә кунакханәдә бераз тыгызланыбрак урнашырга туры килде. Шулай итеп, Марсель Хәкимович белән мин икебезгә бер люкс номерга урнаштык. Икенче көнне, җыелыштан соң, без номерыбызга Россия культура министрлыгыннан берничә «хәлиткеч» кешене кунакка чакырдык. Ул елларда коры шәраб эчү модага кереп бара иде. Без дә кунакларыбызны коры шәраб һәм чәк-чәк белән сыйладык. Кунаклар таралышкач, беребез йокы бүлмәсендә, икенчебез залда килеш, озак кына сөйләшеп яттык.

— Салкын номерларда торабыз... Репертуар дип тарткалашабыз... Мировая, русская, советская классика дигән булып, бөтен театрларга бер үк кием киендертмәкчеләр... Сизәсеңме, бер үк авторларны такмакчы булалар... Мәскәүнекеләрне... Ә милли авторларны тәрҗемә итәргә ашыкмыйлар үзләре... — дип, Марсель Хәкимович ачуын куертып алды... — Йөрибез шунда вакыт әрәм итеп... Нервы бозып... Сәламәтлекне туздырып... Менә миңа тиздән кырык... Әллә уздырып була, әллә юк...

— Кырык яшьне уздырмыйлар бит... Ниндидер начар фалы бар, имеш...

— Мин банкет-фәлән турында әйтмим... Сез бит берегез дә белмисез — минем бөерләр бернигә дә ярамый... — диде ул, әллә сыкранып, әллә көрсенеп...

— Ник дәваланмыйсың соң?.. Обком сине теләсә нинди больницага сала ала бит...

— Обком ул сала. Минем ятасым килми... Үзең беләсең ич — алда күпме эш тора...

Ул елларда театрлар сезонга 6–7шәр премьера уйныйлар иде. Үз театрында премьераларның күбесе Марсель Хәкимовичныкы була торган иде... Шунысын да искәртеп китәргә кирәк — Казанның барлык театрлары да бу чорда тамашачылар кытлыгы кичерде һәм премьераларның күп булуы тамашачыны театрга китертә торган иң мөһим чараларның да нәтиҗәлесе дип карала иде. Хәзер инде Марсель Хәкимовичның ул

сезонда нинди әсәрләр куерга җыенганын хәтерләмим.

Кыскасы, Республика хастаханәсендә минем хәтеремә әнә шул вакыйга килде. Мин аны Марсель Хәкимовичның да исенә төшердем.

— Менә шулай, килә-килә килеп җиттек... пычак астына, — дип куйды ул, үзенең хәленә исе китмәгәндәй. — Ходай ни язган булса, шул булыр инде...

Безне берничә көн буена операциягә әзерләделәр. Шул вакытта без бик күп нәрсәләр турында сөйләшеп өлгердек. Аны сәясәт тә, татар әдәбиятының хәле дә, республика җитәкчелеге турында имеш-мимешләр дә элеккечә үк борчый. Ул романнарның юк дәрәҗәдә аз язылуы, язылганнарының үткәннән гел гаеп эзләүгә корылган булулары, тарихка багышланган әсәрләрнең бармак имеп язылулары турында дәлилле һәм кискен фикерләр әйтте — димәк, журналларыбызны да, нәшриятларыбыз җимешләрен дә күз уңыннан төшерми. Мин аңа татар театрының киләчәге һәм эстафета таягын алып китәчәк кадрлар турында берничә сорау бирдем... Режиссерлар турында ул болайрак җавап бирде:

— Менә сезнең шагыйрьләр арасында инде картаеп бара торган яшь буын бармы, аларга нинди җитешсезлекләр-кимчелекләр хас булса, безнең режиссерларга да нәкъ шулар хас...

— Димәк, безгә яшәргә дә яшәргә генә кала, — дидем мин.

— Ни язган булса, шул килер инде, — дип кабатлады Марсель Хәкимович.

Сөйләшү аның палатасында булды. Миңа иртәгәсе көндә операциягә керергә иде, аңа — бер көн соңрак... Без, операциядән соң әңгәмәне дәвам итәргә язсын, дип кочаклаштык. Бу бәхилләшү түгел иде... Бу кочаклашуны мин әлегәчә ничектер читтән карап күрәм — рәссам Искәндәр Рафиковның «Җәлилчеләр» әсәре кебегрәк итеп...

Миңа операцияне 8 октябрьдә профессор Ринат Харисович Галиев, ә аңа 9 октябрьдә профессор Дмитрий Михайлович Красильников ясады. Минем хәлләр җиңелрәк булган — аякка тизрәк бастым һәм Марсель Хәкимовичның бер этажга югарырак урнашкан палатасына кереп йөри башладым. Кайчан гына керсәң дә, аның янында хатыны Гөлнара ханым булды. Мин кергәндә, еш кына ул Марсель Хәкимовичның кулын тотып утырган була иде. Марсель Хәкимовичка бу бик ошый иде булса кирәк — Гөлнара ханым якынлашкан саен, ул аның кулына үзе сузыла. Ул миннән, мин аңардан яраларыбызның ничегрәк авыртуы, төзәлүе турында сорашабыз. Минем хәлне сорашып, ул үз хәлен чамаларга тырыша. Савыгудагы кайбер аермалыкларны «синең яраң уң якта, ә минеке сулда...», «синдә май катламы кимрәк шул...», «миңа бер көнгә соңрак ясадылар шул...» дип аңлатты һәм үзен тынычландырды...

Марсель Хәкимовичның аякка басу теләге гаҗәеп көчле иде, чөнки аны яңа эшләр, куеласы яңа спектакльләр ашыктырды... Шуңа күрә дә ул язмышның әлеге катлаулы һәм хәтәр сынавыннан чагыштырмача тиз чыкты, аягүрә калды...

*15 февраль, 2003*

# Ишморат алмагачы

Шулай туры килде ки, озак еллар дәвамында Аккош күлендә без Риза ага Ишморат белән бер өйне икегә бүлеп яшәдек. Шәһәрдәге фатирларыбыз да Чехов һәм Лесгафт урамнарындагы күрше йортларда иде...

1972 елда күренекле чуваш язучысы Алексей Талвир яңадан Чабаксарга кайтып киткәч, Аккош күлендә алардан бушаган иҗат йортының ике бүлмәсен миңа — инде бер елдан артык Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре булып эшләгән яшь язучыга тәкъдим иттеләр. Бу өйнең ярты ягындагы ике бүлмәдә озак еллар Риза ага үзенең гаиләсе белән яшәгән һәм язу өстәле янында бихисап күп сәгатьләр уздырган. Риза абзый һәм аның хәләл җефете Рәисә апа белән якыннан аралашуыбыз әнә шул иҗат йортында башланды... Бүген дә бу өй исән әле. Аның янындагы ел саен мул уңыш бирә торган бер бик карт алмагач та исән... Без бу өйне бераз яңарттык, сипләттек, ныгыттык — шулай итеп, татар мәдәнияте тарихында якты эз калдырган күренекле шәхесләрнең рухларын, истәлекләрен сеңдергән өйне саклап калдык. Бу өйнең яшьтәшләре инде ишелеп беттеләр... Бу истәлекләремне дә мин кайчандыр Риза ага эшләгән бүлмәдә, Хәсән Туфаннан, Шәрәф Мөдәррис һәм Ләбибә Ихсановадан, Нәби Дәүлидән, Зәки Нуридан, Алексей Талвирдан, Рәисә Ишморатовадан калган өстәлдә язам...

Ул елларда Аккош күле язучылары бакчачылык белән дә шактый тырышып шөгыльләнәләр иде. Төгәлрәк итеп әйткәндә, бу эш, әлбәттә, язучы хатыннары җилкәсендә булды. Шуңа күрә дә биредәге өйләр Сибгат Хәким өе, Гомәр Бәшир, Нил Юзиев, Нәби Дәүли өе дип, ә бакчалар Мөршидә апа бакчасы, Кәримә апа, Дамира ханым, Наҗия апа бакчасы дип йөртелә иде... Ә Риза абзый белән Рәисә апа икесе дә язучы булганга, җир эшенә артык игътибар бирмәделәр. Безнең бакчада күбрәк минем әти белән әни эшләсә, аларныкында башлыча уллары, киленнәре, бигрәк тә кече киленнәре Рәхилә әвәрә килә иде. Әлбәттә, Риза абзый да бакчада еш күренә. Язу өстәлен беравыкка ялгыз калдырып, берәр түтәл янына килеп баса да: «Рәисә, моны нишләтергә?.. Рәисә, моңа күпме су сибәргә?..» — кебегрәк сорау белән хатынына эндәшә. Рәисә апа да чыга. Ул да, түтәлләргә бераз карап торганнан соң, Рәхиләне чакырып чыгара, аңардан сорашып, Риза абзыйга ЦУ (ценное указание) бирә. Шуннан Риза абзый, иелеп, бер-ике чүп үләне йолкып ала, аны кая ташларга белмичә аптырап тора. Ниһаять, койма буендагы компост өеменә илтеп ташлый да, гаҗәеп канәгатьлек хисе кичереп, ятим калган язу өстәле янына кереп китә... Озак кына чыкмый тора. Чыга... һәм теге күренешкә охшаш хәрәкәт тагын кабатлана... Читтән карап торганда, бу кемгәдер бераз мәзәгрәк булып тоелгандыр, әмма сиксәненә таба барган язучының бөтен дикъкате язу өстәлендә булуы, аның һаман да иҗат дәрте белән яшә-

ве, җәйләрнең ымсындыргыч ямена дә бирешмичә, көннәр буе язып утыра алуы мине әле дә сокландыра һәм әле дә үрнәк булып тора...

Егерме еллап күршелек кылган дәвердә Риза абзый белән бик күп мәртәбәләр сөйләшеп-әңгәмәләшеп утырырга да туры килде. Кызганыч ки, мин, хәтеремә ышанып, аларны кәгазьгә төшерә бармаганмын. Хәзер, инде алтмышны узгач, беләм: иҗат кешесе өчен иң кирәклесе һәм шул ук вакытта иң ышанычсызы — хәтер икән!..

Аның яраткан темаларыннан берсе Сәгыйть Сүнчәләй булды. Риза абзый бу шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесенең тормыш юлын да, шигырьләрен дә тирәнтен белә, аңардан дәресләр алуы турында (шулай хәтерлим) горурланып сөйли иде. Тукайны чын шагыйрь итешкән кешеләр арасында Сүнчәләйнең урынын ул бик зурдан билгеләде, әмма аның тиешле бәя алмавына бик эче пошты... Риза абзый Сүнчәләйнең күп кенә шигырьләрен яттан сөйләп, соклана-соклана, аларга шәрех-аңлатмалар бирә. Аны тыңлаганда, мин Сәгыйть Сүнчәләйнең чыннан да зур шагыйрь булуына ышана башлый идем... Тагын бер яраткан темасы — театр. Ул үзенең төп остазы итеп Кәрим Тинчуринны таный иде. Әңгәмәбез нәрсә турында гына бармасын, Риза абзый Кәрим Тинчуринны, һичшиксез, искә төшерә, аның белән бергә эшләгән чактагы берәр эпизодтан мисал китерергә ярата. Театрларыбызның теге яки бу спектакльләре турында сүз чыкканда, ул «Кәрим абзый болайрак иткән булыр иде, тегеләйрәк иткән булыр иде» дип, аңа сылтап, үз бәясен бирә... Риза абзый белән Рәисә апа Казан театрларындагы барлык премьераларны карап бардылар. Мин дә ун елга якын мәдәният министры урынбасары булып эшләгән чорда бер генә премьераны да калдырмадым. Шуңа күрә безнең театр турындагы фикер алышуларыбыз конкрет булды. Кызганыч ки, бу әңгәмәләрнең нечкәлекләре хәтеремдә сакланмаган. Ләкин шунысын ачык әйтә алам: һәр премьера Риза абзыйда үз әсәрләренең берәрсен яңадан сәхнәдә күрү теләге уята иде. Гомеренең соңгы бик күп елларында кайчандыр үзе баш режиссер булып эшләгән театр ни өчендер аның бер генә пьесасына да әйләнеп кайтмады. Бу хәл күпне күргән, күпкә түзгән мәшһүр драматургның бәгырен көйдерде... Ләкин ул өметен өзмәде.

Әле дә хәтеремдә, Риза абзый Габдулла Тукайның 100 еллык юбилеена биш-алты ел элегрәк әзерләнә башлады. 1981 ме, 1982 ме елны ул «И мөкатдәс моңлы сазым» дигән пьесасын язып бетерде һәм театрга тәкъдим итте. Драматургның үз юбилеена — 80 еллыгына да, кем әйтмешли, бер генә адым калып бара иде. Кайда гына очрашсак та, ул чорда Риза абзый үзенең язу өстәлендә яткан пьесасы турында сүз кузгатмый калмады. Сөйләшүләрнең берсендә ул миңа «Тукайның иң зур гражданлык батырлыгы нәрсәдә?» дигән сорау бирде. Бу сорау алдында мин шактый каушап калдым. Без бит мәктәпнең беренче сыйныфыннан башлап, Тукайның бөеклегендә бер генә тап та, ярты гына күләгә дә күрмәскә күнеккән, аның турындагы һәр язмага берсүзсез ышанган кешеләр. Бүген дә күбебезнең Тукай турында үз фикере юк дисәк тә ярый. Әйе, Тукай — халкыбызның даһи улы, бөек шагыйре. Ләкин ул балигъьлык чорыннан күптән түгел генә чыккан яшь җилкенчәк вакытында ук вафат булган. Баррикадаларга күтәрелмәгән, сугышларда катнашмаган, патша төрмәләрендә ятмаган, парламентларда ялкынлы чыгышлар ясамаган... Риза абзый әлеге соравы белән мине бөек шагыйребез турында тирән уйлар чоңгылына батырды. Әлбәттә, Тукайның иң зур гражданлык батырлыгы — аның адәм ышанмаслык авыр шартларда барлыкка килгән, кояш нуры белән өртелгән, татар горурлыгы белән сугарылган иҗаты. Ләкин ул вакытта мин, Риза абзыйның уйлары сукмагында калырга тырышып, шагыйрь шәхесен шактый тарайтып һәм сәясиләштереп, «Китмибез!» дип әйтә алуында!» дип җавап бирдем. Бу идеяне пьесага кертү, аны сәхнә әсәренең бер агымы рәвешендә алып бару Тукай шәхесен калку һәм сугышчанрак итәр иде, дигән фикер дә әйттем. Риза абзый үзенең героен, әлбәттә, моның белән генә чикләмәде, киңрәк, Сибгат Хәким әйтмешли, масштаблырак итеп язды. Анда татар халкының күренекле уллары Хөсәен Ямашев, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй һәм башка тарихи шәхесләр конкрет тарихи вакыйгалар эчендә гәүдәләндерелгән... Драматургның иң соңгыларыннан булган бу сәхнә әсәренә мин бәя бирергә җыенмыйм. Заманалар бәя бирер. Әмма «И мөкатдәс моңлы сазым»ны театрның борып кайтаруы турында әйтми кала алмыйм. Һәрвакыт һәркем белән мөлаем елмаеп сөйләшә торган, җитмеш тугыз яшен тутырган, җилфердәп тора башлаган картның күз яшьләре беркайчан да хәтеремнән чыкмас. Юк, үз пьесасына тискәре бәя алудан түгел, аның белән чакырып та сөйләшмичә, ни өчен сәхнәгә менгерә алмаганнарын аңлатып та тормыйча, бер тәкъдим дә әйтмичә кире боруларына хәтере калып елады карт драматург. Бу хәлләрдән соң театрларыбыз сәхнәләрендә бик күп яңа пьесалар рампа уты күрде. Аларның күбесе хәтердә дә юк инде — хәзерге бер көнлек эстрада җырларын йоткан кебек, аларны да җил йотты. Тукайга багышланган сәхнә шедеврлары да әлегәчә тумады...

1983 елда Риза Ишморатка 80 яшь тулды. Олы драматургны ихтирамлап, «Казан утлары» журналы «И мөкатдәс моңлы сазым» пьесасын бастырып чыгарды. Әсәр укучыларны битараф калдырмады — журнал һәм драматург адресына матур-матур хатлар килде. Аларның авторлары күбесенчә укытучылар булганын да ачык хәтерлим, чөнки мин ул вакытта «Казан утлары»ның баш редакторы идем һәм редакциягә килгән барлык хатларны үзем укып бардым.

Ул елларда Татарстан язучылары белән Башкортстан язучылары бер-берсенә еш кына кунакка киләләр иде. Хәзер бу матур көннәрне сагынып сөйләргә генә калды, ахры... Мостай ага Кәрим Казанга килсә, берничә өйдә кунакта була. Мостафа агага ияреп, минем Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники өйләрендә булганым бар. Казанга килгәнен ишеткәч, алар Мостафа аганы үзләре чакырып алалар. Ә Хәсән ага Туфаннарга һәм Риза абзыйларга Мостафа ага үз инициативасы белән бара. Чакырсалар да, чакырмасалар да... Чөнки бармый кала алмый. Әлбәттә, алар да Уфа кунагын сагынганнар, зурлап каршылыйлар, олы табын коралар... Мостафа ага берничә тапкыр Аккош күленә дә килгән. Соңгы тапкыр, хәтерем ялгышмаса,

Ишморатларда (Лесгафт урамындагы йортта) Мостафа ага 1992 елның августында булды. Риза абзый Уфа хәлләрен, андагы таныш-белешләре турында сорашты, Мостафа ага сизелер-сизелмәс юмор белән аңа җавап кайтарды. Риза абзый тыйнак кына кеткелдәп көлә-көлә тыңлады. Аннары фронтовиклар, гадәттәгечә, сугышта күргәннәрен искә төшереп утырдылар, төрле иҗат йортларында, язучылар съездларында, Казан, Уфа премьераларында очрашуларын, андагы гәп-әңгәмәләрне хәтерләренә китерделәр. Ул вакытта Риза абзый шактый хәлсезләнгән иде инде. Колагы да катыланган, күзләре дә тоныкланган иде. Ә хәтере искиткеч якты. Бигрәк тә илле-алтмыш ел элек булган вакыйгаларга... Мостафа абыйны озатканда, Риза абзый аның белән бәхилләшә башлады. Рәисә апа аны « Юкны сөйләп торма әле монда!..» дип туктатты, аннары Мостафа ага, Риза абзыйны кочаклап алып, «Без әле әүвәл синең туксаныңны бәйрәм итәчәкбез, бәйрәм итә-итә йөзеңә дә җитәчәкбез!..» дип, уенга борды. Риза абзый «Туксанга хәтле көч бар әле анысы...» дип егетләнде, ләкин аның елмайган күзләреннән караңгы, дымлы нурлар агыла иде. Өч елдан соң, вәгъдәсендә торып, туксан еллык юбилеен үткәреп, язу өстәлендә башланган әсәрләрен калдырып, Риза абзый мәңгелеккә китеп барды.

Вафатына бер ел калгандарак, Риза абзый, сөйләшәсе бик мөһим сүзләрем бар дип, мине өенә чакыра башлады. Күп тапкырлар вәгъдә бирдем, ләкин озак вакытлар аның янына керә алмадым. Ул елларда минем вакытым бик тыгыз иде, чөнки «Татарстан хәбәрләре» гәзитенең баш редакторы булып эшли идем. Өстәвенә Татарстанның халык депутаты вазифалары... Шулай да мин аның Лесгафт урамындагы фатирында булдым. Озак-озак кына сөйләшеп утырдык. Беренче сөйләшү 1994 елның 24 мартында, сишәмбе көнне булды. Өч бүлмәле фатирның берсе Риза абзыйның йокы бүлмәсе дә, эш кабинеты да иде. Андагы зур шкаф китаплар һәм бәйләп-бәйләп куелган төрле зурлыктагы, төрле төстәге папкалар белән шыгрым тулы. Кайберләре саргаеп кына түгел, вакытлар кагылудан көрәнләнеп тә киткән. Шундый папкаларның берничәсе язу өстәлендә ята... Риза абзый ул елларда урамга сирәк чыга, Аккош күленә килми, әнә шул кабинетында тыныч кына хатирәләрен яңартып, архивын рәткә кертү белән шөгыльләнә иде. «Тыныч» сүзе бу урында, бәлки, башка сүз белән алмаштырылырга тиештер, чөнки Риза абзыйның күңеленә олы борчулар кереп тулган булган. Сүзен ул шуннан башлады да. Бу әңгәмәне, кызганыч ки, мин стенографик тулылык белән хәтеремдә тергезә алмам, әмма мәгънәсен төгәл итеп язам.

«Миңа инде озак калмады, — дип күрсенде ул. — Архивым зур, күреп торасың... Андагы бик күп нәрсәләр, төрле сәбәпләр аркасында, матбугатка чыкмаган. Бу папкаларда әсәрләремнең вариантлары, төшереп калдырырга мәҗбүр булган өзекләре... Минем шәҗәрәм... Язып бетерә алмаган әсәрләрем... Төрле документлар... Шуларны ышанычлы кулларга тапшырасы иде, үзебез исән чакта... Менә без сине бик күп еллар беләбез, күзәтеп киләбез... Разый булып, безнең архивны үз кулларыңа алып кал инде!.. Безнең өчен иң ышанычлысы — син... Минем күңелем тынычланыр иде...»

Менә шундый минем өчен һич көтелмәгән әңгәмә-тәкъдим булды ул көнне... Мин, Риза абзыйның үпкәләвеннән, рәнҗүеннән курка-курка, барлык дипломатия сәләтемне кулланып, аңа бу эшнең минем өчен мөмкин түгеллеген аңлатырга тырыштым. Мирас комиссиясе эшлисе барлык эшләрне, зур бер иҗатның алдагы язмышын Риза абзыйның күпсанлы туганнары, балалары барында үз җаваплылыгыма мин һичничек тә ала алмый идем. Ләкин Риза абзый бу юлы мине аңламады. Икенче юлы да, өченче юлы да аңламады. Һәм шул килеш булса кирәк, якты дөньядан китеп тә барды...

...Аккош күлендә бер бик юан, тармакланып үскән карт алмагач бар. Ярты гасыр яшәгән бу алмагач әле дә булса ел саен мул итеп җимеш бирә, ял итеп маташмый... Ул безнең тәрәзә каршында үсә. Элек бу тәрәзә Ризаэтдин абзыйның йокы бүлмәсенеке иде. Менә шушы алмагач Яңа елны — 1979 ны каршылыйсы төндә — Казанны камап алган 51 градуслы суыкта да исән калды, ә бакчадагы башка алмагачлар барысы да диярлек шул кышта өшеделәр... Риза абзый шул алмагач төбендә ял итәргә ярата иде. Аның ышыгында кемнәр генә сөйләшеп утырмаган?! Риза абзый үлгәннән соң, 1996 елның җәендә, әлеге алмагачның бер ботагы, алмаларын күтәреп тора алмыйча, сынып төште. Мин бу алмагачның сурәтен, алда ни булмас дип, үземнең дәфтәремә гади автокаләм белән төшереп алдым. Әлеге рәсем минем «Шигырь язган каләм белән» дигән китабымда басылып та чыкты... Без бу чыдам, армый-талмый җимеш биргән алмагачны әле дә «Ишморат алмагачы» дип йөртәбез һәм аңа караган саен гел елмаеп торган, зыялылык үрнәге булган, олы эшләр башкарып та кече күңелле булып калган Ризаэтдин абзыйны күз алдына китерәбез...

*2003*

# Ташлама йөгерүеңне, дулкын!

*(Буага китеп барабыз...)*

> ...бәхетле булганмын мин: нинди
> кешеләр минем туган туфрагыма
> аяк баскан, минем кырларымның
> һавасын сулаган...
> *Мостай Кәрим*

Ә мин үземне бераз башкарак сәбәпләр аркасында бәхетле санап йөри идем — күпме бөек кешеләрнең

туган яки үлгән җирләренә аяк бастым бит: Гете, Пушкин, Лермонтов, Тукай, Дәрдмәнд, Тургенев, Есенин, Бакый Урманче, Нәҗип Җиһанов, Райнис, Альфонс Доде, Хузангай, Ухсай!.. Ә Муса Җәлилнең туган авылы Мостафаны барып күргәч, шундый шигырь яздым:

Һәрвакытта менә шулай була —
рух көчәя, сагыш сүрелә,
бастым исә бөек кешеләрнең
туган яки үлгән җиренә.

Шундый ук хисләрне Мостай Кәримнең туган авылы Келәштә дә кичердем. Анда миңа берничә мәртәбә булырга туры килде. Кызлар тавына күтәрелеп, Мостай учагы ягулар! Аларның чәчрәп менеп киткән чаткылары күкләрдә минутлык йолдыз булып сүнсә дә, минем күңелемдә әле дә булса саклана, балкый ... Күңел күктән биегрәк!

Ләкин бәхетнең Мостафа ага әйткән төре шулай ук зур икән. Синең өеңә игелекле кунак килү бер шатлык булса, ил, дөньякүләм билгеле кешеләрнең туган туфрагыңа, җылы идәнеңә аяк басуы, табыныңнан сыеңны авыз итүе — олы бәйрәм! Әгәр дә андый кеше синең чакырылган кунагың булса?! Мондый очракта инде бәхетнең дәрәҗәсен билгеләү өчен сүз табуы ай-һай авыр була. Шуңа күрә, ахры, мин Мостай Кәрим дигән язучы, җәмәгать эшлеклесе, бүгенге төрки дөньяның иң олпат шагыйре турындагы сүземне, мөгезеннән тотып алып, башлап җибәрә алмый утырам бугай...

*

1992 елның август ахырларында Мостафа ага оныгы Тимербулат белән Казанда булып киткән иде. Ул көннәрдә без «Метеор» белән Болгарга бардык, ерак бабаларыбызның эзләренә басып йөрдек. Ул вакытта Тимербулат мәктәп укучысы гына иде, картатаеның һәр адымын киногa төшереп йөгереп йөрде. Көн гаҗәеп җилле булды — диңгездә генә йөгерешә торган чал дулкыннар безне Казанга алып кайтасы «Метеор»га пристаньга якынлашырга бик озак ирек бирмәделәр. Шул дулкыннарга «Бераз гына туктап торыгыз инде — үлмәссез әле!» дип кычкырырдай булган идек... Бәлки, кычкырылгандыр да әле... Шул гаҗәеп көннәр истәлеге булып минем бу олуг шагыйрь турында язган «Исеңдәдер...» циклына кергән шигырем калды.

Аннары ул 2001 елның октябрь аенда шагыйрьләр Рауил Бикбаев, Кадим Аралбаев һәм кызы Әлфия ханым (Тимербулатның әнисе) белән минем юбилеемда катнашты. Исеме дөньяның күп илләрендә билгеле шагыйрь һәм акыл иясе белән бу очрашу да минем күңел канатымны ныгытып калдырган иде...

Шул еллар эчендә тормыш дәрьясының кайбер сулары хәтта кирегә таба акты, җилләр өермәләнеп исте, яшәү рәвешебез, нигез төшенчәләребез үзгәрде. Мостафа аганың оныгы да бүген Мәскәүдәге бер җитди фирманың вице-президенты булып үсеп җиткән... Бу килүендә, Буа районы китапханәчеләре белән очрашканда, Мостафа ага әлеге елларны «кан тамырларымнан кан агып беткәндәй, рух тамырларымнан вакыт агып беткәндәй булды» дип билгеләде. Дөресен генә әйткәндә, аның бу сүзләре мине сискәндереп җибәрде. Тормышның балын да, борычын да потлап татыган, үзен сәясәтнең кайнарлы-суыклы контраст ташкыннарында чыныктырган, түземлек түлен уныбызга җитәрлек итеп туплаган кешедән мин мондый сүзләр көтмәгән идем. Дан, ихтирам, дәүләт игътибары үрләрендә торган шәхеснең төрле катаклизмнардан саклану чаралары көчлерәк, камилрәктер, диеп уйлый идем. Алай ук түгел икән! Аллаһ кушуы буенча шагыйрь итеп яратылгансың икән, синең тамырларыңда үз каның гына түгел, халкың каны да ага. Ул канда кислород кимесә, синең җаның да сызланмый кала алмый... Ләкин безнең алда кан тамырыннан — кан, рух тамырыннан вакыт агып беткән шагыйрь түгел, ә сәясәттә дә, икътисадта да, ярлыларга, байларга, урта хәллеләргә бүленә барган җәмгыятьтә дә, замандашларыбыз психологиясендә дә һәр «усак яфрагы селкенгәнне» сизеп торган, гаҗәеп күзәтүчән, телендә кискенлек һәм әдәплелек балансын саклый белгән, үткен уйлы, киная сүзле, кемнеңдер төгәл эпитеты аша бөтен элеккеге СССРда «мудрый Мустай» дип йөртелгән аксакал иде... Үзгәрешләрнең сагышлылары да аз түгел: теге килүләрендә аны самавыр җырлатып көткән табыннар бу юлы инде корылмаганнар — Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Риза һәм Рәисә Ишморатлар, Гариф Ахуновлар, урыннары җәннәттә булсын, якты дөнья белән хушлаштылар. Аларны искә төшереп, Мостафа ага бераз ямансулап алды. «Казанда да мин аргамак бәйлисе капкалар бетеп бара» дип көрсенеп куйды һәм:

— Бездә хәзер иң карт язучы — мин, ә сездә кем? — диде.

Мин күңелемнән язучыларны барлый башладым.

— Сафа абзый Сабиров иде — 1915 ме, 1916 мы елгы. Ул да быел вафат булды, — дидем мин.

— Беләм аны. Ул Татиздатта минем ике китабымны бастырып чыгарды, — диде Мостафа ага, — моряк иде ул. — Ә хәзер иң карты кем?

— Әдип Маликов йә Геннадий Паушкиндыр... Ләбибә апа Ихсанова булмаса... Алар да сиксәннәрен уздылар... Соңгы елларда мин белмәгән берәр картны Язучылар берлегенә алып куймаган булсалар...

— Бездә дә әгъзалар саны өч йөзгә җитеп бара бугай... Санның сыйфатка әйләнәсен генә көтәсе калды... Күпме көтәсе икән?.. Әйдә, көтик хәлебездән килгәнчә, — дип елмаеп куйды Мостафа ага. — Ә Әдипне бик хөрмәт итәм... Саҗидә шәп шагыйрә иде... Ләбибә белән Шәрәф Мөдәррисне дә яхшы беләм... Ләбибә — прелесть, ә Шәрәф — парень хоть куда иде, — диде Мостафа ага, русчасын-татарчасын бергә кушып. Күрәсең, хәтере дулкынланганда, ул тәрҗемәгә көч сарыф итүне кирәкле санамады, хисенә тәңгәл сүзләрен туры-

дан-туры җиткерде. Бу юлы ул сүзләр русча булды.

Сүз уңаенда бер күзәтүем белән дә уртаклашыйм әле. Миңа Мостафа аганың русча сөйләгән чыгышларын ишетергә, сөйләшкәнен тыңларга, рус телендә язган мәкаләләрен күпләп укырга туры килде. Үзем дә кайчандыр рус теле укытучысы булганлыгыма таянып әйтә алам: Мостафа аганың русчасы татарда, башкортта, чувашта еш очрый торган тәрҗемә русча түгел, ә табигый рәвештә агыла торган, төрле төсмерләргә, фразеологик әйләнмәләргә, мәкальләргә, анекдотларга бай, уйда туганда ук русча булып туган сыгылмалы тел. Ә аның татарчасы турында мин тагы да сокланыбрак сөйли алыр идем. Башка төрки телләрне дә яхшы белүе, башкорт теленең остасы булуы Мостафа агага, гарәп, фарсы алынмаларыннан, хәтта латин терминнарыннан гадәттәгедән кимрәк файдаланып, үзенең татарчасын төркирәк итәргә, аңлаешлырак итәргә мөмкинлек бирә. Бу темага нигә болай тәфсилләп тукталдым соң әле мин? Беренчедән, соңгы елларда татар теленең сәяси, икътисади, иҗтимагый, юридик (карагыз әле: бер генә сүз дә татарча түгел!) терминнарын барлау белән шөгыльләнгән, хәтта сүзлек туплашкан кеше буларак, миңа Мостафа аганың татарчасы шушы җәһәттән бик кызыклы булып күренде. Безгә, терминнар эзләгәндә, башка төрки телләр хәзинәсеннән дә кыюрак файдаланырга кирәктер, мөгаен. Икенчедән, Мостай Кәрим шигырьләренең һәм прозасының поэтик үзенчәлекләренең берсе, һичшиксез, күптеллелек нигезендә ешрак барлыкка килә торган хикмәтле сүз әйләнешләре, шулардан яралган «үлемечле хәсрәт», «ачлык имезеп яту», «җирдә яшәп туймас өчен яратылган кеше» кебегрәк метафоралар. Өченчедән, кызганыч ки, бездә татарча иҗат иткән язучылар арасында тагын бер телне яки икене камил белүчеләр элегрәк тә юк иде, хәзер дә бармак белән генә санарлык. Андыйлар яңа кабул ителгән әгъзалар арасында булса — бик һәйбәт, дип, аларга төрле яклап үсәр өчен мөмкинлек бирергә кирәк, тараеп бара торган әдәбиятыбызның офыкларын шундыйлар тизрәк һәм уңышлырак киңәйтерләр, дип әйтәсем килде.

Буа белән Казан арасындагы ике сәгатьлек юлны без «Тойота»ның арткы урыннарында тоташ әңгәмәдә уздык. Мостафа аганың кызы Әлфия ханым безгә комачауламыйча, алгы урында барды, ә фотокорреспондент белән минем улым Әмир башка машинада иделәр. Мостафа абый сорашты — мин сөйләдем, мин сораштым — ул сөйләде. «Йә, аңлата алдыммы?» дия-дия, күп нәрсәне тәфсилләп аңлатып бирде.

— Салават Юлаевның 250 еллыгы ничек узды? — дип сорадым.

— Бик югары кимәлдә узды, ул бит безнең Беренче башкорт, милләтнең символы.

— Сезнең чыгышыгыз барысына да ошап бетмәгән икән дигән хәбәр килеп җитте Казанга.

— Мин үз алдыма беркайчан андый максат куймыйм да...

— Ә шул бәйрәмдә үзе катнашкан ИЯЛИ директоры Нурмөхәммәт Хисамов сезнең чыгышны бик тә олыдан бәяләде, Салават образын антик мифлар югарылыгына күтәргәнсез диеп сөйләде.

— Бусы дөрес... Ләкин Салават мифик Алла түгел... Һәм була да алмый... Ләкин без аңа горурлыгыбыз символына әйләнгән каһарманыбыз, шагыйребез, халкыбызның хыял тупланышы дип табынабыз... Салават безнең сәнамыбыз, идолыбыз... Мин аны шулай дип атасам да, атамасам да, Салаватны әлеге югарылыкка халык үзе күтәргән, аны үзенең аң символына, төшенчәсенә әверелдергән... Ә халык мифларсыз, идолларсыз яши алмый. Ансыз яшәсә, рухы сүнәчәк...

Нәрсә турында гына сөйләшмәдек без! Театрларыбыз, аларның репертуары да, эстрада сәнгатенең миллилектән ераклаша баруы да, әсәрләребезне тәрҗемә итү мәсьәләләре дә, газета-журналларыбызның азаеп, хафага салган тиражлары да, талантларны яшьли ега торган эчкечелек афәте дә безне бер дәрәҗәдә үк борчый икән.

— Бездә хәзер егетләрчә сөйләшерлек язучылар азая бара. Аларның да күбесе шагыйрәләр, — дип куйды Мостафа ага.

Юл буе яңгыр коеп торды. Мин, чыланып яткан күпьеллык үлән покосларына ымлап, «Харап итә инде...» дип, артык еш яуган яңгырлардан зарланып алдым. Мостафа ага «Яңгырлы елны ачлык булмый ул...» дип, Башкортостанда инде күптән яңгырлар булмавы хакында, халыкның курка башлавы турында борчылып сөйләде. Әлфия ханымнан хәзер үк «мобильник»тан Уфага шалтыратып яңгырлар хакында белешүен үтенде. Әлфия ханым шалтыратты, ләкин куанычлы хәбәр әйтмәде...

— Ә Буада яңгырлар күперләрне агызды, иген кырларын юып төшерде, — дидем мин...

Чуваш әдәбиятына да кереп чыктык. Мостафа ага чуваш әдәбияты һәм язучылары проблемаларыннан да хәбәрдар икән. Язучылар оешмасының яшь рәисе Валери Тургайның күп кенә эшләрен хуплап телгә алды: «Булдыра бит, таркалып бетә язган оешманы яңадан туплап бетерде! Энергичный егет...» — дип мактап алды.

Мостафа аганың данлыклы якын дуслары Рәсүл Гамзатов, Чыңгыз Айтматов, Кайсын Кулиев, Давыт Көгелтиневләрне дә искә төшердек. Мостафа ага аларны гомумән бик еш телгә ала, бергә булган кызыклы хәлләрне сөйли, әсәрләреннән цитаталар китерә. Ул мәшһүр язучылар белән мин дә күп тапкырлар Мәскәүдә дә, Казанда да, Уфада да очрашканым-сөйләшкәнем булды.

— Чыңгызның хәле яхшыра, телефоннан сөйләштем — инфаркты әллә ни каты булмаган, — диде Мостафа ага. — Давыт белән бу араларда гына сөйләшкәнем булмады... Рухлар якын, дуслык исән, шәһәрләребез, кем әйтмешли, элеккеге урыннарында, ә һаман ераклаша барабыз, ераклаша барабыз, — дип көрсенде ул.

— Ишетүемчә, Президент Путин өченче ел Рәсүл Гамзатовны, Сезне, Давыт Көгелтиневне Сочига чакырган иде. Сез бармадыгыз бугай...

— Дөрес, ул очрашу Рәсүлгә 80 яшь тулу уңаеннан оештырылган иде... Ләкин мин ничектер бармый кал-

дым... Рәсүл дусымны җирләүдә катнаша алмадым, менә бусы аяныч... Аны хатыны Патимат янына күмгәннәр...

Шактый гына сүзсез бардык. Мостафа ага, машинаның ян-ягыннан артка таба йөгергән манзараларга карамыйча, үз эченә чумды, уйларына батты. Беравыктан әйтеп куйды:

— Рауза апаң каберенә барып кайттым әле... Мин бит анда ике урынлы «хрущёвка» алып куйган идем. Бик матур урында... Үземә дә ошап китте, — диде ул, күзләре, битләре, иреннәре белән рәхәтләнеп елмаеп... — Шулай, үлем турында шаяртырга кирәк ул... Мин бит инде аның кочагында ике мәртәбә булган кеше... Ул миңа куркыныч түгел, мин аңа тыныч карыйм хәзер... Куркыныч түгел, ләкин аяныч... Соңгы айларда сәяхәтләрем язмаларын актарып утырдым әле. Ай-һай күп йөрелгән, кемнәр белән генә очрашылмаган! Эшкәртергәме инде аларны, юкмы, дип аптырап торам әле...

— Эшкәртергә, эшкәртергә!.. Сез үзегезнең кем икәнлегегезне онытасыз, ахры, — дип, мин Мостафа агага аның башкорт, татар, Россия әдәбиятында-сәнгатендә генә түгел, бөтен төрки һәм аннан киңрәк дөнья мәдәниятендәге кабатланмас олы урынын билгеләргә керештем. Ләкин ул миңа артык иркенәеп китәргә ирек бирмәде.

— Үземнең кем икәнлегемне мин беләм, — диде ул, — мин киләчәкнең нинди буласын белмим. Нинди кешеләр килер? Кирәк булырмы аларга мин язганнар, мин күргәннәр, минем тормыш тәҗрибәм? Кешедә бит ике төрле хәтер бар: яманы, яхшысы... Безгә карап, безгә карата алар нинди хәтерләрен эшкә җигәрләр? Бу мәсьәләдә безнең заман киләчәккә матур үрнәк күрсәтә алмады...

Шулай сөйләшә-сөйләшә, без Буага барып җиткәнебезне сизми дә калганбыз...

*

Буа безне чәчәкләр һәм чәкчәк, телекамералар белән район чигендә үк матур итеп каршылады. Район хакимиятенә барысы өчен дә рәхмәт, ләкин беразга булса да яңгыр кранын гына ябып куя алмаганнар... Юл уңаеннан гына төзелешләрне, яңа спирт заводын карадык һәм мин укып тәмамлаган А.В.Луначарский исемендәге мәктәпкә килдек. Бу мәктәпкә мин үземнең рәсемнәрем күргәзмәсен бүләк иткән идем. Аларны бер кабинетка туплап, эстетика классы ясаганнар. Мостафа ага шул рәсемнәр белән танышты. Аннары каникул башлануга да карамастан җыелган укытучылар белән әңгәмә булды. Мин әдәби остазым Мостай Кәрим алдында үзем укыган мәктәп укучылары өчен өч премия булдыруым турында хәбәр иттем: берсе — әдәби иҗатта, икенчесе — рәсем сәнгатендә, өченчесе — музыкаль йә үзешчән сәнгатьтә ирешкән уңыш өчен. Бәлки, минем премияләр укучылар игътибарын сәнгатьнең әнә шул төрләренә төгәлрәк юнәлтерләр дип эшләгән эшем иде бу үзенә күрә. Белмәссең, киләчәктә нәкъ менә минем лауреатлар арасыннан Буа районының данын тагын да биеккәрәк күтәрүче язучылар, рәссамнар, музыкантлар үсеп чыгар... Иншалла!..

Мостафа ага укытучыларның сорауларына кызыклы-кызыклы җаваплар бирде, алдагы иҗат планнарының бер читен генә булса да ачып күрсәтте, шигырьләрен яттан укыды, бер мәктәп балаларының «Аю һәм башка кошлар» дигән китап язулары хакында сөйләп көлдерде. Әлбәттә, минем иҗатыма булган мөнәсәбәтен дә, Казанга һәм Буага минем чакыруымны ихтирам итеп килгәнлеген дә әйтергә онытмады.

— Рәхмәт Ренатка, ул мине үзенең әдәби остазы дип саный, — диде ул, — бу аның эше. Әлбәттә, андый шәкертең булу күңелле нәрсә... Укучы үзенә укытучы сайлый ала. Ә менә шагыйрь беркемне дә үзенең шәкерте дип саный алмый. Хакы юк... Шагыйрь, асылда, шагыйрь булып туа һәм аны беркем дә шигырь язарга өйрәтә алмый...

Бу сүзләре белән Мостафа ага миңа Кено дигән француз шагыйренең шаян шигырен исемә төшертте, ләкин мин ул чагында аны хәтеремдә торгыза алмадым. Менә ул шигырь:

Сүзне нигез итеп ал,
аны көчле утка сал,
бер чеметем акыл сип,
арттырып җибәрмә тик,
куш йолдыз, борыч, тирәк,
хисчән самими йөрәк.
Ә эшнең азагында
осталык казанында
кайнат барсын төн вә көн,
һәм яза башла... Ләкин
бер шартны да тор белеп —
шагыйрь булып ту элек...

Шуны сөйләп җибәргән булсам, нинди урынлы булыр иде!.. Ләкин мин Мостафа ага фикерен үземчә дәвам итеп киттем, чөнки Мостай Кәрим дигән шагыйрьнең һәм аның иҗатының кайсы яклары миңа йогынты ясаганлыгын остазның үзенә әйтергә, ниһаять, нинди матур җай чыкты!.. Бу темага озаклап тукталып, чагыштырулар, параллельләр китерә-китерә, мисаллар белән нигезли-нигезли, тәфсилләп сөйләп булган булыр иде. Андый эшне киләчәк буын әдәбият белгечләренә калдырып (бәлки, бүгенгеләренә дәдер!), мин фикеремнең йомгагын гына әйттем: Тарих, сәясәт һәм фәлсәфә эретмәсеннән хасил дәүләти фикерләрне хәтта беләме түбән булган кешеләргә дә аңлаешлы итеп җиткерү сәнгатенә яки, башкача итеп әйткәндә, сәяси җые-

лышлар җитдилеге белән дуслар табыны ихласлыгын шигырь юлларында бергә кушу осталыгына ирешүдә миңа Мостай Кәрим иҗаты иң якын үрнәк. Немец Гёте, руслар Державин һәм Тютчев та миңа ерак түгел. Ә Мостай Кәрим иҗаты — үз замандашым һәм тел кардәшем үрнәге!

Остазлык, әлбәттә, моның белән генә чикләнми. «Ташлама утыңны, Прометей!» авторының антик мифологияне бүгенге көн проблемаларына эшләтә алуы да, «Салават» трагедиясен язган әдипнең көрәшкә милләт язмышы күзе белән карый белүе дә, «Ай тотылган төндә»трагедиясенең гади, аңлаешлы вакыйгалары аша вөҗдан азатлыгы дигән үтә катлаулы философик категорияне һәр йөрәк төшенчәсе итеп күтәрүе дә, кечкенә генә вакыйганы тирән мәгънәле метафора итеп җәеп салу осталыгы да, бүгенге сәяси очкыннан киләчәктә нинди янгын чыгачагын хөкемдарлар күзенә бәреп әйтергә курыкмавы да миндә соклану һәм үрнәк алу теләге тудыра.

Кыскасы, прозада — Шагыйрь, шигырьдә — Драматург, драмада — Философ булган Мостай Кәрим һәр җитди язучы өчен иҗат һәм гражданлык университеты була ала.

Буа китапханәсендә дә бик ихлас очрашу булды. Мостафа аганың, нинди аудитория белән очрашмасын, кеше күңелендәге бикләрне алып, ишекләрен шар ачтыра ала торган ниндидер көче-тылсымы бар. Китапханәчеләр бик күп сораулар бирделәр, Мостафа ага, тормыштагы төрле хәлләрдән мисаллар китерә-китерә, җаваплар бирде. «Бүгенге көндә нинди әсәр язасыз? Шигырьме, прозамы, пьесамы?» дигән сорауга ул «Бүгенге көндә бернәрсә дә язмыйм, сезнең каршыгызда утырам...» дип җавап бирде елмаеп. Аннары, җитди тонга күчеп, хәзер инде шигырьләрне азрак язуы, күбрәк истәлекләрен тәртипкә китерүе, шулардан чыгып «Гомер мизгелләре» дигән китабының дәвамын язуын сөйләде.

— Мин бик күп яхшы, акыллы, көчле кешеләр белән очрашканмын икән гомер юлларымда, төрле-төрле вакыйгалар шаһиты булганмын, — диде ул. — Менә шулар турында язам соңгы айларда...

— Ә начар кешеләр очрамадымыни?

— Андыйлары да шактый очрады, ләкин алар турында исемләп язмыйм, минем әсәрләремдә мәңгеләшмәсеннәр әле... — диде Мостафа ага, елмаеп. — Әлбәттә, начарга карап та файдалы нәтиҗә чыгарып була, ләкин күбрәк яхшыдан үрнәк алыйк әле.

*

Юлда килгәндә үк Мостафа ага: «Без нинди районга барабыз соң? Буа нәрсәсе белән билгеле?» — дип сораган иде. Өзлексез яуган яңгыр аккомпанементына кушылып, мин, хикәяләү белән генә чикләнмичә, Буага ода, кантата ук җырладым булса кирәк. Аның икътисади яктан да, ашлык җыюда да, төзелеш буенча да республикабызда алдынгы урыннарда икәнен әйттем. Татарда беренче сатирик журнал «Карчыга»ның баш мөхәррире Шакир Мөхәммәдев, Тукайның иң беренче китабын бастыручы Шәрәфләр, шулар нәселеннән чыккан композитор Алмаз Монасыйпов, җәлилче Фоат Булатов, лингвист Галимҗан Шәрәф, язучы Җәвад Тәрҗеманов турында кыскача мәгълүмат бирдем. Районыбызда туып үскән язучыларыбыз Гомәр Толымбайскины, Гомәр Галины, Шәриф Хөсәеневне, Әхмәт Рәшитовны, яшьли киткән Тәүфикъ Камалиевны, чуваш язучыларыннан Н.Дедушкинны, В.Ухлины, К.Петровны, А.Калганны, В.Урдашны да искә алдым, декабрист Ивашовны да, Мао Цзе-Дунның күп урынбасарларының берсе булган Борһан Шаһидине дә онытмадым, дәүләт эшлеклеләре, академиклар, профессорлар, министрлар, композиторлар, рәссамнар, Дәүләт премияләре лауреатлары да читтә калмады. Мостафа аганы мин әнә шуларның эзләре буйлап бераз гына булса да йөртмәкче идем, коеп торган яңгыр моны эшләргә ирек бирмәде. Шулай да без Казма авылына барып кайтырга булдык, чөнки анда минем бабамнар нигезе, әнием кабере, әтием салган йорт! Анда туган-тумачаларым чәй әзерләп көтеп торалар. Ә колхозыбыз үзәге булган Килдуразда — олы кунак хөрмәтенә кайдадыр ямьле Зөя елгасы буенда корылган табын...

Черкенгә килеп кергәч, Мостафа ага:

— Шушымы синең Казмаң? — дип сорап куйды.

— Юк әле... Әнә теге йортта академик Фуат Гарифуллин туган, — дидем мин, машинаның сул тәрәзәсенә төртеп. — Бу — Бакый Урманче туган Кул Черкене авылы.

Мостафа ага авыл өйләрен җентеклəбрәк карарга кереште. Авыл уртасына килеп туктадык. Монда элек мәчет иде, хәзер — мәктәп. Мәчет мәйданы күршесендә кайчандыр Идрис мулла йорты булган. Шунда татар халкының мәшһүр рәссамы һәм сынчысы Бакый Урманче дөньяга килгән. Ул урында карт агачлар үсеп утыра, аларны бүген җилле яңгыр айкый.

— Беләм мин ул мәһабәт картны, күп аралашырга туры килмәсә дә, беләм, — диде Мостафа ага.

Чиләкләп үк булмаса да, иләкләп койган яңгырны ерта-ерта, безнең өч-дүрт машинадан торган кортежыбыз Казмага таба юл алды. Ике авыл арасы — ярты гына чакрым. Черкен Казмага таба үсә, ә Казма Өчмунчага (Шәриф Хөсәенев туган авыл) таба үсә. Бүген анда 60–70 йорттан ары юктыр. Бу авылдан 4 профессор чыккан, шуларның берсе — химик Р.В.Гафиятуллин — СССР Дәүләт премиясе лауреаты, икенчесе — Ә.Б.Халидов — Коръәннең татарчага беренче фәнни тәрҗемәсен башкарган, гомер буе Санкт-Петербург университетының академик И.Ю.Крачковский исеме белән бәйле кафедрасында эшләгән галим. Кызганыч ки, әлегәчә бу хезмәтнең нәшер ителгәне юк бугай...

Такыр юлдан мәчеткә хәтле килеп җитеп тукталдык. Дегет кебек сыегайган кара туфраклы урам буйлап тагы да хәрәкәт итеп булмады. Автомобилебезнең тәрәзә сөрткечен кызуракка куеп, мин Мостафа агага төп йортыбызның яктырып күренеп торган түбәсен күрсәттем.

— Аһ, төп йортыбызга аяк бастыра алмадым, ахры, инде!

Йөземдә, күрәсең, яшереп кала алмаслык үкенеч булгандыр. Мостафа ага мине юатырга кереште:

— Мин бик канәгать, Ренат, борчылма, — диде ул, — мин инде бөтен нәрсәне күземә сеңдереп кала торган яшьтә түгелмен. Синең нигезең, Бакый Урманче җире минем рух хәтеремә сеңде... А это для меня важнее, — дип өстәде, русчалап.

— Нигез дигәннән, Мостафа ага, без менә хәзер чын мәгънәсендә төп нигезебез янында ук торабыз. Минем ерак бабайлар да мулла булганнар бит. Садыйк мулла исемле бабабыз бу авылда кырык елдан артык муллалык иткән... Әнә, мәчеттән бераз арырак, безнең нәселнең төп йорты булган. Әтием П хәрефе рәвешендә салынган өйдә үскән. Аннары, Пның бер аягын сүтеп, балалар бакчасы салганнар. Мин белгәндә, өебез инде Г хәрефе кебек кенә иде: бер канаты — клуб, икенче канаты — мәктәп. 1948 елны беренче сыйныфта мин шунда укып йөрдем...

— Алай булгач, синең борчылуың гомумән урынсыз... Дәвам итик сәяхәтне...

Һәм без, күлдәвек суларын Казма хөрмәтенә фейерверк итеп чәчрәтә-чәчрәтә, Буага кайтып киттек, ә Буадан — «Орхидея» мотеле, аның мунчалары, биллиард заллары һәм тәмле табыны аша — Казанга.

Юл өсли генә язучыларның Аккош күле дип аталган иҗат йортларына кереп чыктык. Равил Фәйзуллин һәм Җәүдәт Сөләйманны очраттык, фотога төштек. Мин Мостафа агага Хәсән Туфан яшәгән өй янында фотога төшәргә тәкъдим ясадым.

— Аның өендә мин берничә мәртәбә булдым, — диде ул, җимерелеп бара торган өйгә моңсу гына карап. — Бу дачаның балкып торган чаклары бар иде... Кайсыдыр елны мин Горькийдан Уфага өр-яңа ак «Волга» куып кайтышлый, бирегә тукталган идем. Бик матур, икебезнең күңелендә дә һәрвакыт саклана торган очрашу булган иде. Шуннан соң Туфан, миңа багышлап, «Аккош күлендәге ак каенга пегасыңны бәйләп куясың...»дип шигырь язды, минем ап-ак машинага ишарәләп... Юк, Туфан өе янында фотога төшмим, анда шагыйрьнең нуры сакланмаган... — диде. Һәм төшмәде.

*

21 июльдә Мостай Кәрим Кремльдә республикабыз Президенты М.Ш.Шәймиев белән очрашты... Сәясәттә дә, сөйләшүләр алып баруда да, кеше психологиясен белүдә дә азау ярган бу ике шәхеснең сәгать ярымга сузылган матур хатирәләр болыннары, сәясәт чытырманлыклары аша узган һәм күңелле, һәм җитди әңгәмәсе аерым тасвирлауга лаеклы. Җае чыккач, анысын да эшләрбез әле...

Шул ук көнне Мостай Кәрим «Татарстан Яңа Гасыр» телекомпаниясенә бер сәгатьлек интервью бирде. Вакыты белән кискен, вакыты белән мәзәкчел, ә тулаем алганда — тирән мәгънәле фәлсәфи фикер алышуны без, Алла бирсә, телевизорлардан тыңларбыз. Хәзер татар телевидениесен бөтен Россиядә генә түгел, хәтта Европаның кайбер илләрендә дә карап була.

Иртәгесен алар Уфага кайтып киттеләр.

*

Идел комаягындамы, диңгез пляжындамы, күбебезнең күргәне бар — зур дулкын килә дә, вак дулкыннар барып җитә алмаган җирне сугара, ташларын кузгата, үсемлекләрен чайкалта да, яңа көч тупларга дип булса кирәк, диңгезенә, Иделенә кабат кереп китә. Андый дулкынның дымы аннары елтырый-елтырый, озын-озак итеп ярга сеңә...

Мин ул шундый яр!.. Оренбург юлында саубуллаштым да, кул изәп янымда басып торган хатыным Лилия һәм улым Әмирдән дымлы күземне яшереп, Шагыйрьне Казаннан алып киткән, һаман кечерәя барган «Тойота»га түгел, ә ерагайган саен зурая барган Дулкынга карап торам. Мостай Кәрим дигән Дулкынга!

Мин ул шундый яр... Минем күңелемә чемерди-чемерди фәлсәфи җылы дым сеңә... Асларын күптән инде саф сулар юмаган, шунлыктан мүкләнә башлаган, авыр ташларым җиңеләйгән кебек булып китте, инде төклетуралар, күбәләкләр кунмый башлаган чәчәкләремә сут йөгерде...

Эчтән генә — күңел тавышы белән генә — шагыйрь Икбальнең «Дулкын» дигән шигырендәге «Я существую на бегу! Не на бегу — не существую...» дигән юлларын кабатладым һәм, дога итеп, «Ташлама йөгерүеңне, Дулкын!» дип пышылдадым...

*Июль, 2004*

# Мин ни сәбәпле язучы булып киттем?

## I

Минем әнием дә, әтием дә укытучылар. Әтием гомере буе татар әдәбияты укытты. Миңа 10–11 яшьләрдә алар авыл клубы сәхнәсендә үзешчән спектакльләр куюда катнашалар иде. Шундый чакларда әтинең «Үзем

дә бер пьеса язам әле!..» дип әйткәннәрен хәтерлим. Булачак пьесасы турында ул әнием белән дә киңәшә иде... Мин ул пьесаны шактый еллар күтәп йөрдем. Әтидән, кайчан язасың инде, дип, күп мәртәбәләр сорадым. Ул һәрвакыт вакыты юклыкка сылтый иде. Чынлап та, аның вакыты бик тыгыз булгандыр: сугыштан соңгы елларда гаиләне алып барулар авылда җиңел булмаган. Шул пьесаны көтә-көтә, мин үзем дә, яшереп кенә, ниндидер диалоглар язгаладым. Алар, әлбәттә, югалганнар. Царско сельский лицейда Пушкинны язулы һәр кәгазьне сакларга өйрәткән кебек, мине һәр язмамны сакларга өйрәтүче булмаган, хаҗәте дә булмаган. Мин Пушкин түгел.

Әнием ягыннан дәү әтиемнең туганнан туган энесе — күренекле шагыйрь Максуд Сөендекле. Ләкин менә шул дәү әтиемнең әдәби сәләте булу-булмавына дәлилләрем юк. Ул рәсемгә бик оста иде, майлы буяулар белән ясалган картиналар өй тулы иде.

Моның белән мин ни әйтергә телим? Иҗатчы буласы кеше «кирәгенә күрә ярагы» (на спрос и предложение) дигән иҗади этәргечне тоярга сәләтле булырга тиеш. Бу сәләт аңа геннар аша бирелергә дә, тәрбия аша килергә дә мөмкиндер дип уйлыйм. Сәләтне үстерү йә үтерү — бусы инде мәсьәләләр мәсьәләсе!..

Шул ук елларда мин композитор булырга хыяллана башладым. Әтием Казаннан хромка гармун алып кайтты. Нота белмәгәнлектән, гармун төймәләренә цифрлар сугып, мин берничә көй яздым. Аларны әтиләргә дә уйнап күрсәтә идем. Күрәсең, ул музыка примитив булгандыр, өлкәннәрнең мактавында кояш нурлары бик үк чәчрәвек булмый торган иде. Мин моны тоям, уйланам, борчылам... Гарьләнә дә идем булса кирәк, юкса бүгенгәчә хәтеремдә йөртмәс идем. Мин композиторлык сәләтемнең амбициямнән чагыштыргысыз дәрәҗәдә бәләкәй булуын, бу шөгылемнең перспективасыз икәнлеген шактый тиз аңладым — нота белмәгән, музыкаль белем алмаган килеш музыка язуны ташладым. Һәм бик дөрес иткәнмендер дип уйлыйм, чөнки күрәм — грамотасыз, музыкаль надан кешеләр, тавышлары булмаган «микрофон балалары» булышлыгында, бүгенге татар эстрадасын харап итеп, халкыбызның эстетик зәвыгын бозып яталар. Мин дә шуларның берсе булыр идем.

Моның белән нәрсә әйтергә телим соң? Шуны — иҗатчы булырга җыенган кеше үз сәләтенең үз амбициясенә туры килү-килмәвен вакытында чамалап алырга тиеш. Сәләтең амбицияңә туры килмәслек икән, аңардан күпкә кечерәк икән, син, күпме генә көчәнсәң дә, иҗатның бу тармагында фәкать дилетант, йә булмаса вак кәсепче генә булып калачаксың... Шунысын да әйтим: нәселемдә миндәге геннар белән тоташкан Сәйдәш Гарифуллин кебек күренекле музыкантлар, Фәридә Фәезова кебек чын композиторлар да бар...

Аннары мин рәссам булырга хыялланып йөрдем. Бик күп рәсемнәр ясадым. Әмма авыл шартларында миңа сәнгатьнең бу өлкәсе буенча да профессиональ дәресләр алырга туры килмәде. Шулай да мин, җиденче классны тәмамлагач, Казан сәнгать училищесына килеп карадым. Дөресрәге — мине анда әниемнең бер энесе алып барды. Училище директоры Зуев Евгений Владимирович рәсемнәремә карап торды да: «Жаль, но вы уже на этот год опоздали — приемные экзамены давно кончились, приезжайте на следующий год», — дип чыгарып җибәрде. Ә шул көздә мин Буа шәһәренең А.В.Луначарский исемендәге мәктәбенә укырга киттем. Ул елларда район газетасы каршында Барлас Камалов җитәкчелегендә әдәби түгәрәк эшли иде. Шунда йөри башладым һәм... гәзит бите кадәр гәзит битендә беренче шигыремне күрдем. Башларым әйләнеп, күңелем әллә кайларга очып китте.

Моның белән нәрсә әйтмәкче буламмы? Моның белән мин иҗатчы язмышында очраклылык һәм ирешкән беренче уңышның ни дәрәҗәдә мөһим көчләр икәнлеген аеруча ассызымламакчы булам. Әйтик, шул елларда Буада бер күренекле рәссам яшәсә һәм мин аның кулына килеп эләккән булсам? Рәсемгә һәвәслек миндә әлегә кадәр югалмады бит! Хәтта бер булса да персональ күргәзмә оештыруга кадәр барып җителде. Ләкин мин барыбер профессиональ рәссам булып китмәдем, чөнки рәссамлык сәләте амбициямә караганда бик күпкә түбәнрәк булган, күрәсең...

Шулай итеп, мин махсус белем алуга һәм профессиональ осталыкка бәйле булмаган «җиңел» иҗат өлкәсенә — әдәби иҗат дөньясына — аяк бастым. Ләкин бу ноктадан «Язучы» дигән тау башына кадәр ара бик ерак иде әле.

Мин җаным тәнемә сыймый башлагач, аңым җаным белән сөйләшергә өйрәнгәч, бу әңгәмәне тыңларга теләүчеләр табылгач кына язучы була башладым бугай... Ләкин бу ноктадан да «Язучы» дигән биеклеккә ара бик ерак иде әле — тормыш тәҗрибәсе аз иде... Әйтәсе килгән сүзләрем, мин аларны матур итеп әйтә белсәм дә, иҗтимагый һәм интим көчкә ия түгел иде.

## II

Әдәбият сөючеләр белән очрашулар вакытында еш кына автор һәм аның персонажлары турында сораулар ишетергә туры килә: әсәрнең герое рухи яктан автордан өстенрәк була аламы, автор тормышта — бер, ә иҗатта бөтенләй икенче кеше булып яшиме һәм башкалар...

Бу сораудан «Язучы дигән биеклеккә күтәрелгән автор, әлбәттә, үзенең персонажларыннан бик күп ягы белән өстенрәк була» дип җавап биреп тә котылып булыр иде. Чынлап та, минем фантазиям җимеше генә булып туган персонаж ничек инде миннән акыллырак, кыюрак, булдыклырак була алсын — ул бит, ахыр чиктә, минем акылымның бер бәләкәй кыйпылчыгы гына. Андый персонажлар бер әсәрдә дистәләгән булырга мөмкин, һәм иҗат гомерендә язучының дистәләгән күп персонажлы әсәр иҗат иткәнен дә онытмаска кирәк. Алмагачның бер ботагы бөтен алмагачтан баерак булуы мөмкинме? Ләкин, әйтик, Җ.Тәрҗемановның «Көмеш дага» романындагы Лобачевский роман авторыннан «акыллыракмы»? Муса Җәлил турында поэма-

лар, романнар язган авторлар рухи яктан үз персонажларыннан өстенрәкләрме? Йә булмаса романдагы Лобачевский тормыштагы Лобачевскийдан өстенрәк була аламы? Бу сорауларга ничек җавап бирергә?

Беренче карашка беркатлы булып күренгән бу сорауларга җавап бирүе бик үк җиңел түгел... Аларга очрагына карап кына җавап биреп буладыр һәм ул җаваплар барыбер якынча гына булып чыгачаклар...

Персонаж башлыча язучының идеяләрен, уй-фикерләрен мөмкин кадәр күбрәк, калкурак, тирәрәк итеп күрсәтә алган сыйфатлардан гыйбарәт. Димәк, язучы, әйтик Җ.Тәрҗеманов, Лобачевский персонажын иҗат иткәндә, фәкать үзенә кирәкле буяуларны, детальләрне, сыйфатларны гына алган. Калганнары романга кермәгәннәр. Шулай итеп, персонаж Лобачевский чынбарлыктагы галимнең бер өлеше генә булып чыккан. Ләкин язучы роман персонажын тормыштагы Лобачевскийда булмаган, әмма үз тәҗрибәсендә булган һәм әсәрнең логикасы таләп иткән кайбер нәрсәләр белән баеткан булуы да ихтимал. Мондый өстәмәләр, әлбәттә, зур осталык һәм чамасын белеп кенә эшләнергә тиешләр, һәм моның өчен автор чын язучы булырга тиеш. Юкса һәр өстәмә — алдашу, ялган, уйдырма булып кабул ителәчәк. Персонажың тарихи шәхес булган очракта, шундый уңышсыз өстәмәләр аңарга яла ягу булып чыгачак.

Язучы үзенең персонажларына үзендә булмаган һәм уңай, һәм тискәре сыйфатларны да бирә. Моңа мисаллар — һәр әсәрдә. Әгәр дә язучы каракны, сукбайны йә бер җинаятьчене әсәренең персонажы итә икән, аның үзен дә шул сыйфатларга ия дип әйтергә бер нигез дә юк. Язучы бик еш кына үзенең идеалын сурәтли — Чернышевский, Тургенев йә Фатих Әмирхан кебек. Чын язучы үз җанына тормыштагы теләсә нинди кешенең тәнен киеп карый ала, әсәрендә шул шәхес булып уйлый, хыяллана, яши. Ул аларны аңлый, җанына кертә, ләкин үзе булып кала.

Язучының җанында персонажлар ничаклы күп булса, ул шуның чаклы бай, көчле һәм кызыклы. Ә язучының үзенә исә шул персонажлар армиясенең чыңгызханы булу олы канәгатьлек хисе китерә. Менә бер персонажыңны җибәреп, укучыларың күңелен яулыйсың, менә икенчесе, өченчесе... унынчысы белән... Ләкин үзең тудырган кайбер геройлар, көтмәгәндә, үзеңә буйсынмый башлыйлар. Дөнья әдәбиятында да, татарныкында да моңа мисаллар шулай ук күп... Син персонажыңны яшәтмәкче буласың, ә ул үлеп китә, синең аны көчле итеп күрәсең килә, ә ул сына, түшенкелеккә бирелә... Үзенә буйсынмаган, баш күтәргән, әсәрнең агышын борып җибәргән, башка персонажларның яшәешен үзгәрткән герой тудыру — язучының олы уңышы. Ә моңа ирешү өчен тулы канлы, төгәл характерлы әдәби геройны, тормыш логикасы белән кораллandырып, әсәр дөньясына табигый итеп кертеп җибәрү осталыгы кирәк. Әйтик, Шәриф Хөсәеневнең «Әни килде» драмасындагы персонажлар йә Туфан Миңнуллинның Әлмәндәр карты, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах, Хисам Камал, Мөхәммәт Мәһдиев, Әхсән Баян персонажлары, һичшиксез, авторлар ихтыярыннан башка яшиләр, авторлар төп геройларының язмышларын үз теләкләренә буйсындыра алмыйлар, чөнки ул геройлар яралмыштан тормышчан һәм төгәл булып туганнар.

III

Әсәрне дөньяга китерүче сәбәпләр һәм көчләр бик күп. Язучы, әлбәттә, күңеле кушканны, йөрәге сораганны яза. Ләкин аның йөрәгенә һәм күңеленә «иҗади боерык» бирүче һәм язучыны каләм алырга мәҗбүр итүче көч күңелнең тышкары ягында, ягъни чынбарлыкта: вакыйгада, хәбәрдә, күзәтүдә... Язучының, бигрәк тә башлап язучының, игътибарын иң тиз җәлеп итә торган вакыйга, әлбәттә, йә куанычлы уңыш, йә коточкыч фаҗига. Бу вакытларда шәхес һәм җәмгыять олы стресс кичерә, бигрәк тә фаҗига вакытында. Фаҗига — югалтулар белән, ә югалту — кызгану, үкенеч, юксыну, сагыну кебек иң көчле хисләр белән бәйле. Фаҗиганең сәбәпчесе кеше, төркем, ил булганда, аларга карата ачу, нәфрәт, үч кебек актив хисләр туа. Әлеге хисләр, әйтик, мәхәббәт хисенең сизелер-сизелмәс мең төсмере белән чагыштырганда, бик күпкә җетерәкләр, кискенрәкләр, калкураклар, һәм алар белән «эш итү» дә бер караганда җайлырак кебек.

Әдәби очрашулар вакытында кайберәүләрнең «Муса Җәлилне фаҗига бөек шагыйрь итмәдеме?» дигән сорау бирүләре урынлымы, түгелме? Әлбәттә, урынлы. Әгәр тә Муса Җәлил фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелмәсә, аның «Моабит дәфтәрләре» булмаса, ул үзгәрәк шагыйрь булыр иде... Ләкин җәлилчеләр арасында Мусадан башка да шагыйрьләр булган бит!.. Аларның шәхесләренә дә бер үк фаҗига кагылган, үзләрен бер үк төрмә җәберләгән, бер үк гильотина башларын кискән... Берсе дә шагыйрьлектә Җәлил биеклегенә күтәрелә алмаган бит! Бүгенге укучыларның бик күбе, бигрәк тә рус йә башка телләрдә укучылар, Җәлил шигырьләрен шагыйрь язмышына бәйсез рәвештә укыйлар. Шуңа карамастан да шигырьләр аларга көчле тәэсир ясыйлар. «Моабит дәфтәрләре» циклында «төрмә шигырьләре» юк дисәк тә ярый. Төрмәдә Муса Җәлилнең, дөресен әйткәндә, фронтта мөмкинлек булмаганга язылмыйча калган шигырьләре язылган! Муса Җәлил аларны үз фаҗигасеннән өстен була алганга язган! Фаҗига Муса Җәлил шәхесенә игътибарны, кешеләрнең кызыксыну һәм тартылу көчен, һичшиксез, арттырган һәм аның шигырьләренә ниндидер бер трагик ямь биргән. Ләкин шигырьләр, авторның фаҗигасенә бәйсез рәвештә дә, көчлеләр, кешелеклеләр һәм лаеклы рәвештә дөнья әдәбиятының бер җәүһәре булып саналалар. Бу әсәрләрендә шагыйрь һәр кеше өчен дә гыйбрәтле һәм вакытлар үтү белән дә искерми торган рухи казанышларга ирешкән, гади авторны бөек Язучы иткән биеклеккә күтәрелгән.

(Сораулар булса, дәвамы булыр.)

# Шигырь бәйрәменең унбишенчесе

Яз менә инде унбишенче тапкыр безгә Шигырь бәйрәме алып килде. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай

туган көнне, ягъни 26 апрельдә, ел саен үткәрелә торган бу бәйрәмнең хәзер сагынып сөйләрлек үткәне, марур тарихы бар. Үзләре безнең арада булмаса да, Әхмәт Фәйзи, Шәрәф Мөдәррис, Зыя Мансур, Гали Хуҗиев, Әнвәр Давыдовларның тавышлары шул тарих ташларына язылган. Аларга алмашка яңа шагыйрьләр килде. Шигырь бәйрәме һаман үсә, аның тавышы елдан-ел ныгый, офыгы киңәя бара. Аның инде хәзер үткәрү тәртибе, ягъни үткәрү церемониясе, гадәткә кереп бара. Шигырь бәйрәме Казанда һәм республикабыз шәһәрләрендә, районнарында, авылларында традициягә керде һәм чын мәгънәсендә традицион бәйрәмгә әверелде. Аның шулай үсә баруының, халык күңеленең түренә хәтле узуының төп сәбәпләреннән берсе — тормыш, көн белән аваздаш булуы, ил, халык сулышы белән бердәм булуы. Былтыр күпмилләтле илебезнең олы юбилее елында үткәрелгән Шигырь бәйрәме халыклар дуслыгына, әдәбиятлар дуслыгына багышлап үтте. Мәскәүдән, күрше автономияле республикалардан килгән кунаклар, үзебезнең шагыйрьләребез дуслыкка, туганлыкка, Ватаныбызга багышланган иң яхшы шигырьләрен халыкка укыдылар. Быелгы, ягъни тугызынчы бишьеллыкның хәлиткеч елында уза торган Шигырь бәйрәме кешене кеше иткән, көчле һәм бөек иткән хезмәткә багышлана. Соңгы елларда әдипләребез хезмәт темасына, хезмәт кешеләренә аеруча игътибар итәләр. Республикабыз җирендә бара торган гигант төзелешләр, гаҗәеп үзгәрешләр язучының күңеленә йогынты ясый: шагыйрьдән роман яздыра, прозаикка җыр илһамы бирә, журналистны драматург итә. Менә шундый хезмәт быелгы Шигырь бәйрәменең түрендә булачак та инде. Ә аңарга бу хәзерлекне март аенда ук башладык. Казанның барлык культура сарайларында диярлек «Казан язы» дип үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләр Шигырь бәйрәменең старты булды. 25 апрель көнне әдәби кичәләр гадәттәгечә Арча районында, Тукай-Кырлайда узды. Бу да Шигырь бәйрәме программасының һәр елны кабатлана торган даими өлеше, гадәткә кереп, традициягә әверелгән өлеше бәйрәмнең кульминацион ноктасы, финишы булган Шигъри митингның урыны былтырдан башлап алмашты. Ул быел да Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Габдулла Тукай һәйкәле каршында узачак. 26 апрельдә 15 сәгатьтә тамашачылар Тукай премиясенең 1973 елгы лауреатлары чыгышын, Мәскәү, Уфа, Ворошиловград, Пермь, Чабаксардан килгән шагыйрьләрнең әсәрләрен тыңлыйлар. Әлбәттә, үзебезнең шагыйрьләрнең яңа әсәрләре белән дә танышырлар. Китап сөючеләр өчен Шигъри митингта афтограф белән китап сату оештырыла. Анда Татарстан китап нәшриятының һәм үзәк нәшриятларның соңгы елларда чыгарган яңа китаплары булачак.

Әйе! Яз, апрель менә инде унбишенче тапкыр безгә Шигырь бәйрәме алып килде, без унбишенче тапкыр аңа ашкынабыз.

*Апрель, 1973*

## Ватандарлык тамырында — җәлилчеләр

Батырлык — кешенең иң матур сыйфаты. Совет власте өчен, социализм өчен, коммунистик идеяләр тантанасы өчен көрәш чорлар, гасырлар таң калырлык тиңдәшсез каһарманнар тудырды. Гражданнар сугышы чоры батырлары Лазо, Щорс, Азин, Амангельды, Котовский, Чапаев, Бөек Ватан сугышы геройлары Матросов, Гастелло, Карбышев, Җәлил һәм меңләгән башка каһарманнар совет халкының хәтерендә генә түгел, аңында, күңел халәтендә. Безнең патриотик хисләребезнең тамыры Ленин эше өчен, коммунистик идеология өчен, Ватан өчен гомерләрен аямаган әнә шул батырларның мәңге тере хатирәсенә дә тоташкан. Алар урам, колхоз, шәһәр исемнәренә генә әверелеп калмыйча, намус, ныклык, халыкка тугрылыклык төшенчәләренең синонимнарына әйләнделәр. Бу төшенчәләр кешенең иң олы сыйфатларын билгелиләр. Кешенең шушы сыйфатларына дан җырлау әдәбиятны һәм сәнгатьне иҗтимагый көч итә.

Муса Җәлилнең һәм аның унбер көрәштәшенең кылган каһарманлыгы язучыларны, композиторларны, рәссамнарны, театр һәм кино сәнгате осталарын илһамландырып тора икән, димәк, аларның батырлыгы халкыбыз күңелендә мәңге яшәячәк рухи көчкә әверелгән дигән сүз.

Муса Җәлил шигырьләренә язылган җырлар, романслар, вокаль циклларны һәм шагыйрьнең үзенә багышлап иҗат ителгән музыка әсәрләрен бер концертка тупласаң, ул концерт берничә көнгә сузылыр иде. Анда Нәҗип Җиһановның мәшһүр «Җәлил», «Алтынчәч» опералары, Алмаз Монасыйповның «Үлемсез җыр», Анатолий Лупповның «Сандугач һәм чишмә» балетлары, Рөстәм Яхинның «Моабит дәфтәрләре» дигән вокаль циклы кебек күләмле әсәрләр яңгырарлар иде.

Муса Җәлилнең скульптор В.Цигаль иҗат иткән бронза һәйкәле Казанның художество символларының берсенә әверелде. Рәссамнарның Муса Җәлилгә булган олы ихтирамнарын бергә туплап, әледән-әле «Сынлы сәнгатьтә Җәлил образы» дигән күргәзмәләре оешып тора. Ул күргәзмәләрдә без Харис Якуповның совет сынлы сәнгатенең алтын фондына һәм хрестоматияләренә кергән «Хөкем алдыннан» дигән картинасы, Бакый Урманченың эшләгән скульптур портретлары белән очрашабыз.

Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясе, Риза Ишморатның «Үлемсез җыр» драмасы буенча эшләнгән спектакльләр Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең образларын театр сәхнәсенә алып менделәр.

Гази Кашшафның, Рафаэль Мостафинның, Роберт Бикмөхәммәтовның шагыйрьнең иҗат һәм тормыш юлын яктырткан фәнни хезмәтләре, Шәйхи Маннурның «Муса» романы, Илдар Юзеевнең «Соңгы сынау» поэмасы, Бәхтияр Ваһабзадәнең азәрбайҗан әдәбияты дәреслекләренә кергән «Очыгыз, толпарларым!» поэмасы, күпсанлы шигырьләр, хикәяләр, җырлар, «Моабит дәфтәрләре» дигән нәфис фильм, документаль ки-

ноленталар — болар барысы да Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты, көрәше илһам чыганагына әйләнү хакында сөйли торган дәлилләр. Бу әсәрләрнең авторлары арасында сиксән яшьтән узганнары да, утызга җитмәгәннәре дә бар — совет шагыйренең, совет солдатының батырлыгы төрле буын вәкилләренә бер дәрәҗәдә иҗат ялкыны бирә ала торган көчкә ия!

Җәлилнең, җәлилчеләрнең каһарманлыкларының нигезе нәрсәдән тора соң? Аларның батырлыгы нәрсәсе белән безнең күңелләрне тартып тора соң? Билгеле, дошман оясында йөзгә-йөз килеп алып барылган яшерен көрәш романтикасы белән генә түгел. Ул көчнең асылы иң беренче нәүбәттә Җәлилнең, җәлилчеләрнең каһарманлыгы идеологик каһарманлык булуда. Коммунистик идеалга, Ватанга тугрылыклык Мусаның һәм аның көрәштәшләренең кеше буларак, солдат буларак ныклыкларының нигезендә ята!

Җәлилнең һәм җәлилчеләрнең батырлыгы аерым бер төркем кешеләрне генә гомерләрен саклап калуга юнәлтелмәгән. Аларның батырлыгы эгоистик максатлардан азат — шуның өчен дә җәлилчеләр, кулларына үлем карары китереп тоттыргач та, фашизмга каршы көрәшләрен дәвам иттерә алганнар.

Рухи каһарманлык һәрвакыт илһам чаткылары сибеп торган мәңге сүнмәс йолдыз булып кабына, йөрәкләргә юл күрсәткән маяк булып балкый! Рухи каһарманлык кешенең яшәү рәвешенә принципиаль төзлек, эшенә максатчанлык кертә, гомерләрне бәяләүче бизмәнгә әверелә. Әгәр дә син аңа табынасың икән, ул синең фикерләү рәвешеңә дә үзенең пакь эзен сала. Иҗади батырлык, ихтыяр көче, идеологик ныклык турында сүз чыкканда, без әле дә, сугыш беткәнгә утыз биш ел үткәч тә, «Җәлил кебек», «җәлилчеләрдәй» дип сөйлибез, аларны үзебезгә дә, балаларыбызга да үрнәк итеп куябыз, аларның туган көннәре безнең йөрәк бәйрәмнәренә әйләнә...

Мин 13–14 еллар элек «Мулланур» дигән поэма яздым. Аның сюжеты бик гади — Мулланурны аталар, ә ул үлми, Мулланурны суга батыралар, ә ул үлми, Мулланурны асалар, ә ул һаман да исән. Минем иҗат аңым формалашкан чорда, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең тормыш үрнәкләре булмаган булса, үлемсезлекнең мондый образын мин таба алган булыр идем микән?!

«Мулланур»ның рухи дәвамы буларак, «Яралар» циклы язылды. Безнең социалистик торышыбызга ил дошманнары, идеологиябез дошманнары үтергеч яралар салалар, ә социализм исән, социалистик Ватан исән. Бу шигырьләрнең дә аркау җебе — Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгыннан аңкыган рух.

Ахыр килеп, мин «Җәлилчеләр» дигән поэма-цикл яздым. Ул «Социалистик Татарстан» газетасының 1980 елның 28 сентябрь санында басылып та чыкты. «Кеше» ораториясенең шагыйрьгә багышланган бүлеген санамаганда, әлегә кадәр язганнарымда Җәлил һәм җәлилчеләрнең рухы гына булган булса, яңа циклымда алар үзләре минем әсәремнең персонажларына әверелделәр. «Җәлилчеләр» циклы Муса Җәлил, Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Фуат Булатов, Әхмәт Симай, Фуат Сәйфелмөлеков, Гариф Шабаев, Зиннәт Хәсәнов, Рәхим Саттар, Абдулла Баттал, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров монологларыннан гыйбарәт. Алар исеменнән сүз әйтер өчен мин үземне алар мохитенә кертергә тырыштым. Бу юлда миңа Гази Кашшафның, Рафаэль Мостафинның, Юрий Корольковның хезмәтләре ярдәм иттеләр. Җәлилчеләрнең батырлыкларын сәнгатьчә өйрәнү процессында мин тагын бер мәртәбә коммунистик идеология тәрбиясе алган кешенең рухи бөеклегенә инандым. Үзеңдә каһарманнар рухы тою — тиңдәшсез шатлык!

Җәлил һәм аның батыр көрәштәшләре турында әдәби әсәрләр СССР халыклары әдәбиятларының һәрберсендә диярлек бар. Аларның саны елдан-ел арта бара. Җәлилчеләрнең батырлыгы яңа легендалар тудыра. Әгәр дә Җәлил, җәлилчеләр турындагы барлык әсәрләрне бергә тупласаң, совет кешесенең үлемсез рухына дан җырлаучы гаҗәеп антология килеп чыгар иде.

*1982*

# Одумайтесь!

*(Текст выступления на IX Международных писательских встречах в Ясной Поляне 7–12 сентября 2004 года)*

Войны повышают температуру планеты или они возникают там, где повысилась температура Земли? Наверное, и так, и эдак... Но не это главное. А главное то, как и почему возникают «горячие точки», почему температура эта повышается, и чьих рук это дело?! Но еще главнее — как эту температуру стряхнуть?

Со времен «Илиады» и «Слова о полку Игореве» или татарского эпоса «Идегей» литература сотни тысяч раз осмысливала эти крайне больные вопросы жизни человечества. По сути дела путь развития всей мировой литературы во многом — это путь осмысления проблем войны и мира, и в этом процессе принимали участие лучшие таланты народов и благодаря этому можно сказать, они становились великими умами человечества как Лев Толстой, Михаил Шолохов, Эрнест Хемингуэй, Анри Барбюс, Иван Вазов, Алексей Толстой, Ярослав Гашек и многие другие... Почему они стали таковыми? Плюс ко всему и потому, что их произведения становились предупреждением, предостережением человечеству и сильным мира сего не делать глобальных глупостей. Великие произведения всех времен и народов о войнах и по сей день кричат: «Одумайтесь!» Но слышим ли мы их сегодня? Или не слышим?.. Скорее всего, у современных политических амбиций планетарного масштаба нет ушей, а если есть, то они забиты, как и во все времена, звоном благородного металла... А в результате: вчера — мировые войны, революции, гражданские войны в различных государствах, Кавказские войны, участниками которых были и Лермонтов, и Толстой, а сегодня — Афганистан, Балканы, Ирак, Абхазия, Южная Осетия и, конечно же, Чечня, в которых так или иначе принимают участие

наши дети, родственники, друзья...

В связи с этим я хочу рассказать о своем последнем посещении Чечни. Во время затишья между двумя кампаниями я, будучи вице-спикером парламента Татарстана, по служебным делам был в Грозном и попросил помочь мне найти своего старого приятеля — чеченского писателя Магомеда Мусаева, с которым мы переписывались, который бывал в гостях у меня дома в Казани, и который много раз приглашал нас к себе в гости. В мирное время как-то не получилось посетить его. Поехали мы по его старому адресу в Ивановский переулок, дом 4. Там должен был быть красивый — по письмам Магомеда Мусаевича — особнячок, а мы увидели на его месте огромную воронку то ли от бомбы, то ли от снаряда... Но знающие люди сказали, что писатель жив, ибо он заблаговременно выехал в горы, а потом вернулся. Действительно, так и оказалось. На следующий день мы его нашли в однокомнатной квартире чудом уцелевшей «хрущевки». Он лежал в постели со сломанной ногой в почти что пустой квартире. Весь его архив, книги, рукописи неопубликованных произведений сгорели. «Это со мной уже во второй раз, — сказал он, — первый раз в 1944 году, когда раненый вернулся с фронта на долечивание в Грозный и за 24 часа меня, раненого, депортировали в Казахстан, и вот сейчас...»

Но мое слово сегодня не об этом... А о том, что этот восьмидесятилетний тогда писатель-фронтовик, чьи произведения изучались в школах, сказал: «Неужели они забыли повесть «Хаджи Мурат» Льва Николаевича Толстого? А может, вовсе и не читали?..» Под словом «они» он имел в виду тогдашних руководителей как страны, так и Чеченской Республики. А из всей повести Льва Толстого он выцедил идею о том, как бездеятельность и пустые обещания командующего Воронцова привели к глупой гибели Хаджи Мурата, вызвавшегося помочь русским быстро завершить Кавказскую войну, да притчу Хаджи Мурата о том, как осел угощал собаку сеном, а собака потчевала осла мясом, а в конечном итоге оба остались голодными. Мы поговорили тогда о святой необходимости в многонациональной, многоконфессиональной России уважения к языкам, обычаям, устоям, культурам народов, о том, что именно пренебрежительное отношение к этим высшим ценностям человека накаляют на конкретной территории обстановку и создают благоприятную почву амбициозной экономической политике превращать ее в так называемую «горячую точку» планеты.

Любую «горячую точку», в конце концов, можно остудить. Для этого в арсенале опыта человечества есть немало способов и методов: и военных, и политических, и экономических. В конечном итоге и на Балканах, и в Ираке, и в Южной Осетии, и в Приднестровье, и в Чечне будет конституционный ли, неконституционный ли порядок, все образумится, все образуется. Но останется одна, казалось бы, неприметная проблема — опасная, ненормальная, больная память, зараженная и заряженная озлобленностью и мстительностью. Именно в «горячих точках» память человека и, осмелюсь сказать, народа заражается этими чудовищными бациллами. Именно озлобленность и мстительность мутируют в такой изуверский монстр, как современный терроризм. И, как мне кажется, именно это является одной из серьезных причин того, что так долго не заживает опасная рана Северного Кавказа, которая уже задела и Северную Осетию. И как очистить память от этой заразы? Что могут сделать в этой связи президенты, короли, главы государств и правительств? Они делают то, что делают, и не больше. Что делают в этом направлении великие религии? Эффекта пока тоже не очень видно. Что делает в этом контексте пресса? Она, на мой взгляд, больше подогревает, чем остужает, ибо слишком политизирована и чересчур свободна от ответственности. Но она способна и на многое позитивное. Если позволят... Если будет знать меру... Есть ли еще какая сила, способная эффективно действовать в этом направлении? Конечно, есть, и эта сила — литература, разумеется — настоящая, высокохудожественная, не подверженная политической или экономической конъюнктуре, стоящая выше потребы дня, литература, которая востребована обществом как учитель, строитель, врач!.. А востребована ли литература как целитель и воспитатель общества сегодняшним российским обществом, пребывающим в продолжительной социально-экономической встряске, с тревогой встречающим каждый божий день? Нужны ли вожжедержателям нашего общества великие уроки «Войны и мира», «Хаджи Мурата», «Тихого Дона», «Хождений по мукам», «Бега» и других великих произведений? Сказать трудно...

Да, литература — самый великий врачеватель заболевшей памяти, но она лечит на протяжении долгого времени и, возможно, не со стопроцентным эффектом. Но такая память уже не будет носителем агрессии. Например, память татарского народа о завоевании Казани Иваном Грозным и разрушении татарской государственности давно уже не агрессивна и, стало быть, безопасна. И в этом есть значительный вклад и татарской литературы. Память кавказских народов о Кавказских войнах XIX столетия до недавнего времени тоже была не агрессивна. Какова она сегодня? Однозначного ответа на сей счет, по-моему, уже нет. И это весьма тревожно.

И в заключение — о слове «ОДУМАЙТЕСЬ !», вынесенном как тема для обсуждения. Замечательное сильное слово-предложение и актуальнейшая тема. И хочется продолжить это предложение гениальной поговоркой «Семь раз отмерь, один раз отрежь!», так как «горячие точки» возникают именно вследствие того, что эта заповедь человеческого опыта не приходит на память в самое нужное время.

Әдәбият һәм сәнгать

# Выступление на *I* съезде художников Татарии

Дорогие художники — мастера кисти и резца!

От имени Союза писателей Татарии, Союза композиторов, Татарского отделения Всесоюзного театрального общества и Союза журналистов разрешите приветствовать вас и поздравить с открытием Первого съезда художников Татарии.

Сегодня слово «первый» звучит часто и, очевидно, еще будет звучать. Мы с удовольствием повторяем это слово, ибо видим в нем ваше совершеннолетие, ваш количественный и качественный рост, видим ваши засученные рукава для того, чтобы сделать все, чтобы за первым ритмично, планомерно последовали второй, третий и т.д. съезды художников республики. В этом слове мы видим ваше большое вдохновение, способное рождать все новые и новые полотна, графические листы, скульптуры, подготавливающие ваши очередные форумы. Всем нам известно, что без новых трудов, без новых и значительных произведений невозможно что-то обобщать, невозможно сверить себя, сравнивая созданное с проблемами, стоящими перед народом, страной. Раз собрался съезд художников, значит у вас есть что обобщать и обобщать по-крупному. Именно поэтому наши сердца переполнены той глубокой радостью, которую, как говорится, ни пером описать, ни в музыке рассказать, ни на сцене сыграть. Остается единственная попытка написать нашу радость на холсте кистью, резцом на камне и на отполированном торце яблони. Это уже, дорогие художники, ваша попытка, ваша возможность. Да сопутствует вам удача!

Мы благодарны за то, что ваш труд сплетается и с нашим трудом: на книгах писателей и нотных изданиях композиторов, на страницах журналов и газет, на сцене всех наших театров мы видим ваш труд, в общем-то украшающий, но иногда оставляющий желать лучшего.

Мы рады тому, что художники являются героями или персонажами повестей, пьес, рассказов, очерков писателей, журналистов, а писатели, композиторы, артисты, воплощенные в мраморе, граните, становятся героями произведений художников. Такое внимание друг к другу — дело очень хорошее и полезное и это содружество, очевидно, найдет свое продолжение. Но главный герой наших произведений и главный их адресат — народ, чей труд является источником богатства страны и источником вдохновения всех работников литературы и искусства. Я, наверное, выражу общее мнение всех присутствующих на этом Первом, знаменательном для всех нас съезде художников Татарии, если пожелаю вам, дорогие художники, чтобы на ваших палитрах никогда не высыхали цвета радуги и их производные, при помощи которых будете создавать не только психологически глубокие портреты, живые жанровые сцены, сочные, обильные натюрморты, до зависти лирические пейзажи, монументальные индустриальные картины и острые сатирические рисунки, но и истинно великий облик нашей бурлящей, но светлой эпохи, нашей счастливой страны, нашей республики, всего советского народа, у которого сильное, объективное, смелое и доброе сердце. Такое сердце — наш главный ориентир и в него можно попасть, шагая только по реалистическому пути искусства. Это неоспоримо!

В связи с этим и заканчивая свое выступление, хочется прочитать одно четверостишие Василия Федорова.

Мы спорили о смысле красоты,
И он сказал с наивностью младенца:
— Я за искусство левое. А ты?
— За левое, но не левее сердца.

*29 сентября,1971*

# Эскизы к творческому портрету Баки Урманче

Баки Урманче — художник-живописец, он один из ведущих скульпторов республики, один из патриархов этого искусства в Российской федерации; скульптура — главное дело его жизни.

Но Баки Урманче — и знаток истории татарского народа и активный ее пропагандист. Он — знаток литературы, песен.

